# Мөселман өммәтенә мөһим дәресләр

**Хәйсәм бин Мөхәммәд Джәмил Сәрхән**
**аңлатмасы**
Пәйгамбәребез мәчетендәге институтта укытучы булып эшләгән һәм

http://attasseel-alelmi.com

сайтының җитәкчесе

Аллаһ Тәгалә үзен дә, эти-әнисен дә, бу китапны чыгарырга ярдәм иткән кешеләрнең дә гөнаһларын гафу итсен

**Бу китап – вакыф, бушка тарату нияте белән эшләнде. Әлеге китапны сатарга ярамый.**

Беренче басма

Барлык хокуклар сакланган.
Кем дә кем бу китапны бастырырга һәм бушка таратырга яки бүтән телгә тәрҗемә итәргә теләсә, түбәндәге адреска язып, рөхсәт алырга кирәк:

islamtorrent@gmail.com

فسح وزارة الإعلام

# Авторның кереш сүзе

بسم الله الرحمن الرحيم
Шәфкатьле һәм Мәрхәмәтле Аллаһ исеме белән

Аллаһ Тәгаләгә барлык мактаулар, хәерле нәтиҗә бары тәкъвалы бәндәләргә генә. Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә һәм аның гаиләсенә, аңа ияргән сәхәбәләргә Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын.

Бу кыска гына китап Ислам дине буенча һәрбер мөселман белергә тиешле кайбер гыйлемнәрне аңлатып бирә һәм мин аны: "Мөселман өммәтенә мөһим дәресләр", - дип атадым.

Аллаһ Тәгаләдән әлеге китапның мөселманнарга файда китерүен һәм миннән кабул кылынуын сорыйм.

Ни өчен без мөһим дәресләр китабын өйрәнәбез?

Чөнки автор әйткәнчә, үтә мөһим булганга һәм галимнәр киңәш иткәнгә.

Әгәр дә берәү: "Әйе, бу мөһим китап, әмма гади кешеләр өчен. Мин бит инде гыйлем алучы, гади халыкныкына караганда минем дәрәҗәм зуррак", - дип әйтсә, моңа җавап итеп без аннан бу китапта булган гыйлемнәр хакында сорарбыз, әгәр җавап бирә алмаса, гади халык аннан хәерлерәк. Гыйлем алучы тыйнак булырга, гыйлемнән һәм галимнәрдән өстен булырга тиеш түгел һәм галимнәр күрсәткән юлдан барырга тиеш. "Сахих Бухарида" килә, Мүҗәһид исемле галим болай дигән: "Оялчан һәм тәкәббер кеше гыйлем ала алмас".

## Бу китап үз эченә нәрсәләрне ала соң?

1. Коръән укуда, ятлауда, фикерләүдә һәм гамәл кылуда изге һәм яхшы гамәл кылып яшәгән үткән буын кешеләренең юлларын.
2. Ислам, Иман, Ихсан, Тәүхид һәм ширекнең төрләре турында аңлатма бирүне.
3. Намаз турында бәян кылуны.
4. Тәһарәт турында ачыклык кертүне.
5. Күркәм сыйфатлар һәм Ислам диненең әдәп-әхлагы турында.
6. Ширектән һәм башка гөнаһлардан кисәтүне.
7. Мәетне җирләү, аны кәфенләү һәм аңа намаз уку хөкемнәрен.

## Ни өчен галимнәр үз хезмәтләрен “Бисмилләһ” белән башлыйлар?

1. Аллаһның Китабына һәм пәйгамбәрләргә ияреп (алардан үрнәк алып).

2. Алдагы буын галимнәргә ияреп. Гадәттә, алар китапларын “бисмилләһ” белән башлый торган булганнар.

3. Аллаһның исеме белән башланган эш бәрәкәтле булачак.

4. “Аллаһ исеме белән башланмаган һәрбер эш...” - хәдисенә ияреп, ләкин бу хәдис зәгыйфь.

# Беренче дәрес

**“Фатихә” сүрәсе һәм кыска сүрәләр.**

Беренче дәрес «Әл-Фатиха», шулай ук «Җир тетрәү» сүрәсеннән алып «Кешеләр» сүрәсенә кадәр булган башка кыска сүрәләрне өйрәнүгә, аларны дөрес итеп укуга һәм мәгънәсен төшенүгә багышлана.

## Аңлатма:

Коръәнне өйрәнүдә алдагы буын галимнәреннән үрнәк алырга кирәк: алар, көн саен, мәгънәләре хакында фикерләп, ун аять өйрәнгәннәр. Бу гамәлдә безгә Габдрахман ибн Насыйр Әс-Саадиның (Аллаһ аны кичерсен) Коръәннең кыскача аңлатмасы ярдәмгә килер. Шулай ук Коръәнгә муафыйк рәвештә гамәл кылуда Аллаһтан ярдәм сорыйк.

Гыйлем эзләүчегә Коръәнгә аңлатма бирүче китапларның кайсысыннан башларга соң?

Габдрахман ибн Насыйр Әс-Саадиның Коръәннең кыскача аңлатмасыннан башлау мәслихәт. **Ни өчен**?

- Галимнәрнең киңәшен тотып һәм аларның әлеге китапка игътибарларын юнәлтү сәбәпле.
- Чөнки бу китапның эчтәлеге кыскача, шуңа күрә яңа гына гыйлем эзләү юлына басучыга ул уңайлы булачак.
- Чөнки аның мәгънәсе гади һәм аңлаешлы.
- Чөнки ул, әгәр Аллаһ теләсә, Коръәнгә муафыйк рәвештә гамәл кылырга ярдәм итә.
- Чөнки автор тәүхид мәсьәләсенә аеруча игътибарны юнәлтә.

**Кешеләр, Коръәнгә карашлары буенча, өч төркемгә бүленделәр:**

Бер төркеме Коръәнне ташлады. Ул менә нәрсәләрдә чагыла:

Икенче төркем кешеләр Коръәнне укыйлар, өйрәнәләр, әмма аның мәгънәсе хакында һич фикерләмиләр һәм аңа муафыйк рәвештә гамәл кылмыйлар.

Өченчеләре Коръәнне укуда, аны өйрәнүдә, аятьләрнең тирән мәгънәләре хакында фикерләүдә даимилек күрсәтәләр һәм Аллаһтан Коръәнгә муафыйк рәвештә гамәл кылуда ярдәм сорыйлар. Болар – яхшы гамәл кылып яшәгән үткән буын кешеләре һәм аларның дәвамчылары.

- Коръән укуны калдыру
- Коръәнне өйрәнмәү
- Аның мәгънәләре хакында фикерләмәү
- Коръәнгә муафыйк рәвештә гамәл кылмау
- Коръән ярдәмендә дәвалауны калдыру

Аллаһ Тәгалә әйтте:" **Пәйгамбәр әйтте: “Я, Раббым, минем халкым Коръәнне ташлады”"** (“Фуркан” сүрәсе, 30нчы аять).
Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа сәламе вә рәхмәте булсын) әйтте: **“Аның нәселеннән шундый кешеләр булыр ки, алар Коръәнне укырлар, әмма ул аларның бугазларыннан ары калебләренә төшмәс. Алар мөселманнарны һәлак итеп, ширек кылучыларны исән калдырырлар. Алар корбанга кадалган ук кебек Ислам диненнән чыгарлар. Әгәр андыйларны очратсам, мин, һичшиксез, аларны, Гад кавеме һәлак ителгән кебек, шул рәвешле һәлак итәчәкмен”** (Бохари 3610 һәм Мөслим 1064).

## Габдрахман ибн Насыйр Әс-Саадиның Коръәннең кыскача аңлатмасыннан өзекләр

### “Фатиха” сүрәсе аңлатмасы (сүрә Мәккәдә ингән)

**(1) Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән. (2) Барча мактау галәмнәрнең Раббысы (Тәрбиячесе һәм Хуҗасы) булган Аллаһка тиешле. (3) Ул – Рәхмәтле, Ул – Рәхимле! (4) Ул – Кыямәт көненең Патшасы. (5) Сиңа гына гыйбәдәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз. (6) Син безне туры юлга бастыр. (7)Ул юл, Синең тарафыңнан нигъмәтләндерелгән бәндәләреңнең юлы булсын, Ачуың төшкән һәм адашканнарның юлларыннан булмасын.**

---

**(1)** Бу сүзләр: “Мин Аллаһ исеме белән башлыйм”, - дигәнне аңлата. Әлеге сүзтезмәнең лексик мәгънәсеннән шул аңлашыла: Аллаһ исеме Аллаһ Тәгаләнең барлык күркәм исемнәрен дә үз эченә алган. Аллаһ – әлеге исемнәрнең берсе, ул: “Иләһләштерелгән һәм табына торган, Үзенең камил һәм саф иләһи сыйфатлары сәбәпле табынырга лаек булган Бердәнбер Иләһ”, - дигәнне аңлата. Рәхмәтле һәм Рәхимле дигән күркәм исемнәре Аның Үзе бар кылган бар нәрсәләргә, бар тереклеккә Бөек шәфәгатьче булуын раслый. Аллаһның тулы дәрәҗәдәге рәхим-шәфкатенә бары пәйгамбәрләр һәм рәсүлләр юлыннан баручы, Аннан чын курку белән куркучы коллары гына лаек булачак. Ә башка тереклек ияләре исә Аның рәхим-шәфкатенең бары тик бер өлешен генә алачаклар. Шуны белергә кирәк: хак галимнәр беравыздан Аллаһка һәм аның иләһи сыйфатларына ышанырга кирәклек хакында әйтәләр иде. Аллаһ Тәгалә - Рәхмәтле һәм Рәхимле, ягъни Ул Үзенең колларында чагылыш тапкан рәхим-шәфкатькә ия. Барлык яхшылыклар һәм байлыклар – Аның мәрхәмәте һәм рәхимлелегенең бер чагылышы булып тора. Шуны ук Аллаһның башка исемнәре хакында да әйтергә була. Ул һәрнәрсәне белүче, ягъни һәрнәрсә хакында да Аның гыйлеме бар. Ул куәтле, ягъни Аның бар нәрсәгә дә көче җитә...

**(2)** Бу – иләһи сыйфатлары һәм гаделлеге яки рәхимлелеге сәбәпле кылыначак гамәлләре өчен Аллаһка мактау сүзләре. Барча мактау бары Аңа гына һәм Ул моңа тулысынча лаек. **(3)** Ул Берүзе генә бар дөнья өстеннән хакимлек итә. Бу дөньяга Аллаһның Үзеннән кала бар нәрсә дә керә. Ул галәмнәрне бар кылды, анда тереклек итүчеләргә яшәү өчен барлык шартларны да тудырды, күптөрле байлыклар бирде. Әгәр әлеге нигъмәтләр юкка чыкса, бер тереклек иясе дә хәтта мизгел дә яши алмас иде.Тереклек ияләренә бирелгән барлык нигъмәтләр - Аллаһ Тәгаләнең бүләге. Аллаһның хакимлеге ике төрле була: гомуми һәм шәхси. Аллаһ Тәгалә тереклек ияләрен бар кылды, ризык бирде, аларга туры юлны күрсәтте – шушы нигъмәтләр сәбәпле кеше үзенең бу дөньядагы тормышын көйли, җайлый ала. Бу *гомуми хакимлекнең чагылышы*. *Ә шәхси хакимлек шунда чагыла:* Аллаһ Үзенең яраткан колларын тәкъвалык рухында тәрбияли, аларга иманнарын үстерергә һәм камилләштерергә ярдәм итә, туры юлдан тайпылдырырга һәм Үзеннән ерагайтырга мөмкин булган бар нәрсәләрдән саклый. Шәхси хакимлекнең мәгънәсе шунда: Аллаһ Үзенең колларына изгелекләр эшләү юлын җиңеләйтә, барлык начарлыклардан саклый. Бәлки шуңа, пәйгамбәрләр үзләренең догаларында Аллаһны үзләренең Раббылары дип атаганнар. Аларның барлык омтылышлары да фәкать Аллаһ Тәгаләнең шәхси хакимлеге белән генә бәйле булган. Бу вәхийдә Аллаһ Тәгалә Үзен Галәмнәрнең Хуҗасы дип атаган һәм шуның белән бары тик Үзенең генә бу дөньяны яралтучы, аның белән идарә итүче һәм нигъмәтләндереп торучы булуын ассызыклаган. Ул бай һәм Үзе халык кылган нәрсәләрдә мохтаҗ түгел. Киресенчә, халык кылынган бар нәрсә дә Аңарда мохтаҗ һәм һәрьяклап Аңа бәйле.

**(4)** Хаким – ул тәхеткә ия булып, хакимлек иткән, шул сәбәпле боерырга һәм тыярга, бүләк бирергә һәм җәзаларга, үз кул астындагылар белән тулы хакимлек итәргә хаклы булган Зат. Хакыйкый хакимлекнең Кем кулында булуы Җәза көнендә билгеле булачак. Бу Кыямәт көнен билгеләүче эпитетларның берсе, бу көндә кешеләр яман яки изге гамәлләре өчен билгеләнгән җәзаны алырлар. Нәкъ менә шушы көндә Аллаһның хакимлеге, гаделлеге һәм хикмәтенең камиллеге ачык күренер. Аларның барысы да элек булган нәрсәләрен югалтырлар.

Патшалар һәм аларның ялчылары, коллар һәм ирекләләр – аларның барысы да Аллаһ каршында тигез булыр, Аның кодрәтенә һәм Бөеклегенә буйсыныр. Алар Аның хөкемен көтәр, Аның бүләген теләр, җәзасыннан куркыр. Менә ни өчен Раббыбыз Аллаһ Үзен Кыямәт көненең Патшасы дип атаган, гәрчә Аның хакимлеге барлык чорларга таралса да.

**(5)** Гарәп теленең грамматикасына күз салыйк: әгәр алмашлык фигыль алдында килсә, эш-хәрәкәт бары тик телгә алынган затка (һич тә башка затларга түгел)  мөнәсәбәтле рәвештә генә үтәлә. Шуңа күрә тикшерелә торган аять без башка затларга түгел, бары тик Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм башка затлардан түгел, ә бары тик Синнән генә ярдәм сорыйбыз, дигән мәгънәдә килә. Гыйбадәт кылу ярдәм сорауга караганда алданрак телгә алынган, һәм бу шәхсине гомумигә кертүнең мисалы булып тора, чөнки санап киткән вакытта гомумине шәхсигә караганда иртәрәк телгә алу кабул ителгән. Шулай ук сүзләрнең мондый тәртибе Аллаһ Тәгаләнең хакы, Аның колларының хакына караганда өстенрәк булуына да ишарәли. *Гыйбадәт кылу  - ул калеб белән дә, тән белән дә кылына торган Аллаһ сөйгән һәм хуплаган барлык сүзләрне һәм гамәлләрне үз эченә алган төшенчә. Ярдәм сорау – Аллаһ Тәгаләгә яхшылыклар белән бүләклә, явызлыклардан сакла, дип, һичшиксез кабул булуына ышаныч белән сугарылган дога белән мөрәҗәгать итү*. Нәкъ менә гыйбадәт һәм ярдәм сорап дога кылу мәңгелек бәхеткә ирешүнең һәм барлык начарлыклардан котылуның ышанычлы ысулы булып тора. Шулардан башка бүтән юллар юк. Гыйбадәтнең дә асыл мәгънәсе шунда: ул бары тик Аллаһ ризалыгы өчен һәм пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) күрсәтмәләренә муафыйк рәвештә үтәлергә тиеш. Әлеге ике шарттан башка һичбер гыйбадәтнең дә мәгънәс юк. Ярдәм сорап дога кылу – гыйбадәтнең бер формасы булып торса да, Аллаһ Тәгалә аның хакында аерым искә алды, чөнки нинди генә гыйбадәт башкармасын, Аллаһның колы үзенең Раббысының ярдәменә мохтаҗ. Алланың ярдәменнән башка кеше һич тә Аның кушканнарын төзек рәвештә үти, ә тыйганнарыннан тулы рәвештә тыела алмый.

**(6)** Бу безгә туры юлны күрсәт, шуңа күндер һәм шул юлдан тайпылмаска ярдәм ит дигәнне аңлата. Әлеге туры юл Аллаһка алып бара һәм Җәннәттә тәмамлана, ә ул юлны бары тик хаклыкны таныган һәм гамәлне шуның нигезендә башкарган кеше генә үтә ала. Ул шулай ук безне туры юлга күндер һәм шул юлдан тайпылдырмыйча алып бар дигәнне дә аңлата. Беренчесе Ислам динен кабул итеп башка барлык диннәрдән ваз кичүне, икенчесе Ислам дине кануннарын өйрәнү һәм алар нигезендә гамәл кылу дигәнне аңлата. Бу дога динебездәге иң файдалы, үтә тирән мәгънәле догаларның берсе. Аллаһ кешеләргә әлеге сүзләр белән намазның һәр рәкәгатендә Үзенә ялваруны йөкләгән, чөнки һәр кеше Аллаһның ярдәменә мохтаҗ.

**(7)** Туры юл – ул Аллаһ Тәгалә риза булган кешеләр – пәйгамбәрләр, тәкъва мөэминнәр, шаһитләр һәм изгеләр юлы. Ул – хакны аңлап та, аннан йөз чөергән һәм шул сәбәпле Аллаһның ачуын алган кешеләр юлы түгел. Яхудиләрнең һәм башка халыкларның язмышы әнә шундый булды. Һәм бу насаралар һәм башка үзләренең наданлыклары һәм саташулары аркасында хаклыктан йөз чөерү сәбәпле адашкан халыкларның да юлы түгел.

Кыска булуына карамастан, бу сүрә Коръәннең башка сүрәләрендә булмаган мәгънәне үз эченә алган. "Галәмнәрнең Раббысы" дигән сүзләрдә бер Аллаһның Раббылыгына иман китерү формалашкан. Аллаһның гыйбадәткә лаеклы икәнлегенә иман китерү "Аллаһ" сүзендә һәм "Сиңа гына гыйбәдәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз" аятендә чагыла. Ә Аллаһның күркәм исем-сыйфатларына иман китерү исә "Барча мактау Аллаһка тиешле" сүзләреннән килеп чыга, бу хакта инде алдарак әйтелде. Ул Үзе һәм пәйгамбәребез (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) сыйфатлаган Аллаһ Тәгаләнең барлык исем-сыйфатларына иман китерүне күздә тота. Шул ук вакытта Аллаһның исем-сыйфатларын аларның асыл мәгънәсеннән мәхрүм итәргә һәм мәхлукларның сыйфатларына тиңләргә ярамый.

Әлеге сүрәдә шулай ук Мөхәммәднең пәйгамбәрлек миссиясе дә исбатлана, ул "Син безне туры юлга бастыр" сүзләрендә чагылыш таба. Әйе, әгәр пәйгамбәр җибәрелмәгән булса, бу мөмкин хәл булмас иде. "Ул – Кыямәт көненең Патшасы" сүзләре исә кешеләр үзләренең кылган гамәлләренә карата җәзаларын һичшиксез алачакларына ишарәли. Һәм бу җәза гадел булачак.

Әлеге сүрә шулай ук кадаритлар и джәбритләр карашларының хаталы булуын да фаш итә, чөнки биредә, кешеләрнең сайлап алу хокукы булуына карамастан, бар нәрсә дә Аллаһ язганча булуы хакында раслана. Моннан тыш, бу сүрәдә динсезләр һәм адашкан агымнарның карашлары кире кагыла, чөнки “Син безне туры юлга бастыр” сүзләре мөселманнарны хакыйкатьне танып белергә һәм хакыйкать нигезендә гамәл кылырга чакыра. Динсезләр, дингә яңалык кертүчеләр, адашучыларга килгәндә исә, аларның һәрберсе хакыйкатьтән йөз чөерә. Моның белән беррәттән, әлеге сүрәдә Аллаһ Тәгаләгә ихлас табынуга һәм ярдәм сораганда бары тик Аңа гына мөрәҗәгать итүгә  чакыру да бар. “Сиңа гына гыйбәдәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз” сүзләренең мәгънәсе дә шуннан гыйбарәт. Мактау исә бары Аллаһка, Галәмнәрнең Раббысына гына тиешле!

## “Аятелкөрси”нең аңлатмасы

**"Аллаһ! Аннан башка гыйбадәткә лаеклы зат юк. Ул — мәңге Тере.Ул — барча тереклекне, яшәешне Барлап торучы. Аны беркайчан йокымсырау басмас. Ул беркайчан да йокыга китмәс. Күкләрдәһәм җирдә булган һәрнәрсә — Аныкы. Ул һәрнәрсәне юктан бар итте һәм Ул — аның Хуҗасы. Кем Кыямәт көнендә, Аның каршысында торганда, Аның рөхсәтеннән башка берәрсе өчен шәфәгать кыла алыр икән? Юк, Аның рөхсәтеннән башка берсе дә шәфәгать кыла алмас, берәү дә башканы яклап сүз әйтергә кыймас. Ул һәрнәрсәнең үткәнен дә, киләчәген дә, дөньядагысын да, Ахирәттәгесен дә белә. Тик, алар гына, Аның иксез-чиксез гыйлеменнән, Ул Үзе теләп аларга белгерткән нәрсәдән башканы белмиләр, чолгап ала алмыйлар. Аның көрсие — тәхете янындагы аяк кую урыны — күкләрне һәм җирне үз эченә алды. Шул күкләрне һәм җирне, күктә һәм җирдә булган һәрнәрсәне саклау Аның өчен бер дә авырлык китерми, Аны бер дә мәшәкатьләндерми.Ул — бар нәрсәдән дә Югары. Ул — һәрнәрсәдән дә Бөек”.**

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әйтте: “Бу – Коръән аятьләренең иң бөеге, чөнки ул тәүхидне һәм Аллаһ Тәгаләнең чиксез исем-сыйфатларын үз эченә алган». Аллаһ барлык иләһи исем-сыйфатларга да ия, һәм иләһләштерү өчен дә һәм табынырга лаеклы булган да Бердәнбер зат булып тора, шуңа күрә башка мәхлукларны иләһләштерү дөрес түгел һәм файдасыз. Тере – Аллаһның күркәм исемнәренең берсе. Аллаһ Үзендә тормыш, яшәү билгеләренең (Аның асылы белән бәйле булган ишетү, күрү, бөеклек, ихтыяр һәм башка шундый сыйфатлар) барысын да берләштерә дигәнне аңлата ул. Тормышны куәтләүче – Аллаһның тагын бер күркәм исеме – Аллаһ иң камил эшләрне башкара дигәнне аңлата. Ул Мохтаҗсыз Хаким, Ул Үзенең мәхлукларында мохтаҗ түгел, Ул аларны барлыкка китерә, аларның яшәешендә ярдәм итә һәм барлык кирәкле нәрсәләр белән тәэмин итә. Аллаһның камил яшәеше һәм мохтаҗсызлыгы шунда чагыла: Аны һичкайчан йокымсырау да, йокы да алмый. Әлеге күренешләр бары мәхлукларга хас: алар арыйлар, аларны йомшаклык һәм көчсезлек баса. Әмма бу күренешләр бөеклеккә, кодрәткә һәм мәһабәтлелеккә ия булган Аллаһка ят. Аллаһ җир һәм күкләр хакимлегенең бары тик Үзендә генә булуын хәбәр итте. Барлык мәхлуклар – Аллаһның коллары, һәм аларның берсе дә бу бәйлелектән котыла алмый. Аллаһ Тәгалә әйтте: “Җирдә вә күкләрдә гакыллы зат булса һәммәсе кыямәт көнне кол сурәтендә Аллаһка килер” (19:93). Аллаһ Үзенең коллары белән хакимлек итә һәм мөлкәткә, бөеклеккә, куәткә һәм башка Хаким һәм Хөкемдар сыйфатларына ия. Аның рөхсәтеннән башка Аңа беркем дә шәфәгать сорап мөрәҗәгать итә алмый – Аллаһның Хакимлегенең камиллеге дә шунда күренә. Аңа кем өчендер шәфәгать сорап мөрәҗәгать итәргә хаклы иң шөһрәтле мәхлукларның барысы да Аның коллары һәм Аның рөхсәтеннән башка алар кемнедер яклап, Аллаһка шәфәгать сорап мөрәҗәгать итә алмыйдыр. Аллаһ Тәгалә әйтте: “Әйт син аларга: "Шәфәгатьнең барчасы Аллаһка хастыр, Аның үзеннән башка һичкем шәфәгать итә алмас. Җир вә күкләр Аллаһ мөлкедер, соңра Аңа кайтарыласыз” (39:44). Аллаһ Үзе риза булган бәндәләре өчен генә шәфәгать сорап мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек бирә, ә Аллаһ бары тик пәйгамбәрләр юлыннан баручы тәүхид әһелләреннән генә риза. Әгәр адәм баласы мондый сыйфатларга ия булмаса, аның шәфәгатьтә

һичнинди дә өлеше юк. Шуннан соң Аллаһ Үзенең чиксез һәм бар нәрсәне үз эченә ала торган гыйлеме хакында бәян итте. Әлеге гыйлеме сәбәпле Ул бар нәрсәне дә: киләчәктә, ул нинди генә ерак киләчәк булмасын, мәхлукларны нәрсә көтәсен дә, үткәндә, ул нинди генә ерак үткән булмасын, мәхлуклары белән ниләр булганны да белеп тора. Аллаһтан һичбер нәрсәне яшереп булмый, Ул бар нәрсәне белә: яшереп эшләгән эшне дә, хәтта калебләрдә яшеренгән серне дә. Мәхлукларга килгәндә исә, алар Аллаһ гыйлеменнән бары тик Ул теләгән нәрсәләрне генә һәм Ул теләгән микъдарда гына белә ала. Ул кешеләрне дин кануннарына  һәм галәм законнарына өйрәтте, әмма бу гыйлемләр – Бөек Раббыбызның  гыйлеме океанына төшеп югалган бер тамчы су шикелле бик кечкенә, бик нәни генә бер өлеш. Нәкъ менә шуңа күрә дә Аллаһ хакында башка мәхлуклардан яхшырак һәм күбрәк белгән рәсүлләр һәм фәрештәләр әйтәләр иде: “Ий һәр кимчелектән пакь булган Раббыбыз! Бездә һич белем юк, мәгәр Син белдергәнне генә beләбез, Син, әлбәттә, һәрнәрсәне белүче, хикмәт белән эш кылучысың” (2:32).

Шуннан соң Аллаһ, җирне һәм күкләрне чолгап алучы Көрсине шаһит итеп китереп, Үзенең олугълыгы һәм бөеклеге хакында белдерде. Галәмнәрнең билгеләнгән бер тәртибе һәм билгеле бер  законнары сәбәпле, Аллаһ җирне вә күкләрне, шулай ук андагы барча мәхлукларны саклап тора. Әмма бу эш Аны һич тә ардырмый, чөнки Аның кодрәте камил, хакимлеге чиксез, ә кануннары зирәклек белән куәтләнгән.  Аның тагын бер күркәм исеме – Иң өстенлекле. Ул Үзенең асылы белән мәхлуклардан өстен тора, Аның сыйфатлары өстенлек белән куәтләнгән, Аның өстенлегенә барлык мәхлуклар да буйсына, барлык коллар да Аңа буйсынган. Аллаһның тагын бер исеме – Бөек. Ул үзенә бөеклек, мактау, мәһабәтлелек һәм дан сыйфатларының барысын да туплаган, шул сәбәп аркасында йөрәкләр Аңа карата мәхәббәт, ә калебләр хөрмәт хисе белән тула. Хак гыйлем ияләре яхшы белә: теләсә-кайсы мәхлукның бөеклеге (әлеге мәхлук башкалар арасында иң данлыклы һәм бөеге булса да хәтта) Иң өстенлекле һәм Бөек Раббыбызның бөеклеге каршында бөтенләй әһәмиятсез.

Әлеге аять, чыннан да, искиткеч һәм соклandyргыч мәгънәгә ия һәм Коръән аятьләренең иң бөеге дип аталырга лаек. Әгәр кеше аны, мәгънәсенә төшенеп, мәгънәсе хакында фикерләп укыса, аның йөрәге

инану, гыйлем һәм иман белән тулачак, шул сәбәпле ул үзен шайтанның явызлыгыннан саклаячак.

## “Әз-Зәлзәлә”сүрәсенең (Җир селкенү. Мәдинәдә иңгән) аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!(1) Җир үзенең тетрәүе белән тетрәгәч, (2) Һәм җир үзенең эчендәге йөкләрне (үлекләрне, хәзинәләрне) чыгаргач, (3) һәм кешеләр әйтерләр: "Ни булды бу җиргә", – дип. (4) Шул көндә җир үзенең өстендә эшләнгән эшләрне сөйләп бирер. (5) Чөнки Раббың аңа сөйлә, дип әйтер. (6) Ул көнне кешеләр каберләреннән кубарылып, нинди гамәлләр кылганлыкларына күрер өчен, төркем-төркем булып, хисап бирергә барырлар. (7) Берәү тузан бөртеге хәтле генә яхшылык кылган булса, аны күрәчәк. (8) Һәм берәү тузан бөртеге хәтле гөнаһ эшләсә, аның җәзасын күрер.**

(1-3) Аллаһ Тәгалә Кыямәт көнендә булачак вакыйгалар хакында, җирнең үзенең өслегендә булган бөтен нәрсәләр дә җимерелеп беткәнчегә кадәр селкенәчәге турында хәбәр бирә. Ул көндә таулар таралыр, ә калкулыклар җир белән тигезләнер. Бөтен җир калкулыкларсыз һәм иңкүлекләрсез булып тигезлеккә әверелер. Җир үз астындагы мәетләрне, кайчандыр күмелгән байлыкларны чыгарып атар, шулвакыт кешеләр моны күрерләр һәм: “Җир белән нәрсә булган соң?” – диярләр.

(4-6) Җир галәмнәрдә яшәгән барча мәхлүкның яхшы һәм яман эшләре хакында сөйләр. Ул кешеләрнең гамәлләре хакында иң дөресен һәм чынын сөйләүче шаһитларның берсе булачак. Аллаһ җиргә аның өслегендә булган бар нәрсә хакында сөйләргә кушар һәм ул Аның боерыгын үтәмәскә батырчылык итмәс. Ул көнне кешеләр аерым төркемнәргә бүленәчәк һәм, төркем-төркем булып, җыелу урынына чыгачаклар. Аллаһ аларга кылган гөнаһларын һәм изгелекләрен күрсәтер, һәм аларның барысы өчен дә үз җәзасын билгеләр.

**(7-8)** Бу тулаем барлык изге һәм начар гамәлләргә дә кагыла, чөнки тузан бөртеге кадәр булган гамәлен күргән кеше, зур гамәлләрен дә һичбер авырлыксыз күрәчәк. Аллаһ Тәгалә әйтте: “Кыямәт көнне һәр изге кеше эшләгән изге эшләренең әҗерен хәзерләнеп, алдына куелганын табар. Бозык эшләрне эшләүчеләр дә гөнаһлары алларына куелганны күрерләр. Бу явыз эшләрнең иясе, явыз эшләре белән үзенең арасын бик ерак булуны теләр, ләкин явыз эшләре үзе белән мәңге бергә булыр”(3:30); “Ул көндә һәркемнең гамәл дәфтәре алдына куелыр һәм гөнаһлы кешеләрне дәфтәрләренә язылган гөнаһларыннан куркучы күрерсең һәм әйтерләр: "Безгә һәлакәтлек килде, ни булды бу дәфтәргә, гөнаһларыбызның кечкенәсен дә, зурысын да калдырмаган, мәгәр барын да санаган, язган", – дип. һәм кылган эшләренең җәзасы хәзерләнеп куелган. Раббың һичкемгә золым итмәс”.(18:49) Бу әйтелгәннәр кешеләрне, кечкенә генә булсын ул, яхшылык эшләргә һәм, киресенчә, кечкенә генә булсын, явызлык кылудан тыелып калырга өнди.

## “Әл-Гадият” (чабып баручылар. Мәккәдә иңгән) сүрәсе аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән**

(1) Тыннары бетеп чабучы атлар белән ант итәм. (2) Дагалары белән ут чыгарып чабучы атлар белән ант итәм. (3) Таң вакытында Аллаһ юлында ашыгып чабучы атлар белән ант итәм. (4) Ул атлар, каты чабулары белән тузан күтәрерләр. 5.Дошман өеренең уртасына бәреп керделәр (6) Дөреслектә, кеше үзенең Раббысына шөкер кылмаучы (шөкерсездер). (7) Һәм һичшиксез, ул моңа үзе шаһит. (8)Хакыйкаттә, адәм баласы дөнья малын бик нык ярата. (9) Әллә адәм баласы белмиме, алар каберләреннән кубарылып чыгарылачагын, 10. һәм күкрәктәге уй-фикерләр ачылгач, (11)дөреслектә, Раббылары аларның кылган эшләреннән хәбәрдар икәнен?

**(1-2)** Аллаһ Тәгалә атлар белән ант итә, чөнки атлар Аллаһның күркәм галәмәтләрен гәүдәләндерәләр һәм кешеләргә бик зур файда китерәләр. Шул ук вакытта Ул атларның шундый сыйфатларын ассызыклаган ки, әлеге сыйфатлары белән алар башка хайваннардан күпкә өстенрәк. Алар томырылып чаба һәм аларның сулышлары тыгыла, нәтиҗәдә, күкрәкләреннән гаҗәеп аваз чыга. Аларның тояклары шулкадәр каты, ә җиргә басулары шулкадәр нык ки, алар хәтта тояклары белән ут чыгара.

**(3-5)** Әлеге сүзләрдән шул ачыклана: һөҗүм, кагыйдә буларак, иртә таңнан башлана. Аллаһ Тәгалә әлеге антларны кешенең Аллаһның кушканнарын үтәүдән һәм яхшы гамәлләр кылудан баш тартуын раслау өчен китерә.

**(6)** Кешенең табигате шундый: күңеле һәрвакыт аны үзенең вазифаларын, бурычларын тиешле дәрәҗәдә җиренә җиткереп үтәүдән һәрвакыт тотып тора. Кеше ялкау һәм еш кына үзенең матди һәм физик вазифаларын үтәүдән баш тарта. Әлеге кимчелектән бары тик Аллаһ туры юлга күндергән бәндәләр генә азат була ала. Бу кешеләр үзләренең бурычларын төгәл үтиләр һәм чын бөеклеккә ирешәләр.

**(7)** Кеше – үзенең комсызлыгы һәм шөкерсезлеге шаһиты. Ул моңа каршы да килми һәм аны кире дә какмый, чөнки бу сыйфатлар ачык күренеп тора. Өченче зат алмашлыгы Аллаһка кагыла, дигән фикер бар. Димәк, әлеге аңлатмадан шул килеп чыга: кеше үзенең Раббысына шөкер итми һәм рәхмәтле түгел, һәм Аллаһ моңа шаһит. Әлеге сүзләрдә кешенең һәр гамәленең шаһиты булган Аллаһ Тәгаләгә шөкер итәргә теләмәүчеләр өчен олугъ бер куркыту бар.

**(8)** Нәкъ менә байлыкны яратуы кешене Аллаһ каршындагы бурычларны үтәмәскә мәҗбүр итә. Ул Аллаһның рәхмәтенә ирешүгә түгел, ә үзенең нәфесен канәгатьләндерүгә өстенлек бирә. Моның сәбәбе исә шунда: кеше Мәңгелек тормыш хакында онытып, үзенең күзаллауларын бу дөньядагы тормыш белән генә чикли.

**(9-11)** Әлеге сүзләр белән Аллаһ Тәгалә кешеләрне Кыямәт көненнән куркырга чакыра. Әлеге куркыныч көндә Аллаһ мәетләрне терелтер һәм бар кешеләрне гадел хөкем өчен җыяр. Кешенең калебендә яшеренеп яткан барлык изгелекләр һәм начарлыклар, ул көнне аерым-ачык күренәчәк. Яшерен булган нәрсәләр дә ачыкланыр, ә кешеләрнең йөзләрендә кылган эшләре чагылыр. Әлеге гамәлләрнең һәркайсы хакында Аллаһ Тәгалә белер, һәм Ул, һичшиксез, кешеләргә, кылган гамәленә карап, җәзасын билгеләр. Аллаһ Тәгалә Үзенең мәхлуклары кылган гамәлләрне һәрвакыт белеп тора, әмма Ул Кыямәт көнендәге хәбәрдарлыгы хакында аерым әйтте, чөнки гадел хөкем Аның чиксез гыйлеме нигезендә башкарылачак.

## “Әл-Карига” (Дәһшәтле кыямәт көне. Мәккәдә иңгән) сүрәсе аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!**

**1. Дәһшәтле көн, кыямәт көне! 2. Нәрсә ул дәһшәтле көн, кыямәт көне! 3. Каян белә идең син кыямәт көнен? 4. Ул көндә кешеләр тузылган (таралаган) вак күбәләкләр кебек булырлар, 5. һәм таулар тетелгән йон кебек булырлар. 6. Кемнең үлчәүе авырырак булса(саваплы изге намәлләр белән), 7. ул рәхәт тормышта булыр. 8. Әмма кемнең үлчәү җиңеллерәк булса (саваплы, изге гамәлләре аз булу сәбәпле) , 9. аның анасы Һавийә булыр. (аның сыеныр урыны һавийа булыр) 10. Ул Һавийәнең нәрсә икәнен сиңа нәрсә белдерде? 11. Ул Һавийә кыздырылган уттыр.**

**(1)** Бу – Кыямәт көне исемнәренең берсе. Ул Кыямәт көнендә булачак һәм кешеләрнең йөрәкләренә дәһшәтле курку салачак олугъ вакыйгалар белән бәйле. Алга таба Аллаһ Тәгалә әлеге көннең мөһимлеген ассызыклый.

**(2-5)** Көчле һәм котычкыч курку сәбәпле, кешеләр ут күбәләгенә яки җир буйлап чәчелгән тынгысыз саранчага охшап калырлар. Ут күбәләге – ул төнлә оча, һәм башка ут күбәләкләре өерендә тәртипсез рәвештә

хәрәкәтләнә торган бөҗәк. Аңы вә гакылы булмау сәбәпле, алар утны күрүгә шунда очалар. Кыямәт көне җитүгә, акыл ияләре булган кешеләр дә шушы гакылсыз бөҗәк халәтендә калырлар. Таулар исә таралган йон шикелле йомшак һәм җиңелгә әверелер. Хәтта җиңелчә генә җил дә аларны күтәреп алып китә алачак, шуңа күрә Аллаһ Тәгалә әйтте: “Син урыннарында таза торалар дип уйлаган тауларны ул көндә күрерсең, болытлар кеби күктә очып йөрерләр” (27:88). Шуннан соң таулар сибелгән туфракка әверелер һәм эссез юкка чыгар. Шул вакытта үлчәү куелыр, ә кешеләр бәхетлеләргә һәм бәхетсезләргә бүленер.

**(6-9)** Әгәр үлчәүнең изге эшләр тәлинкәсе гөнаһлы гәмәлләр тәлинкәсеннән авыррак булса, мондый кеше Җәннәт бакчаларында рәхәт чигәчәк. Әгәр дә изгелекләрнең гөнаһ гамәлләр тәлинкәсе авырлыгын басарга көче җитмәсә, бу кешенең барачак урыны Җәһәннәм булачак. “Барачак урын” дигән сүзне аңлату өчен бу аятьтә “умм” (“әни”) дигән гарәп сүзе кулланылган. Бу, әни тәрбиясе кеше тормышының аерылгысыз бер өлеше булган кебек, ут газаплары да гөнаһлы кешеләр яшәешенең аерылгысыз бер өлеше булачак дигәнне аңлата. Менә ни өчен ут газаплары чигүчеләр: “Ий Раббыбыз бездән җәһәннәм ґәзабын алгыл, чөнки аның ґәзабы һәлак итүчедер” (25:65), - дип әйтәчәкләр. Әмма бу сүз шулай ук “Баш миенең тышчасы” дигәнне дә аңлата, шуңа күрә Корьәнгә аңлатма бирүчеләрнең кайберләре гөнаһ әһелләре Җәһәннәмгә башлары белән түбәнгә атылырлар, дип аңлаталар.

**(10)** Аллаһ Тәгалә Җәһәннәмнең олугълыгын ассызыклады һәм алдагы аятьтә аны тасвирлады.

**(11)** Аның кызулыгы бу җирнең ут кызулыгыннан җитмеш мәртәбәгә катырак. Аллаһ безне андый җәзалардан сакласа иде!

## “Әт-Тәкәсур” (Арттыру. Мәккәдә иңгән) сүрәсенең аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!**

**1. Арттыруга хирыслылыгыз сезне читләшдерде** 2. **Каберләргә кергәнчегә хәтле** .3. **Юктыр, тиздән беләчәксез** 4. **Соңыннан Тагын бер юктыр! тиздән беләчәксез** 5. **Юктыр! Әгәр дә сез тәгаен белсәгез иде** 6. **Сез, әлбәттә, җәһәннәмне күрәчәксез.** 7. **Соңыннан тәгаен аны үз күзләрегез күрәчәксез.**8. **Соңыннан сез ул көнне нигмәтләр турында һичшиксез соралачак.**

**(1-2)** Аллаһ Тәгалә колларын, бер Аллаһка гына гыйбадәт кылудан баш тартып, Аңа башка иләһләрне тиңдәш кылганнары, әлеге иләһләрне бер Аллаһка гына тиешле мәхәббәт белән сөйгәннәре өчен шелтә кылды. Дөнья малын күбәйтергә тырышулары кешеләрне Галәмнәрнең Раббысына ихлас гыйбадәт кылудан читкә тайпылдыра. Аллаһ кешеләрнең нәрсә арттырулары хакында тәгаенләми, шуңа күрә бу аятьтә сүз байлык артыннан куучылар ихлас гамәлләрдән тыш нәрсәләрне ярата, нәрсә белән горурлана – барысы да, бөтен дөнья малы турында да бара: акча, балалар, армия, хезмәтчеләр, җәмгыятьтәге халәт... Әмма дөнья рәхәтлекләре һәм күңел ачулар озакка бармый. Кеше вафат була һәм кабер тормышына күчә. Анда бу кешенең дөньялыкта онытылып йөрүләре юкка чыга, һәм ул үткәннәрне кире кайтара алмый. Әлеге аять бу тормыш белән Мәңгелек тормыш арасында булган барзах тормышы булуы хакында бәян итә. Ул – Мәңгелек тормыш алдыннан килүче тормыш, шуңа күрә Аллаһ кешеләрнең кабергә керүләре, тик анда мәңгелеккә калмаулары хакында хәбәр бирә. Ә янәдән терелтелгәннән соң, алар кылган гамәлләренең әҗерен алачаклар һәм һич тә бетмәс, калдырып та китә алмас мәңгелек тормышка керәчәкләр.

**(3-5)** Әгәр сез үзегезне Мәңгелек тормышта ни көткәнен белсәгез, сезнең йөрәкләрегез уяныр иде! Нәфсегез дә, дөнья малын арттыру теләге дә сезне кызыктырмас иде, һәм сез изге гамәлләр кылырга ашыгыр идегез. Ныклы белемегез булмау сезне җәзага алып киләчәк, һәм бу җәзаны сез үз күзләрегез белән күрәчәксез.

**(6)** Сез янәдән терелүнең шаһитлары булачаксыз һәм имансызлар һәм динсезләр өчен дип әзерләнгән Җәһәннәмне күрәчәксез.

**(7)** Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте: “Гөнаһлы кешеләр утны күргәч, әлбәттә, белерләр анда төшәчәкләрен вә ул уттан котылып барачак җир

тапмаслар” (18:53).

(8) Шуннан соң сез дөньялыкта бүләкләнгән юмартлыклар хакында соралачаксыз. Әгәр алар өчен шөкер итүчеләрдән булып, Аллаһ каршындагы бурычларыгызны үтәгән булсагыз, Ул сезне шул юмартлыкларга караганда да искиткечрәк һәм гүзәлрәк нәрсәләр белән бүләкләр. Әмма әгәр сез дөнья гүзәллекләренә алданып, Раббыгызга шөкер итүчеләрдән булмасагыз, һәм әгәр Ул биргән нигъмәтләрне Аңа каршы килеп гөнаһ гамәлләр өчен куллансагыз, Ул сезне моның өчен җәзалар. Аллаһ Тәгалә әйтте: “Кыямәт көнне кәферләр утка күчерелерләр вә әйтелер: "Сез дөнья тереклегендә Аллаһның, күп нигъмәтләре белән файдаланып әмма Ана гыйбадәт кылмыйча кайбер яхшы эшләрегезнең савабын бетердегез, инде бүген хур рисвай итүче ґәзаб белән җәза ителәсез, җир өстендә хаксыз тәкәбберләнгәнегез һәм чиктән чыгып бозыклык кылганыгыз өчен” (46:20).

## “Әл-гаср” (Гасыр, заман, вакыт. Мәккәдә иңгән) сүрәсенең аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!**

**1. Гасыр белән ант итәмен. 2. Дөреслектә, адәм баласы хәсрәттәдер 3. Иман китереп,изге гамәлләр кылучылардан һәм бер-берсенә хаклык һәм сабырлык белән васыят кылучылардан тыш.**

**(1-3)** Гаср дигән гарәп сүзе көнне һәм төнне билгеләү өчен кулланыла. Моннан шул аңлашыла: Аллаһ Тәгалә, гомумән, вакыт белән ант итә.
Вакыт – ул үлчәү берәмлеге, әлеге үлчәм аралыгында кешеләрнең төрле гамәлләр кылырга мөмкинчелеге бар. Менә ни өчен Аллаһ кешеләрнең табыштан һәм уңыштан коры калып, зыян күрүләрен хәбәр итте. Әлеге зыян авырлыгы буенча төрле дәрәҗәдә булырга мөмкин. Берәүләр бу дөньяда да, вафатларыннан соң да яхшылыктан мәхрүм ителәләр һәм тулаем зыян күрәләр. Мондый гөнаһлы кешеләр Җәннәткә кермиләр,

ә Җәһәннәмгә атылалар. Башкалар өлешчә генә зыян күрә. Шуңа күрә Аллаһ туры юлдан баручылардан тыш башка бар кешеләр дә югалту кичерәчәк, дип хәбәр бирде.
Ә туры юлдан баручылар исә ошбу дүрт сыйфатка ия:
1. Алар Аллаһ иңдергән бар нәрсәгә дә иман китерделәр. Әмма иман гыйлемнән башка була алмый. Гыйлем – иманның мөһим бер өлеше. Гыйлемнән башка иман тулы һәм камил була алмый.
2. Алар изге гамәлләр кылалар. Бу кешенең Аллаһ һәм кешеләр каршындагы бурычларына карый торган тән белән һәм калеб белән кылынучы бөтен мәҗбүри һәм ихтыяри гамәлләргә дә кагыла.
3. Алар кешеләрне иманга һәм изге гамәлләр кылырга чакыралар һәм аларны һәрчак яхшы гамәлләр кылырга рухландырып торалар.
4. Алар кешеләрне Аллаһның кушканнарын сабырлык белән үтәргә, гөнаһлардан ерак булырга һәм кайчак бик авыр һәм ачы булган язмышка сабыр итәргә чакыралар.

Беренче ике күрсәтмәне үтәп, кеше үзен тәрбияли. Соңгы икесен үтәп, ул башка кешеләрне тәрбияли. Әлеге дүрт сыйфатны үзендә камилләштергән кеше генә югалтулардан качып, олугъ бәхеткә ирешә ала.

## “Әл-Һумәзә” (Сүз йөртүче. Мәккәдә иңгән) сүрәсенең аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән.**

1. Үкенеч вә һәлакәтлектер һәрбер яманлап яла ягучыга.2. Кайсысы мал җыеп аны санап торды.3. Малы аны мәңгеләштерер дип уйлый . 4. Юктыр әлбәттә, җәһәннәм утына ыргытылыр. 5. Сиңа ул җәһәннәмне нәрсә белдерде? 6. Ул Аллаһнның кабызылган утыдыр, 7. йөрәкләргә үтеп керәдер. 8. Дөреслектә, аларның өстеннән бикләнгән булыр 9. озын терәүләр белән (терәтелгән булырлар).

(1-3) Аллаһ Тәгалә Үзенең колларын үзенең эше һәм сүзе белән

башкаларны мыскыллап кимсеткән, түбәнсеткән кешеләргә киләчәк зур афәттән һәм каты газаптан кисәткән. “Һүмәзә” (“Хурлаучы, яманлаучы”) дигән гарәп сүзе кешеләрне үз эшләре белән мыскыллаучы яки алардан көлүче, аларга бармак белән төртеп күрсәтүче бөтен кешегә дә кагыла. Ә “лүмәзәһ” («хурлаучы») сүзе башкаларны әшәке сүзләр белән хурлаучыларга кагыла.

Гадәттә, мондый кешеләр байлыкка омтылалар һәм үз рәхәте өчен байлыкларын санарга яраталар, ди Аллаһ. Бу тормышта әлеге шөгыль – аларның бердәнбер мәшәкате. Алар байлыкларын сәдакага һәм изге максатларга тотарга омтылмыйлар һәм фәкыйрьләргә һәм туганнарына ярдәм итәргә теләмиләр. Аларның тырышлыклары һәм омтылышлары бары тик үз байлыкларын күбәйтүгә генә юнәлтелгән, чөнки алар әлеге байлык гомерләрен озынайтыр, дип ышаналар. Алар комсызлык һәм саранлыкның кешеләр тормышын һәм гаиләләрне җимерүен белмиләр. Ә игелекләр сәбәпле, чыннан да, Аллаһ Үзенең колларының гомерләрен озынайта.

(4-7) Җәһәннәм котычкыч һәм дәһшәтле. Аның ягулыгы кешеләр һәм ташлар булачак, ә ялкыны кешеләрнең тәне аша үтеп кереп, йөрәкләрен көйдерәчәк. Аллаһка карышканнар мәңгелек эсселек хөкем сөргән Җәһәннәмгә атылачак, һәм аларның аннан чыгуга һичбер өмете булмаячак.

(8-9) Җәһәннәмнең капкалары, аның әһелләре чыга алмасыннар өчен, озын баганалар белән бикләнгән һәм терәтелгән булачак. Аллаһ Тәгалә әйтте: “Әмма имансыз фасыйкларның торачак урыннары уттыр, һәркайчан алар ул уттан чыгарга теләсәләр, алар ул утка эчкәрәк кайтарылырлар вә аларга әйтелер: үзегез ялганга токтан ут ґәзабын татыгыз, – дип”. (32:20). Раббым, мондый газаплардан коткар, ярлыка һәм сакла!

## **“Әл-Фил” (Фил. Мәккәдә иңгән) сүрәсенең аңлатмасы**

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!**

**1. Рабыңның фил хуҗаларын нишләткәнен күрмәдең мени? 2. Аларның хәйләләрен адашуда калдырмадымы (юкка чыгармадымы)? 3. Алар өстенә төркем-төркем кошлар җибәрде. 4. Кошлар аларга кыздырлган ташлар белән аттылар. 5.һәм аларны ашалган саламдай кылды (бөртеге ашалган, саламы калган игеннәр кебек).**

(1-5) Коръәндә сурәтләнгән әлеге вакыйга Аллаһның кодрәтен иң ачык исбатлаучы вакыйга булып тора. Ул олугъ гамәлләр кыла, Үзенең колларын кызгана, тәүхиднең хак булуына, Үзенең илчесенең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) дөреслегенә кире кагылмаслык дәлилләр китерә. Кәгъбәне җимерергә дип ниятләгән Фил гаскәре белән ниләр булганы хакында уйлан! Җинаять кылучылар әлеге походка яхшылап әзерләнде. Кәгъбәтулланы җимерү өчен алар дәү ана филне әзерләделәр һәм йәмәнлеләрдән һәм хәбәшләрдән торган күпсанлы армия тупладылар. Бу гаскәр шулкадәр куәтле иде ки, гарәпләрнең аңа каршы торырга көчләре җитми иде. Гаскәр изге шәһәргә якынлашуга, Мәккә халкы аларгы каршылык күрсәтмәде. Киләчәк коллык һәм җәбер-золымнан куркып, алар Мәккәне калдырып киттеләр.

Шулвакыт Аллаһ дошманнар өстенә кыздырылган ташлар алып килүче кошлар өерен җибәрде. Алар гаскәр өстенә ташлар яудырды, дошманнырның берсе дә исән калмады.
Кинәт бар нәрсә тынды, ә һәлак булган сугышчылар ашалган бөртеклеләр рәвешенә керде. Шул рәвешле Аллаһ дөньяны яманлыктан, әшәкелектән саклап калды һәм дошманнарның явызлыгын үзләренә үк юнәлдерде. Бу вакыйга һәркемгә яхшы таныш. Фил гаскәре Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) туган елда тар-мар ителде. Әлеге вакыйга исламның килүен алдан хәбәр итте һәм Мөхәммәднең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) пәйгамбәрлек миссиясенең хак булуы хакында белдерде.

## “Корәеш” (Корәеш кабиләсе. Мәккәдә иңгән) сүрәсенең аңлатмасы.

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!**

1. Кураеш кабиләсенең килешүләре (дуслыклары )өчен.2. Аларның җәй һәм кыш көннәрендә сәфәрдәге бердәмлекләре өчен.3. һәм шуңа күрә ошбу йортның (Кәгъбәнең) Раббысына гыйбадәт кылсыннар.4. Ачлыктан соң аларны ашаткан һәм куркудан коткарган өчен.

---

(1-2) Күпчелек тәфсир кылучылар фикеренчә, бу сүрә алда китерелгән сүрәнең мәгънә ягыннан дәвамы булып тора. Бу Аллаһ фил гаскәрен корәеш халкының куркынычсызлыгы һәм иминлеге өчен тар-мар иткән, дигәнне аңлата. Моның белән беррәттән, Аллаһ Тәгалә Мәккә халкына кышын Йәмәнгә, ә җәен Шәмгә барып табышлы һәм файдалы сәүдә эшен оештырырга да ярдәм иткән. Ул аларга каршы золымлык кылырга ниятләүчеләрне һәлак итте, шуның белән Кәгъбәне һәм мәккәлеләрне гарәпләр алдында олылады, югары күтәрде. Гарәпләр мәккәлеләргә тирән хөрмәт белән карыйлар иде һәм аларның сәүдә кәрваннарына бер дә комачау итмиләр иде. Менә ни өчен алга таба Аллаһ аларга, күрсәтелгән мәрхәмәте өчен, шөкер итәргә боерды.

(3-4) Кәгъбәнең Раббысына ширек китермәгез һәм үзегезне Аңа гына гыйбадәт кылуга багышлагыз. Ул сезне дөньядагы иң олугъ нигъмәт – ризык һәм иминлек белән нигъмәтләндерде. Бары шул гына да сезгә Раббыгызга шөкер итүне һәм рәхмәтле булуны йөкли. Аллаһ – һәр нәрсәне халык кылучы, әмма Кәгъбә, башка халык кылынучылар арасында үзенең өстенлеге һәм олугълыгы сәбәпле, аерым урында тора. Раббым, безгә биргән барча нигъмәтләрең өчен мактау сиңа!

## “Әл-Мәгун” ( Мәккәдә иңгән) сүрәсе аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!**

**1. Хисаб һәм җәза көнен, ялганга санаган кешене күрдеңме? 2. Ул ятимне яныннан куар 3. Ач кешене ашатырга өндәми4. Ни үкенеч намаз укучыларга. 5. Алар намазларыннан гафилләр (вакытында**

**укымаслар). 6. Укыган намазларын да рия белән укырлар. 7. Ул тормыш әйберләрен вакытлыча биреп тормас.**

(1-3) Үлгәннән соң торгызылу һәм җәза көнен инкарь иткән, Аллаһның илчеләренә ышанмаган кешеләр хакында уйлан. Үзләренең каты бәгырьле булулары сәбәпле, алар ятимнәрне куалар һәм аларга карата мәрхәмәт күрсәтмиләр. Алар Аллаһтан әҗер алуга өметләнмиләр һәм Аның каты газабыннан курыкмыйлар. Алар кешеләрне фәкыйрь-мескеннәргә сәдака бирергә өндәмиләр, үзләре дә моны эшләмиләр.

(4-5) Биредә сүз намазларына игътибарсыз караган намаз укучылар хакында бара. Вакытында укымау һәм барлык фарызларны да үтәмәү сәбәпле, алар үзләренең намазларын харап итәләр. Моның сәбәбе – Аллаһның кушканнарын игътибарсыз калдырудыр. Алай булмаса, иң мөһим гыйбадәтләрнең берсе булган намазларын юкка чыгармаслар иде. Нәкъ менә үзләренең намазларына карата игътибарсызлыклары сәбәпле алар шелтәләүгә лаек. Намаз укыганда кылынган хаталарга килгәндә, хатаны һәр кеше ясарга мөмкин. Кайвакыт мондый хәл хәтта пәйгамбәребез Мөхәммәд (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) белән дә була иде.

(6-7) Намазларына игътибарсыз караучыларның йөрәкләрендә кызгану хисе юк, алар рияга һәм икейөзлелеккә бирелүчән. Изге гамәлләрне алар башка кешеләр мактасын өчен эшлиләр. Алар кешеләргә кечкенә генә сәдака бирүдән дә баш тарталар, хәтта бу гамәлне кылганнан аларның байлыклары кимемәсе билгеле булса да. Алар, хәтта кешеләр гадәттә бер-берсенә бушлай бирә торган савыт, чиләк яки балта кебек әйберләрне дә бүләк итәргә яки биреп торырга теләмиләр. Чамадан тыш комсызлыклары сәбәпле, алар кечкенә генә сәдәка бирүдән дә баш тарталар. Ә инде кыйммәте зур булган әйберләр хакында сөйләп тә торасы юк. Әлеге сүрәдә Аллаһ Тәгалә мөселманнарны ятим һәм мескеннәрне ашатырга, башкаларны да моңа чакырырга, намазны төзек тотарга, намаз укыганда да, башка төрле гыйбадәт кылганда да Аллаһ каршында ихлас булырга өндәде. Аллаһ Тәгалә шулай ук кешеләрне изгелекләр кылырга, бигрәк тә сүз савыт, чиләк, китап һәм башка шундыйлар турында барса, бушка ярдәм итәргә рухландырды. Изгелекләр эшләргә саранланган һәркем иң кырыс шелтәгә лаек. Ә бу хакта Аллаһ Тәгалә яхшырак белә.

## “Әл-Кәүсәр” (Муллык. Мәккәдә иңгән) сүрәсе аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!**

**1. Без сиңа кәүсәр (күп хәерле нәрсәләр) бирдек. 2. Раббың ризалыгы өчен намаз укы һәм корбан чал! 3. Һичшиксез, сиңа ачу тотучы үзе хәерләрдән мәхрүм ителгән.**

---

(1) Без сине мул һәм олугъ нигъмәтләр белән бүләкләдек, шуларның берсе – Җәннәттәге Кәүсәр елгасы. Без сиңа шулай ук озынлыгы һәм киңлеге бер айлык юл озынлыгына тигез булган сулык бүләк иттек. Аның сулары сөттән ак һәм балдан татлырак. Аның әйләнәсендә савытлар куелган һәм ул савытлар үзләренең саннары һәм ялтыраулары белән күктәге йолдызлардан ким түгел. Әлеге сулыктагы суны авыз итәргә рөхсәт ителгән һәркем, моннан соң һичкайчан сусау кичермәс. Шуннан соң Аллаһ Үзенең илчесенә (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) бу нигъмәтләр өчен рәхмәтле булырга боерды.

(2) Аллаһ Тәгалә намазны һәм корбан чалуны аерып алып күрсәтте, чөнки нәкъ менә бу ике гыйбадәт иң яхшы һәм иң мөһим гыйбадәтләр һәм Аллаһка якынаю чаралары булып тора. Намаз гыйбадәтен башкарып, кеше тәне белән дә, калебе белән дә Аллаһ Тәгалә каршында баш ия, Аңа буйсына һәм тулаем Аңа гына булган гыйбадәткә бирелә. Корбан чалып, кеше Аллаһка сайлап алынган һәм кыйммәтле малы ярдәмендә якыная. Ул корбанны, акчасын Аллаһ ризалыгы өчен сарыф итеп, калебенең байлыкка мәхәббәтен һәм байлык белән аерыласы килмәвен җиңеп чала.

(3) Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) карата нәфрәт кичергән һәм аны хур итәргә, аның абруен төшерергә теләгән кеше, һичшиксез, үзенә генә зыян сала. Аның гамәлләре файдасыз булачак, ә бу кеше хакындагы яхшы фикерләр кешеләр күңеленнән мәңгегә югалачак. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Аллаһның мәхлугы ирешә алырдай хакыйкый камиллеккә иреште. Аның хакында якты истәлекләр, аның артыннан иярүчеләрнең күплеге моңа дәлил булып тора.

## “Әл-Кәфирун” (Кәферләр. Мәккәдә иңгән) сүрәсе аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!**

**1. Әйт: "Ий сез кәферләр, (иман китермәгән кешеләр)! 2. Сез гыйбадәт кыла торган сынымнарга мин гыйбадәт кылмыймын. 3. Һәм сез дә мин гыйбадәт кыла торган Аллаһка гыйбадәт кылмыйсыз. 4. һәм мин сезнең гыйбадәт кыла торган сынымнарыгызга гыйбадәт кылучы түгелмен. 5. һәм сез мин гыйбадәт кыла торган Аллаһка гыйбадәт кылучы түгелсез. 6. Сезгә үз динегез, миңа үз динем!**

**(1-3)** Бу – Аллаһтан башка бүтән иләһләргә табынудан җан белән дә, тән белән дә ваз кичәргә боеру. Әй кәферләр! Сезгә бер Аллаһка гына ихластан табыну ят. Сез кылган йолалар ширек булып тора һәм гыйбадәт дип атала алмый.

**(4-5)** Бу – Аллаһтан башка бүтән иләһләргә табынудан җан белән дә, тән белән дә ваз кичәргә боеру. Әй кәферләр! Сезгә бер Аллаһка гына ихластан табыну ят. Сез кылган йолалар ширек булып тора һәм гыйбадәт дип атала алмый.

**(6)** Аллаһ Тәгалә Үзенең илчесенә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын): “Әгәр алар сине ялганчы дисәләр, әйт: "Миңа үз гамәлем, сезгә дә үз гамәлегез вә сез минем кылган эшемнән бизүчесез, мин дә сез кылган эштән бизүчемен"(10:41), - дип әйтергә кушты.

## “Ән-Нәср” (Ярдәм. Мәдинәдә иңгән) сүрәсе аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!**

**1 Аллаһның ярдәме һәм җиңү килгәч 2. шул вакытта күрерсең кешеләрне, төркем-төркем булып Аллаһ дине Исламга керерләр. 3. Раббыңны мактап тәсбих әйт, һәм Аңардан ярлыкауны сора!**

**Дөреслектә Ул тәүбәне кабул итеп гөнаһларны гафу кылучыдыр.**

(1-3) Аллаһ Тәгалә Үзенең илчесен (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) яхшы хәбәр белән сөендерде һәм Раббысының биргән вәгъдәсе чынга ашкач, нишләргә кирәклеген өйрәтте. Моның белән беррәттән, Аллаһ Тәгалә мөселманнарның игътибарын әлеге вәгъдәгә Үзе сәбәп булачагына юнәлтте. Әлеге сүрәдә телгә алынган яхшы хәбәр – пәйгамбәргә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Аллаһның ярдәм итүе һәм Мәккә шәһәрен алу хакындагы хәбәр ул. Әлеге вакыйгадан соң, кешеләр күпләп ислам динен кабул итә башлыйлар. Аллаһның вәгъдәсе чынга ашты, пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) дошманнарыннан булган кешеләрнең күбесе аның яклы һәм аның ярдәмчеләре булды. Менә ни өчен Аллаһ аңа Раббысына шөкер итәргә, Аны мактарга һәм ярлыкау сорарга боерды.

Әлеге сүрәдә ике галәмәт бар. Беренчедән, Аллаһ Тәгалә җиңү һәрчак Аның дине ягында булачак, ә Аллаһны мактау һәм ярлыкау сорау җиңүгә ирешүне җиңеләйтер, дип вәгъдә бирде. Нәкъ менә шул рәвешле иман китергән бәндәләр Аллаһка рәхмәтле булуларын җиткерә алалар. Аллаһ Тәгалә әйтте: "Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, нигъмәтемне сезгә арттырырмын, әгәр көферлек кылсагыз, минем ґәзабым бик каты" (14:7). Гадел хәлифләр чорында да, аннан соң да хак иман ияләре Аллаһ сүзләренең дөреслеге шаһитлары булдылар. Ислам – күп диннәрнең берсе. Әмма бу хак дингә Аллаһның ярдәме һичкайчан да соңга калмады. Бөтен дөнья буйлап кешеләр исламга килделәр һәм киләләр, һәм мөселманнарның куәте, алар Аллаһ кушканнарга каршы килә башлаганчыга кадәр, нык булды. Менә шул вакытта алар арасында каршылыклар башланды. Әмма ни генә булмасын, мөселман өммәте һәм Аллаһның дине, Аның чиксез, хәтта хыялыбызда да күз алдына китереп булмый торган рәхим-шәфкате астында. Икенчедән, Аллаһ Тәгалә Үзенең илчесенә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) аның бу дөньядагы тормышы ахырына якынлашуы хакында хәбәр бирде. Шуның белән Ул пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) тормышы данлыклы булуын ассызыклады. Аллаһ Тәгалә Үзе дә аның белән ант итте: "Ий Лут, синең гомер белән ант итеп әйтәбез, алар шәһвәт исереклеге белән хәйран калып йөриләр, синең нәсыйхәтеңне ишетмәсләр"(15:72).

Аллаһ Тәгалә барлык иман әһелләренә дә бу тормыштагы гомерләрен намаз вакытларында, олы хаж һәм башка шундый гамәлләр кылганда ярлыкау сорау белән тәмамларга васыять итте. Менә ни өчен Аллаһның Аны мактарга һәм ярлыкау сорарга боеруы пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) озакламастан вафат булачагына ишарәли иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Үзенең Раббысы белән очрашуга әзерләнергә һәм үзенең гомерен иң күркәм рәвештә төгәлләргә күрсәтмә алды. Ул иңдерелгән бу вәхийгә буйсынды һәм үлем сәгате килгәнче намаз вакытларында Раббысына дога белән мөрәҗәгать итте:

سُبْحَانَكَ اللَّهُمَّ رَبَّنَا وَبِحَمْدِكَ، اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِي

«Аллаһ, Раббыбыз! Син пакь, һәм мактау Сиңа! Аллаһ, ярлыка мине!» Бу сүзләрне ул бигрәк тә рөкугъ һәм сәҗдә вакытларында кабатлый иде.

## “Әл-Мәсәд (Бау. Мәккәдә иңгән) сүрәсе аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!**

**1. Әбү Ләһәбнең ике кулы корысын һәм һәлак булсын! 2. Аңа ґәзабтан котылырга малы һәм кәсеп иткән нәрсәләре һич файда бирмәде. 3. Тиздән ул Әбү Ләһәб ялкынлы утка кереп янар. 4. хатыны да утка керер утын күтәргән хәлдә. 5. Ул хатынның муенында хөрмә мунчаласыннан булган бау булачак.**

(1-5) Әбу Ләхәб Мөхәммәд пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әтисе ягыннан абыйсы иде. Ул пәйгамбәребезгә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) карата көчле нәфрәт утында яна иде һәм аңа күп җәфа-газаплар китерә иде. Әбу Ләхәб имансыз булды һәм туганлык җепләрен сакларга омтылмады. Аллаһ аны бу гамәле өчен кырыс хөкем итте һәм аны Кыямәт көненәчә рисвай итте. Әбу Ләхәбнең ике кулы да корысын! Ул мескен һәм аңа бернәрсә дә файда китерә алмас. Байлык аны бозыклыкка кертте, әмма гадел җәзадан коткарып калмады. Аңарга гадел җәза килгәч, аны бернәрсә дә саклап кала алмас. Җәһәннәм уты аны һәрьяклап камап алыр, ә аның хатыны бу ут өчен утын

ташыячак. Ул да Аллаһның илчесенә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) ачы газаплар китерә  һәм үзенең иренә гөнаһлар эшләргә һәм Аллаһ һәм Аның диненә каршы көрәштә ярдәм итә иде. Ул да пәйгамбәребезгә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) ялалар яга иде һәм бар көченә аңа зыян китерергә тырыша иде. Җәһәннәмдә ул кешеләр, муеннарына пальма җепселләреннән ишелгән бау тагып, аркаларында утын ташыган кебек, үз гөнаһларының авырлыгын тоячак. Башка аңлатмада исә, ул, муенына пальма җепселләреннән ишелгән бау тагып, үзенең ире өчен утын җыячак, диелә. Бу сүрәдә Аллаһның иң зур, иң бөек галәмәтләренең берсе сурәтләнә.

## “Әл-Ихлас” ( Мәккәдә иңгән) сүрәсе аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!**

**1. Әйт: "Ул – Аллаһ һич, тиңдәше һәм охшашы булмаган ялгыз бер генә 2. Һичнәрсәгә, һичбер мәхлукка ихтыяҗы юк бәлки һәр мәхлукның хаҗәтен үтәүче Аллаһдыр. 3. Ул һичкемне тудырмады һәм һичкемнән тудырылмады. 4. һәм һичкем Аңа тиң булмады.**

(1-4) Аллаһ Тәгалә бу сүзләрне аларның хаклыгына ныклы ышану һәм тулы иман белән әйтергә боерды. Моны эшләр өчен кеше бу сүзләрнең хак мәгънәсен белергә тиеш. Аллаһ – Бердәнбер иләһ. Аның күркәм исем-сыйфатлары камил, Аның гамәлләре изге һәм кимчелексез, һәм Аңа охшаган яки Аңа тиң булган бер генә зат та юк. Аның бер мәхлукка да ихтыяҗы юк, һәм күкләрдә вә җирдә яшәүчеләр Аңарга югары дәрәҗәдә мохтаҗ һәм Аңардан ярдәм сорыйлар, чөнки аның барлык сыйфатлары да камил. Ул бар нәрсәдән хәбәрдар, һәм Аның гыйлеме чиксез. Ул сабыр, һәм Аның сабырлыгы чиксез. Ул рәхимле, шәфкатьле, һәм Аның рәхим-шәфкате һәр нәрсәне чолгый. Аллаһның башка сыйфатларына килгәндәдә шулай. Аллаһның камиллеге шунда да күренә: ул тудырмады һәм тумады, шуңа күрә һичкемдә һәм һичнәрсәдә мохтаҗлык кичерми. Аның исемнәре, сыйфатлары һәм гамәлләре мәхлукларның исемнәре, сыфатлары һәм гамәлләренә караганда бик күпкә өстенрәк.

Ул – Бөек һәм Күркәм. Шулай итеп, әлеге сүрә тулаем Аллаһның гына иләһи исемнәре һәм сыйфатлары бар дигән тәгълиматны үз эченә ала.

## “Әл-Фәләкъ” (Таң. Мәккәдә иңгән) сүрәсе аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!**

**1. Әйт: "Мин таңның Раббысына сыенамын 2. Ул яралткан нәрсәләрнең зарарыннан. 3. һәм караңгы төннең зарарыннан 4. төеннәренә өрүче сихерче хатыннар явызлыгыннан, зарарыннан сыгынамын. 5. Һәм көнләшүченең көнләшкән чагындагы зарарыннан”.**

(1-5) “Фәләка” (“Яру”) дигән гарәп фигыле, таң җиткәч, нәкъ менә Аллаһ Тәгалә төнге караңгылыкны яруы, шулай ук шытып чыккан вакытларында орлыкларны нәкъ менә Аллаһ Тәгалә яруы хакында ассызыклый. Үзенең колларын кешеләрнең, җеннәрнең, хайваннарның һәм башка мәхлукларның  явызлыгыннан һәм әшәкелегеннән Бары Ул гына  саклый ала. Аллаһ Тәгалә кайбер мәхлукларның күп явызлык алып килүләре хакында әйтте. Төнлә кешеләрне йокы баса, ә җир өстеннән явыз рухлар һәм зыян салучы җанварлар йөри. Сихерче хатыннар кешеләргә бозым салу өчен төеннәргә өрәләр. Ә көнчеләр кешеләр нигъмәтләрен югалтсыннар иде дип телиләр һәм моңа күп көч куялар. Кешеләрне мөртәтләрнең явызлыгыннан сакларга һәм аларның мәкерлекләрен бетерергә бары тик Аллаһ кына булдыра ала, һәм шуңа күрә һәр кеше Аның саклавы астына сыеныргa тиеш.  Көнче кешеләргә шулай ук яман күзле кешеләр дә керә, чөнки күзне бары тик яман холыклы һәм бозык күңелле көнче кеше генә тидерә ала. Шулай итеп, әлеге сүрә мөселманнарны сыену урынын һәм явызлыктан котылуны Аллаһтан эзләргә өйрәтә. Ул шулай ук сихерчелекнең бар икәнлегенә һәм аның зыяныннан, сихерчеләрнең мәкерлекләреннән Аллаһка сыенып, сакланырга кирәклеккә дәлил булып тора.

## “Ән-Нәс” (Кешеләр. Мәдинәдә иңгән) сүрәсе аңлатмасы

**Рәхмәтле һәм Рәхимле булган Аллаһның исеме белән!**

**1. Әйт: "Кешеләрнең Раббысына сыенамын. 2. Кешеләрнең патшасы булган Аллаһка сыенамын 3. Кешеләрнең гыйбадәт кыла торган Илаһәсе булган Аллаһка сыенамын. 4. сәваблы эштән тыеп, гөнаһлы эшкә өндәп вәсвәсә кылучы шайтанның зарарыннан. 5. Ул шайтан кешеләрнең күңеленә явызлыкны саладыр. 6. Ул жennәрдән дә һәм кешеләрдән дә бардыр.**

(1-6) Әлеге сүрәдә мөселманнарга бөтен явызлыкның башында торучы иблистән саклану өчен барлык кешеләрнең Патшасы һәм Аллаһысы булган Аллаһ Тәгаләгә сыенырга боерыла. Иблис кешеләрне вәсвәсәгә сала, аларның күзләренә явызлыкны һәм гөнаһны матурлап күрсәтә һәм кешеләрдә гөнаһ эшләү теләге уята. Шуның белән берррәттән, ул аларга изгелек кылырга комачау итә һәм изгелекне ямьсезләп күрсәтә. Иблис бертуктаусыз кешеләрне вәсвәсәгә сала, әмма Аллаһның колы үзенең Раббысын искә төшереп, бу дошман белән көрәштә Аннан ярдәм сорап дога кылса, ул чигенә һәм юкка чыга. Менә ни өчен иман ияләре бары тик кешеләр һәм башка мәхлукларның Аңарга гына гыйбадәт кылу өчен яратылган Хакименә ярдәм сорап сыенырга тиешләр. Кешеләр, үзләрен барлык нигъмәтләрдән кисәргә, алар арасына кереп үз фиркасына авыштырырга һәм Җәһәннәм әһелләре ясарга теләүче бу дошманнан котылмыйча торып, бәхеткә ирешә алмаслар. Әмма истә тотарга кирәк: Иблис тәэсирендә генә түгел, кешеләр тәэсирендә дә коткыга бирелергә мөмкинсең. Гамәлләребезнең башында һәм ахырында Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһ Тәгаләгә барча мактаулар булсын!

## Кереш өлеш һәм сүрәләрнең аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар.

***1. Ни өчен без “Мөһим дәресләр”не өйрәнергә тиешбез?***

- Чөнки алар мөһим;
- Галимнәр өйрәнү өчен нәкъ менә бу китапны киңәш итәләр;
- Әлеге китапта һәр мөселман өчен мөһим булган гыйлемнәр тупланган;
- Бөтен вариантлар да дөрес.

***2. “Мөһим дәресләр” үз эченә нәрсәләрне ала?***

- Мөселманнарның Коръәнгә һәм Тәүхидкә мөнәсәбәтләрен;
- Намаз һәм тәһарәт белән бәйле мәсьәләләрне аңлатуны;
- Әхлаклы булу һәм ислам этикетын үтәүне;
- Ширектән һәм гөнаһлардан кисәтүне ;
- Мәетне җирләргә әзерләүне, шулай ук җеназа намазы мәсьәләләрен;
- Бөтен вариантлар да дөрес.

***4. Мөселман кешесе гыйлем алуны кайсы сүрәне дөрес итеп укырга өйрәнүдән, аның мәгънәсенә төшенүдән башларга һәм аны белергә тиеш?***

- “Әл-Галәк” (Оеш кан) сүрәсеннән;
- “Әл-Фатиха” (Ачучы) сүрәсеннән;

- “Әл-Ихлас” сүрәсеннән.

***5. Гыйлем эзләүчегә Коръәнгә аңлатма бирүче китапларның кайсысыннан башларга?***

- Ибн Кәсир аңлатмасыннан;
- Әл-Куртуби аңлатмасыннан;
- Габдрахман ибн Насыйр Әс-Саади аңлатмасыннан.

***6. Кешеләр, Коръәнгә карашлары буенча, өч төркемгә бүленделәр.***

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

***7. Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Коръәнне аның мәгънәләре хакында фикерләмичә һәм аңа муафыйкъ рәвештә гамәл кылмыйча гына укудан тыйды.***

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

## “Әл-Фатиха” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

8. ***“Әл-Фатиха” (Ачучы) сүрәсенең шул исем белән аталуның сәбәбе нинди [2]?***

______________________________________________________________

______________________________________________________________

***9. “Әл-Фатиха” сүрәсенең исемнәре арасыннан:***

- Коръәннең анасы;
- Җиде аять;
- Өшкерү (рукъя);
- Дога;

- Бөтен вариантлар да дөрес

***10. Раббыбызның “Аллаһ” исеме нәрсәне аңлата?***

- Иләһләштерелгән һәм табына торган Иләһ;

- Үзенең камил һәм саф иләһи сыйфатлары сәбәпле табынырга лаек булган Бердәнбер Иләһ;

- Бөтен вариантлар да дөрес.

***11. Аллаһ Тәгаләнең хакимлеге була:***

- Гомуми; - Шәхси; - Бөтен вариантлар да дөрес.

***12. Аллаһ Тәгаләгә дога белән мөрәҗәгать иткәндә пәйгамбәрләр ешрак ничек мөрәҗәгать иткәннәр?***

- Йә Аллаһ; - Йә Раббым.

***13. Гарәп теленең грамматикасы нигезендә, әгәр алмашлык фигыль алдыннан килсә бу:***

- Эш-хәрәкәт бары тик телгә алынган затка мөнәсәбәтле рәвештә генә үтәлә дигәнне аңлата;

- Эш хәрәкәт һичнинди чикләүләрсез барлык затларга мөнәсәбәтле рәвештә үтәлә дигәнне аңлата.

***14. “Сиңа гына гыйбәдәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз”аятендә гыйбадәт кылуның ярдәм сорауга караганда алданрак телгә алынуы нәрсәне аңлата?***

- Бу шәхсине гомумигә кертүнең мисалы;

- Аллаһ Тәгаләнең хакы, Аның колларының хакына караганда

өстенрәк булуын;

- Бөтен вариантлар да дөрес.

***15. Гыйбадәт – ул:***

- Калеб белән дә, тән белән дә кылына торган Аллаһ сөйгән һәм хуплаган барлык сүзләрне һәм гамәлләрне үз эченә алган төшенчә;

- Аллаһка Аның кушканнарын үтәү һәм тыйганнарыннан тыелу ярдәмендә (ә болар Аллаһка мәхәббәт белән һәм Аны олугълау белән бергә үрелеп бара) тулы буйсынучанлык;

- Кайчагында күз уңында беренче билгеләмә, ә кайчагында икенчесе тотыла.

***16. “Җәза көне” - ул:***

- Кубарылу көне;

- Кешеләргә гамәлләре өчен җәза билгеләнәчәк көн;

- Бөтен вариантлар да дөрес.

***17. “Син безне туры юлга бастыр” догасы Ислам динендә мәгънәсе буенча иң тирән, файдалы һәм һәрьяклы догаларның берсе.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***18. Түбәндәге сүрәләрнең кайсысы Коръәндәге бүтән бер генә сүрәдә дә, бер генә аятьтә дә булмаган мәгънәләрне үз эченә алган?***

- “Әл-Фатиха” сүрәсе;

- “Аятелкөрси”;

- “Әл-Ихлас” сүрәсе.

## “Аятелкөрси”нең аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

***19. Көрси телгә алынганга күрә бу аять шулай атала.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***20. Коръән аятьләренең кайсысы иң бөеге?***

- Ун вазифа турындагы аять; - “Аятелкөрси”.

***21. Бу аятьтә Аллаһның ничә күркәм исем-сыйфаты бәян кылынган?***

- Биш; - Алты; -Җиде.

***22. Аллаһ Тәгалә Үзеннән кире каккан һәм Пәйгамбәребез дә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Аннан кире каккан исем-сыйфатларны инкарь иткән вакытта, Аллаһ Тәгаләнең тулыканлы, капма-каршы сыйфатларын танырга һәм Аны шул исем-сыйфатлар белән тасвирларга кирәк. Мәсәлән, Аллаһ Тәгалә Үзеннән “йокы”, “йокымсырау” кебек сыйфатларны кире каккан һәм Үзен әлеге сыйфатларга капма-каршы булган “тере” һәм “кодрәт иясе” сыйфатлары белән тасвирлаган.***

- Дөрес; - Дөрес түгел

***23. Аллаһ Тәгалә Үзе риза булган бәндәләре өчен генә шәфәгать***

***сорап мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек бирә, ә Аллаһ:***

- Тәүһид әһелләреннән генә риза;

- Пәйгамбәрләр юлыннан баручылардан риза;

- Бөтен вариантлар да дөрес.

***24: Аллаһ Тәгалә мәхлукларга өйрәткән дин кануннары һәм галәм законнары:***

- Аз санлы; - Күп санлы.

***25. Аллаһның "Иң өстенлекле" дигән исеме нәрсәне аңлата?***

- Ул Үзенең асылы белән мәхлуклардан өстен тора;

- Аның сыйфатлары өстенлек белән куәтләнгән;

- Аның өстенлегенә барлык мәхлуклар да буйсына;

- Бөтен вариантлар да дөрес.

***26. "Аятелкөрси" кайчан укыла:***

- Һәр фарыз намазыннан соң; - Йоклар алдыннан;

- Иртән һәм кичен; - Бөтен вариантлар да дөрес.

**"Әз-Зәлзәлә" (Җир селкенү) сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

***27. "Әз-Зәлзәлә" сүрәсе кайда иңгән?***

- Мәккәдә; - Мәдинәдә.

***28. "Әз-Зәлзәлә" сүрәсе үз эченә нәрсәләрне ала?***

- Изгелекләр эшләргә өндәүне; - Гөнаһлардан качарга өндәүне;

- Бөтен вариантлар да дөрес.

**29**. ***Аллаһның: “Җир үзенең тетрәүе белән тетрәгәч” дигән сүзләре Аның: “Ул бөтен җирне тигезләр, анда син калкулыклар да, иңкүлекләр дә күрмәссең” дигән сүзләренә тиңме?***

- Әйе; - Юк.

**30.** ***Аллаһның: “һәм җир үзенең эчендәге йөкләрне чыгарса” аятендә сүз нәрсә хакында бара?***

- Таулар һәм калкулыклар; - Мәетләр һәм күмелгән байлыклар.

**31**. ***Җир галәмнәрдә яшәгән барча мәхлукның яхшы һәм яман эшләре хакында сөйләрме?***

- Әйе; - Юк.

**32**. ***Аллаһ Тәгалә әйтте: “Ул көндә кешеләр төрле төркемнәргә бүленеп барырлар” – бу сүзләр нәрсәне аңлата?***

- Һәр кеше җыйналу урынына аерым-аерым барачак;

- Кешеләр аерым төркемнәргә бүленәчәк һәм җыйналу урынына төркем-төркем булып барачак.

**33**. ***Аллаһның: “Берәү тузан бөртеге хәтле генә яхшылык кылган булса, аны күрәчәк. Һәм берәү тузан бөртеге хәтле гөнаһ эшләсә, аның җәзасын күрер”, - дигән сүзләре Аның: “Һәм бөтен кылганнарын каршыларында табарлар”(18:49), - дигән сүзләренә тиңме?***

- Әйе; - Юк.

## “Әл-Гадият” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

***34. “Әл-Гадият” сүрәсе кайда иңгән?***

- Мәккәдә; - Мәдинәдә.

***35. “Әл-Гадият” сүрәсе үз эченә вазифаларны үтәмәүдән кисәтүне алган.***

- Дөрес; - Дөрес түгел

***36. Әлеге сүрәдәге сүзләрнең мәгънәләрен аңлат:***

ضَبْحًا ____________________________________________

قَدْحًا ____________________________________________

نَقْعًا ____________________________________________

لَكَنُودٌ ____________________________________________

## “Әл-Карига” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

***37. “Әл-Карига” сүрәсе кайда иңгән?***

- Мәккәдә; - Мәдинәдә.

***38. “Әл-Карига” сүрәсенең мәгънәләре арасыннан нинди кисәтүне аерып карарга мөмкин?***

- Кыямәт көненең котычкычлыгы хакында;

- Кеше тормышындагы сынаулар турында.

***39 “Әл-Карига” нәрсәне аңлата?***

- Үлгәннән соң кубарылу көне; - Куркыту.

**40**. ***Әлеге гыйбарәләрнең мәгънәләрен аңлат:***

“тузылган (таралаган) вак күбәләкләр кебек булырлар”:

___

“тетелгән йон кебек булырлар”:

___

***41. Әлеге сүрәдә телгә алынган үлчәү – ул:***

- Чын үлчәү, туры мәгънәдә килә;

- “Үлчәү” сүзе астында гаделлек күз алдында тотыла.

***42. “Рәхәт тормышка ирешәчәк”:***

- Бу дөньяда; - Җәннәт бакчаларында.

***43. Аллаһның: “Аның анасы – мәрхәмәтсез булган Һавийә исемле җәһәннәм аңа урын булыр” сүзләре нәрсәне аңлата?***

- әни тәрбиясе кеше тормышының аерылгысыз бер өлеше булган кебек, ут газаплары да гөнаһлы кешеләр яшәешенең аерылгысыз бер өлеше булачак;

- Гөнаһ әһелләре Җәһәннәмгә башлары белән түбәнгә атылырлар;

- Бөтен вариантлар да дөрес.

44. “**Ул һавийәнең нәрсә икәнен сиңа нәрсә белдерде?**”, - сүзләре белән Аллаһ Тәгалә нәрсә әйтергә теләде?

- Җәһәннәмнең олугълыгын ассызыклады;

- Җәһәннәм турында сорарга теләде.

***45. Җәһәннәм утының исемнәре арасында түбәндәгеләр бар:***

- Упкын;
- Тәмуг;
- Җимергеч ут;
- Җәһәннәм уты;
- Бөтен вариантлар да дөрес.

***46. Җәһәннәм утының (Аллаһтан аннан сыену сорыйбыз) кызулыгы бу җирнең ут кызуыннан ничә мәртәбәгә катырак?***

- Җитмеш мәртәбәгә;
- Туксан мәртәбәгә;
- Туксан тугыз мәртәбәгә.

## “Әт-Тәкәсур” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

***47. “Әт-Тәкәсур” сүрәсе кайда иңгән?***

- Мәккәдә;
- Мәдинәдә.

***48. “Әт-Тәкәсур” сүрәсе үз эченә нәрсәләрне алган?***

- Кешеләрнең халәтләре хакында яңалыкларны;

- Галәмнәрнең Раббысына ихлас гыйбадәт кылудан читкә тайпылып, башка эшләр белән мәшгуль булулары өчен кешеләргә белдерелгән шелтәне.

***49. Әлеге сүрәдә һәр нәрсәдә, хәтта изгелекләр эшләүдә һәм Аллаһ белән якынаюга омтылуда да, арттыруга һәвәслекне тыю бар.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***50. Ни өчен Аллаһ Тәгалә: “Каберләрегездә мәңгегә калганчыга кадәр”, - дип түгел, ә “Хәттә үлеп кабергә кергәнегезгә хәтле”, - диде?***

- Чөнки “Барзах” – ул Мәңгелек тормыш алдыннан килүче вакытлыча тору урыны;

- Чөнки мәетләр бу дөньядагы үз йортларыннан аларның милке булмаган зиратларга күченделәр.

## “Әл-гаср” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

***51. “Әл-гаср” сүрәсе кайда иңгән?***

- Мәккәдә; - Мәдинәдә.

***52. “Әл-гаср” сүрәсендә дүрт мәсьәләгә: гыйлем, гамәл, чакыру һәм сабырлыкка дәлил бар.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***53. Аллаһ тарафыннан ант итүгә бәйләнмәгән әлеге фикерләрнең кайсысы дөрес?***

- Аллаһ Үзенең мәхлуклары арасыннан кайсысы белән тели, шунысы белән ант итә ала;

- Аллаһның колларына Аллаһтан тыш һичкем һәм һичнәрсә белән дә ант итәргә ярамый;

- Аллаһның коллары Аллаһтан тыш теләсә-кем белән ант итә алалар;

- Беренче һәм икенче фикер генә дөрес.

***54. Сабырлык бүленә:***

- Ике төргә; - Өч төргә; - Дүрт төргә.

***55. Әлеге сүрәдә дүрт күрсәтмә бар. Шуларның беренче икесен үтәп, кеше үзен тәрбияли, ә соңгы икесен үтәп, ул башкаларны тәрбияли.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

## “Әл-Һумәзә” (Сүз йөртүче) сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

***56. “Әл-Һумәзә” сүрәсе кайда иңгән?***

- Мәккәдә; - Мәдинәдә.

***57. Хурлаучы, яманлаучы (“һүмәзә”) – ул кешеләрне үз эшләре белән мыскыллаучы яки алардан көлүче, аларга бармак белән төртеп күрсәтүче, башкаларны әшәке сүзләр белән хурлаучы.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***58. Аллаһ Үзенең колларының гомерләрен озынайтуга алар кылган изгелекләр сәбәп буламы?***

- Әйе; - Юк.

***59. Җәһәннәм утының ягулыгы булып торалар:***

- Кешеләр; - Ташлар; - Бөтен вариантлар да дөрес.

***60. Аллаһ Тәгаләнең “Ул ут йөрәккә төшәр”, - дигән сүзләре, ялкын кешеләрнең тәне аша үтеп кереп, йөрәкләрен***

***көйдерәчәк, дигәнне аңлата.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

**“Әл-Фил” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен *сораулар***

***61. “Әл-Фил” сүрәсе кайда иңгән?***

- Мәккәдә; - Мәдинәдә.

***62. Әлеге сүрәдән алырга мөмкин булган гыйбрәтле дәресләрнең берсе шул – зур гәүдәле хайван Аллаһ йортларының берсенә карата чикләрне бозарга курка, бу очракта кешеләр дә беренче чиратта шуннан куркырга тиешләр.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***63. Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) кайсы елда туды?***

- Фил вакыйгасы елында; - Кайгы елында; - Көл елында.

***64. Бу вакыйга исламның килүен алдан хәбәр итте һәм Мөхәммәднең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) пәйгамбәрлек миссиясенең хак булуы хакында белдерде.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

**“Корәеш” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

***65. “Корәеш” сүрәсе кайда иңгән?***

- Мәккәдә; - Мәдинәдә

.

***66. Бу сүрә кайсы сүрә белән бәйләнгән?***

- “Әл-Фил” ; - “Әл-Кәфирун” ;
- “Ән-Нәс”.

***67. Корәеш кабиләсе кышын Шәмгә, ә җәен Йәмәнгә барып табышлы һәм файдалы сәүдә эшен оештыралар.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***68. Аллаһ Тәгалә Кәгъбәне һәм Харам мәчетен, шулай ук мәккәлеләрне гарәпләр алдында шулкадәр олылады, югары күтәрде ки, гарәпләр аларга хөрмәт белән карый башладылар һәм һөҗүм итәргә кыймадылар:***

- Мәккә шәһәрендә; - Мәккә шәһәрендә дә, шулай ук башка җирдә дә.

***69. Аллаһ – һәр нәрсәне халык кылучы, әмма Кәгъбә башка халык кылынучылар арасында үзенең өстенлеге һәм олугълыгы сәбәпле, аерым урында тора.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***70. “Әлеге йортның Раббысына гыйбадәт кылсыннар” – әлеге аятьтә, ихтирамга лаек икәнен күрсәтү максатыннан, мәхлук Раббысына бәйле рәвештә килә.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

**“Әл-Мәгун” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

***71. “Әл-Мәгун” сүрәсе кайда иңгән?***

- Мәккәдә; - Мәдинәдә.

***72. Аллаһның “Хисаб һәм җәза көнен, ялганга санаган кешене күрдеңме?” сүзләрендәге “Җәза көне” “Үлгәннән соң кубарылу” дигәнне аңлата.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***73. Ятим– ул:***

- Әтисез калган бала; - Әнисез калган бала.

***74. Ул ятим булып атала:***

- Женси җитлеккәнче; - Хәтта женси җитлеккәч тә.

***75. Намазга карата игътибарсызлык – нәкъ менә шул шелтәләүгә лаек, ә хаталарга килгәндә, аны һәр кеше ясарга мөмкин.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***76. Рия, изгелекне күрсәтеп эшләү:***

- Рөхсәт ителә; - Шелтәләнә; - Тыела;
- Ул кече ширек; - Ул зур ширек.

***77. Әлеге сүрәдә хуплана торган изгелекләр эшләргә теләк уяту бар.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

## “Әл-Кәүсәр” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү

**өчен сораулар**

***78. “Әл-Кәүсәр” сүрәсе кайда иңгән?***

- Мәккәдә;
- Мәдинәдә.

***79. Әл-Кәүсәр - ул:***

- Елга;
- Нигъмәтләрнең муллыгы;

***80. Аллаһ Тәгалә намазны һәм корбан чалуны аерып алып күрсәтте, чөнки нәкъ менә бу ике гыйбадәт иң яхшы һәм иң мөһим гыйбадәтләр һәм Аллаһка якынаю чаралары булып тора.***

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

***81. Аллаһның: “Тәхкыйк, сине әбетәр дип кимсетүче дошманың үзе әбетәрдер – нәселе бетүчедер” дигән сүзләре пәйгамбәребезне (Аллаһның аңа рәхмәте вә сәламе булсын) яраткан кеше хакында якты истәлекләр сакланыр дигәнне аңлата.***

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

***82. Бу сүрәдә Аллаһ илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) артыннан иярүчеләрнең күплегенә ишарә бар.***

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**“Әл-Кәфирун” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

***83. Бу сүрә кайда иңгән?***

- Мәккәдә;
- Мәдинәдә.

***84. “Әл-Кәфирун” сүрәсен беренче рәкәгатьтә “Фатиха” сүрәсеннән соң уку яхшырак:***

- Иртәнге намаз алдыннан укылучы мөстәхәб (хәерле, саваплы) намазда;
- Ахшам намазыннан соң укылучы мөстәхәб (хәерле, саваплы) намазда;
- Кәгъбә тирәли тәваф кылганнан соң укыла торган намазда;
- Витр намазында;
- Бөтен вариантлар да дөрес.

***85. Ширек катышкан гыйбадәт:***

- Тулыканлы гыйбадәт түгел;
- Гыйбадәт дип аталмый

***86. Аллаһ “Әйт” дигән сүз белән кемгә мөрәҗәгать итә?***

- Аллаһның илчесенә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын);

- Аллаһның илчесенә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын), шулай ук мөрәҗәгать итәргә мөмкин булган бар кешегә .

***87. Кәферләр – алар:***

- Аллаһның илчесенең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) чакыруы ирешеп тә, аңа иман китермәгән кешеләр;

- Аллаһның илчесенә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) иман китермәгән Мәккә халкы.

***88. Бу сүрәдә йөрәктә, телдә һәм тән әгъзаларында чагылыш***

***тапкан ширеккә һәм кәферләргә катнашмаганлык бар.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

## “Ән-Нәср” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

***89. Бу сүрә кайда иңгән?***

- Мәккәдә; - Мәдинәдә.

***90. Әлеге сүрәдә шатлыклы хәбәр, фәрман һәм игътибарны җәлеп итү бар.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***91. Бу дингә һәм бу өммәткә Аллаһның рәхим-шәфкате шулкадәр зур ки, безгә аны хәтта күз алдына китерү дә кыен.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***92. Бу сүрәдә Аллаһның илчесенең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) бу дөньядагы тормышы ахырына якынлашуы хакында хәбәр бар.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

## “Әл-Мәсәд сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

***93. Бу сүрә кайда иңгән?***

- Мәккәдә; - Мәдинәдә.

***94. Әбу Ләхәб - ул:***

- Пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) этисе ягыннан абыйсы;

- Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) белән аны бернинди туганлык җепләре дә бәйләми.

***95. Кыямәт көненәчә рисвай кылынды:***

- Әбу Ләхәб;

- Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) белән дошманлашкан һәркем.

***96. Бу сүрәдә Аллаһ Тәгалә Әбу Ләхәбнең һәм аның хатынының беркайчан да исламны кабул итмәячәкләре хакында алдан әйтте.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

## “Әл-Ихлас” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

***97. Бу сүрә кайда иңгән?***

- Мәккәдә; - Мәдинәдә.

***98. “Әл-Ихлас” сүрәсе шулай дип аталган, чөнки:***

- Ул башка нәрсәләргә түгел, ә тулаем Аллаһны тасвирлауга багышланган;

- Аны укыган кеше ширектән чистара;

- Бөтен вариантлар да дөрес.

***99. Әлеге сүрәне укыган өчен билгеләнгән әҗер:***

- Ярты Коръәнне укыганга тиң;

- Чирек Коръәнне укыганга тиң;

- Коръәннең өчтән бер өлешен укыганга тиң.

***100. “Әл-Ихлас” сүрәсен икенче рәкәгатьтә “Фатиха” сүрәсеннән соң уку яхшырак:***

- Иртәнге намаз алдыннан укылучы мөстәхәб (хәерле, саваплы) намазда;

- Ахшам намазыннан соң укылучы мөстәхәб (хәерле, саваплы) намазда;

- Кәгъбә тирәли тәваф кылганнан соң укыла торган намазда;

- Витр намазында;

-Фарыз намазларыннан соң;

- Бөтен вариантлар да дөрес.

***101. “Әл-Кәфирун” һәм “Әл-Ихлас” сүрәләре көндез һәм төнлә укыла, чөнки аларда тәүхиднең өч төре дә бар.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***102. “Әл-Ихлас” сүрәсендә:***

- Аллаһны иләһлетә (табыну хокукында) берләү;

- Аллаһны Раббылыкта, шулай ук иләһи исемнәрендә һәм сыйфатларында берләү чагылыш тапкан.

***103. Аллаһның “Әйт” дигән сүзләре түбәндәге мәгънәдә килә:***

- Телең белән әйт;

- Телең белән әйт, йөрәгең белән инан, һәм шуңа муафыйк рәвештә гамәл кыл.

***104. Аллаһның “Ул - Аллаһ һич, тиңдәше вә охшашы булмаган ялгыз бер генә Аллаһудыр” дигән сүзләре Аллаһны раббылыкта, иләһлектә, шулай ук исем һәм сыйфатларында берләү ул.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

***105. Аллаһның “Һичнәрсәгә, һичбер мәхлукка ихтыяҗы юк” дигән сыйфаты түбәндәге мәгънәгә ия:***

- Мохтаҗ вакытта Аңарга юнәлә һәм мөрәҗәгать итә торган Зат;
- Бер мәхлукка да ихтыяҗы булмаган, ә күкләрдә вә җирдә яшәүчеләр Аңарга югары дәрәҗәдә мохтаҗ булган Зат;
- Иләһлеге, исем һәм сыйфатлары камил булган кебек, Раббылыгы да камил һәм тулыканлы булган Зат;
- Бөтен вариантлар да дөрес.

***106. Аллаһ Тәгаләнең әти-әнисе яки баласы бар дип әйтү зур ширек була.***

- Дөрес; - Дөрес түгел.

**“Әл-Фәләкъ” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

***107. Бу сүрә кайда иңгән?***

- Мәккәдә; - Мәдинәдә.

***108. “Әл-Фәләкъ” сүрәсен уку яхшырак:***

- Йоклар алдыннан;

- Фарыз намазларыннан соң;

- Бөтен вариантлар да дөрес.

***109. Әлеге гыйбарәләрнең мәгънәләрен аңлат:***

“Яклавына сыенам”:________________________________________

«Фәләка» (Яру): ________________________________________

«Төеннәргә өрүче»:________________________________________

***110. Әлеге сүрә үз эченә түбәнедәгеләрне ала:***

- Мөселман кешесе явызлыктан Аның саклавы астына сыенырга тиеш;

- Сихерчелекнең бар икәнлегенә дәлил;

- Бөтен вариантлар да дөрес.

**“Ән-Нәс” сүрәсе аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

***111. Бу сүрә кайда иңгән?***

- Мәккәдә; - Мәдинәдә.

***112. “Ән-Нәс” сүрәсен укырга яхшырак:***

- Йоклар алдыннан;

- Фарыз намазларыннан соң;

- Бөтен вариантлар да дөрес.

***113. “Ән-Нәс” сүрәсендәге “...юкка чыга торган вәсвәсә кылучы” дигән гыйбарә нәрсәне аңлата?***

_____________________________________________________________

# Икенче дәрес

## Икенче дәрес: ИСЛАМНЫҢ БАГАНАЛАРЫ

Икенче дәрес Исламның биш баганасын аңлатуга багышлана. Әлеге баганаларның беренчесе һәм олугы – Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, һәм Мөхәммәд – Аның колы һәм илчесе икәнлегенә шәһәдәт китерү.

لا إله إلا الله محمد رسول الله

Дәрес “Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк” шәһәдәт кәлимәсенең мәгънәсен, шулай ук аның шартларын аңлатуны үз эченә ала. Шәһәдәтнең мәгънәсе шул: 1) Аллаһтан башка бүтән гыйбадәт кыла торган иләһләрне инкарь итү (лә иләһә – Табынырга лаеклы зат юк); 2) Тиңдәше булмаган Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылуны раслау (иллә-Ллаһ – Аллаһтан башка).

“Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк” шәһәдәт кәлимәсенең шартлары исә шул:

1) Наданлык белән тиң булмаган гыйлем;
2) Шик-шөбһә белән тиң булмаган инану;
3) Ширек белән тиң булмаган ихласлылык;
4) Ялган белән тиң булмаган дөреслек;
5) Нәфрәт белән тиң булмаган мәхәббәт;
6) Карышу белән тиң булмаган буйсыну;
7) Кире кагу белән тиң булмаган кабул итү;
8) Аллаһтан башка табына торган иләһләргә ышанмау.

Шулай ук әлеге дәрестә Мөхәммәд – Аллаһның илчесе дигән шәһәдәт кәлимәсе дә аңлатыла. Ул үз эченә пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) сөйләгән барлык хәбәрләргә дә һич шикләнмичә ышануны; ул кушкан әмерләргә буйсынуны, ә тыйган нәрсәләрдән ерак булуны; Аллаһ Тәгаләгә ул күрсәтеп калдырганча гыйбәдәт кылуны ала. Шуннан соң Исламның башка әркәннәре: намаз, зәкәт, Рамазан аенда ураза тоту, Мөмкинчелеге булган кешегә Аллаһның йортына барып хаж гыйбадәтен кылу хакында аңлатыла.

**“Лә иләһә иллә-Лланһ”ның әркәннәре**

**Инкарь итү (Лә иләһә)**
Аллаһтан башка бүтән гыйбадәт кыла торган иләһләрне инкарь итү (Тагутка ышанмау)

**Раслау (иллә-Лланһ)**
Тиңдәше булмаган Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылуны раслау (Аллаһка иман)

**Ихласлылык сүзләренең ике әркәне бар: инкарь итү һәм раслау – аларны тулысынча белү тиешле**

## “Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк” шәһәдәт кәлимәсенең шартлары

Әлеге шәһәдәт кәлимәсенең шартлары ачкычның тешләре кебек, чөнки “лә иләһә иллә-Лланһ” – Җәннәт ачкычы, ә йозакта яраклы тешләр булмаса, ул ачкыч аны ачмаячак. Нәкъ менә шул рәвешле, “Лә иләһә иллә-Лланһ”ны әйткән өчен Коръән һәм Сөннәттә вәгъдә ителгән барлык бүләкләрне алу өчен дә, ошбу сигез шартны үтәргә кирәк:

1. **Гыйлем** - әлеге шәһәдәт кәлимәсенең мәгънәсен белү, әлеге гыйлем наданлык белән һич тиң түгел. Шәһәдәтнең мәгънәсен белмәгән кешегә ул файда китермәс, шуңа күрә Ислам динен кабул итәргә теләгән кешегә, беренче чиратта аның мәгънәсен белү кирәк. Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын): **“Аллаһтан башка табынырга лаеклы башка зат юк икәнлеген белеп вафат булган кеше Җәннәткә керәчәк**”, - диде, хәдисне имам Мөслим китерә.

2. **Тулы инану** – әлеге шәһәдәтнең хаклыгына тулысынча инану. Әгәр кеше аның хаклыгында йөз процентның бер генә өлеше кадәр генә шикләнсә дә, ул тәүхид иясе түгел. Шулай ук Аллаһ Тәгалә имансызлар дип атаган бәндәләрне имансызлар дип санамаган кеше дә тәүхид иясе булмый. Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын): “Аллаһтан башка табынырга лаеклы һичбер зат юк, һәм мин – Аның илчесе. Әгәр Аллаһның колы Аллаһ белән очрашкан вакытта аңарда шушы ике шәһәдәт тә булса, һәм ул аларда һич шикләнмәсә, ул Җәннәткә керәчәк”, - диде, хәдисне имам Мөслим китерде.

3. **Ихласлылык.** Бу шәһәдәттә тышкы яктан гына (рия) тәкъвалык күрсәткән яки зур ширек (Аллаһтан башка затка гыйбадәт кылу кебек гамәл) кылган кешегә ул файда бирмәс. Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын): **“Кыямәт көнендәге иң бәхетле кешеләр – “Ләилаһә илла-Ллаһ”ны чын күңеленнән яки йөрәгеннән ихласлылык белән әйткән кешеләр**”, - диде, хәдисне имам әл-Бохари китерә.

4. **Дөреслек.** Икейөзлеләр кебек, бу шәһәдәт кәлимәсен ялганлап кына әйткән кешегә дә ул файда китермәс. Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын): **“Дөреслек белән чын йөрәктән Аллаһтан башка табынырга лаеклы башка бер зат та юк һәм Мөхәммәд – Аның колы һәм илчесе, дип шәһәдәт китергән кешегә Аллаһ Җәһәннәм утын харам кылды”**, - диде, хәдисне имам Әл-Бохари һәм имам Мөслим китерде.

5. **Мәхәббәт.** Кеше Аллаһны яратырга тиеш һәм Аның белән беррәттән башка затларны яратырга тиеш түгел. Моннан тыш, Аллаһ яратырга боерган кешеләрне да яратырга кирәк. Мәхәббәтнең капма-каршысы – нәфрәт (күралмау), шуңа күрә “Исламнан чыгаручы гамәлләр” юлламасында: “Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) алып килгәннәргә карата нәфрәт кичергән кеше, хәтта аларга муафыйк рәвештә гамәл кылса да, имансыз була”, - диелә. Аллаһ Тәгалә әйтте: “**Кешеләр арасында шундыйлары бар, алар Аллаһка тиңдәш кылалар һәм ул затларны Аллаһны яраткан кебек яраталар**”.

6. **Буйсыну.** Әлеге шартның мәгънәсе шул ки, шәһәдәтне әйткән кеше, ана муафыйк рәвештә гамәл кылырга тиеш. Шулай эшләмәгән кешегә бу шәһәдәт файда китермәс. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Ләкин юк — синең Раббың белән ант итәм! — сине, үзләре арасындагы буталчыкларда хөкемдар итеп сайлаганчыга кадәр алар иман китермәсләр, синең карарларыңа карата күкрәкләрендә кысылу бетмәс, һәм тулысы белән буйсынмаслар**”.

7. **Кабул итү.** Кеше әлеге шәһәдәт кәлимәсенә кагылышлы сүзләрнең, гамәлләрнең һәм инануларның берсен дә кире кагарга тиеш түгел. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аларга: “Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк”, - дип әйткән вакытта алар һаваланып китә һәм әйтә иделәр: “Юләр шагыйрьгә ияреп, без үзебезнең иләһләребездән баш тартырбыз мени?”**

8. **Аллаһтан башка бүтән табына торган иләһләргә ышанмау** шундый мәгънәгә ия: кеше Аллаһтан башка бүтән затларга табынуның нигезсез, мәгънәсез һәм бары Аллаһ кына табынырга лаеклы зат булуына инанган булырга тиеш.

Мөһим:

Хаклыкка шәһәдәт китергәндә сүзләр әйтелергә, гамәлләр белән расланырга һәм йөрәктә инану булырга тиеш

## Мәхәббәтнең төрләре

### Аллаh белән беррәттән кемгәдер мәхәббәт

Мондый төр мәхәббәт зур ширек була, моңа Аллаhның сүзләре дәлил: "Кешеләр арасында шундыйлары бар, алар Аллаhка тиңдәш кылалар һәм ул затларны Аллаhны яраткан кебек яраталар".

### Аллаhка мәхәббәт

Аллаhка карата мәхәббәт мәҗбүри, һәм, аннан да бигрәк, иманның мөһим билгеләренең берсе булып тора. Аллаh Тәгалә әйтте: **"Мөхәммәд — Аллаhның илчесе. Аның белән бергә булучылар имансызларга кырыс һәм үзара рәхимле".** Аллаh ризалыгы өчен яратырга кирәк:

### Табигый мәхәббәт

Рөхсәт ителгән, ләкин бер шарт белән: ул Аллаhка мәхәббәттән катырак булырга тиеш түгел. Табигый мәхәббәтнең мисалы: хәләл җефетләргә, балаларга карата мәхәббәт. Аллаhның илчесе (Аллаhның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әйтте: *"Мине балагызга, әти-әниегезгә һәм башка кешеләргә караганда катырак яратканчыга кадәр сезнең берегез дә иман китермәс".*

---

- Аллаh ярата торган **билгеле бер урыннарны**, мәсәлән: Мәккә, Мәдинә…
- Аллаh ярата торган **билгеле бер вакытларны,** мәсәлән: Кадер кичәсе яки төннең өченче өлеше
- Аллаh Тәгалә риза булган **гамәлләрне**. Моңа шәригатьтә килгән бар нәрсә дә керә, мәсәлән: Тәүхид
- Бу гамәлләрне кылучы **кешеләрне**. Мәсәлән: пәйгамбәрләр, рәсүлләр, фәрештәләр, сәхәбәләр һәм барлык тәүхид ияләре

“Мөхәммәд – Аллаһның колы” гыйбарәсе нәрсәне аңлата?

Ул (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Аллаһка иң күркәм һәм иң дөрес рәвештә гыйбадәт кылучы дигәнне.

Аңа (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) гыйбадәт багышлау ярамаган эш һәм ул нинди дә булса илаһлек һәм раббылык сыйфатларына ия түгел дигәнне.

Гыйбадәтнең төрләре

**Гомуми**

Бу Аллаh Тәгаләнең Раббылыгына нигезләнгән гыйбадәт. Аны шулай ук “мәҗбүри коллык” (убудияту әл-кахр) дип тә атыйлар. Аллаh Тәгалә әйтте: **«Күкләрдәге һәм җирдәге һәр мәхлук Аллаh каршысына кол сыйфатында басачак”.** Бу төр коллык иманлы бәндәләргә дә, имнсызларга да кагыла.

**Махсус**

Бу Аллаhка буйсынуга нигезләнгән гыйбадәт. Аллаh Тәгалә әйтте: **“Аллаhның коллары җир өстендә түбәнчелек белән йөрүчеләрдер”**. Әлеге төр Аллаh Тәгаләгә гыйбадәт кылып, Аның динен тоткан һәр кешегә кагыла.

**Махсусның да махсусы**

Бу Аллаһның илчеләре һәм пәйгамбәрләр гыйбадәте. Аллаh Тәгалә әйтте: **“Чынлыкта, ул шөкер итүчеләрдән булды”.** Әлеге төр бары тик Аллаһның илчеләренә генә кагыла, чөнки Аллаһка гыйбадәттә алар белән һичкем ярыша алмый.

Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) тормышыннан өзекләр

**Исеме һәм нәселе**

Ул - Мөхәммәд ибн Габдуллаh ибн Габделмотталиб ибн Хашим. Хашим – Корәеш кабиләсеннән, ә корәешләр – килеп чыгышлары Ибраһимның (галәйхиссәләм) угълы Исмәгыйль нәселенә барып тоташучы гарәпләр.

## Икенче дәрес аңлатмасы

| | |
|---|---|
| Тууы | Ул (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Фил вакыйгасы елында Рабигуль-әүвәл аенда Мәккәдә туа. Ул алтмыш өч ел яши, шуларның кырыгын – пәйгамбәрлек иңгәнче, егерме өч елын – пәйгамбәр һәм Аллаһның илчесе буларак гомер итә. Ул ятим була: әтисе ул туганчы ук вафат була, башта бабасы Габделмотталиб, аның вафатыннан соң, әтисе ягыннан абыйсы - Әбу Талиб карамагында тәрбияләнә. |
| Аның рәсүл булуы | Ул (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) җеннәр һәм кешеләр нәселенә рәсүл итеп җибәрелә. Аның чакыруы барып ирешкән, әмма аны кабул итмәгән һәркем имансыз була. |
| Аның чакыруы | Ул (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) тәүхидкә чакырган, барлык хәерле, изге гамәлләргә өндәгән, ширектән, начар, бозык, яман гамәлләрдән тыйган. |
| Исра һәм Мигъраж | Ул (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Мәккәдән Иерусалим шәһәренә күчерелә, шуннан соң күкнең җиденче катына мендерелә, анда аның белән Аллаһ Тәгалә сөйләшә һәм биш вакыт намазны фарыз итә. |
| Хиҗрәт кылуы һәм вафаты | Ул (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Мәккәдән Мәдинә шәһәренә хиҗрәт кыла. Анда вафат була һәм Гайшә анабыз (Аллаһ аннан разый булсын) бүлмәсендә җирләнә. |
| Кешеләргә Аллаһның вәхиен җиткерү | Аллаһ Тәгалә динне Үзенең рәсүле аша камилләштерде. Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) исә Ул индергән вәхийне кешеләргә ачык итеп җиткерде, үзенә йөкләнгән эшне җиренә җиткереп үтәде, өммәтенә карата ихласлылык күрсәтте, хакыйкатьне җиткерде һәм Аллаһ юлында хакыйкый тырышлык күрсәтте, шуңа күрә аннан соң әлеге дингә нинди дә булса яңалык кертергә һичкемнең хакы юк. |
| Мөһим сугышлар | Алар җидәү: Бәдр, Өхед, чокыр янындагы сугышлар, Хәйбәрне, Мәккәне алу, Тәбук һәм Хунәйн янындагы сугышлар. |
| Аның җиде баласы | Аның (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) өч угълы: Әл-Касыйм, Ибраһим, Габдуллаһ (аны шулай ук “Әт-Тайиб” (яхшы) һәм “Әт-Таһир” (чиста) дип тә атаганнар) һәм дүрт кызы: Зәйнәб, Рөкыя, Умм Көлсем, Фатыйма була. Фатыймадан кала барлык балалары да үзе исән вакытта ук вафат булалалар. Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) вафат булып алты ай үткәч, Фатыйма да бакыйлыкка күчә. |
| Аның унике хатыны | Хәдичә, Гайшә, Сәүдә, Хәфсә, Зәйнәб әл-Хиләлия, Хинд Умм Сәләмә, Зәйнәб Бинт Җәхш, Җөвәйрия Бинт әл-Харис, Сафия, Рәмлә Умм Хәбибә, Рәйхана Бинт Зәйд, Мәймүнә Бинт әл-Харис, Аллаһ Тәгалә аларның барсыннан да риза булсын. |
| Аның сөт аналары | Аның (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әнисе - Әминә Бинт Вәхб; сөт аналары - Сувәйбә (Әбу Ләхәбнең азат ителгән кол хатыны); Хәлимә Бинт Әби Зи'б Әс-Си‘дия, Аллаһ аннан риза булсын |
| Аңа беренче булып иңгән сүзләр | Аллаһ Тәгаләнең “Галәк” сүрәсендәге ошбу сүзләре: **“Ий Мухәммәд г-м Коръәнне укы һәрнәрсәне халык кылучы Раббың исеме илә! Ул халык кылды кешене оешкан каннан. Укы, синең Раббың – Аллаһ бик хөрмәтле һәм юмарттыр. Ул – Аллаһ каләм белән язуны өйрәтте”** |
| Аның артыннан ияргән беренче кешеләр | Ир-атлардан - Әбу Бәкр Әс-Сиддыйк, хатын-кызлардан – мөселманнарның анасы Хәдичә Бинт Хувәйлид, балалардан - Гали Ибн Әби Талиб, азат кылынганнардан - Зәйд Ибн Харисә, коллардан - Биләл Ибн Рабәх, Аллаһ Тәгалә аларның барысыннан да риза булсын. |

## Икенче дәрес аңлатмасы

| | |
|---|---|
| Аның Хажы һәм Гомрәсе | Ул (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) дүрт Кече хаж (Гомрә) кыла, аларның барысы да Зөлкагдә аена туры килә. Шулай ук ул (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) бер тапкыр унынчы Хиҗри елда Олы хаж кыла. Бу Хаҗны саубуллашу хажы дип атыйлар. |
| Аның әхлагы | Аллаһ Тәгалә әйткән: **“Хакыйкатьтә, син – югары әхлак иясе”,** шулай ук анабыз Гайшә, Аллаһ аннан риза булсын, әйтте: “Аның холкы – Коръән иде”. |
| Пәйгамбә-ребезнең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) тормыш юлын өйрәнүнең әһәмияте | Ибн Әл-Кайим, Аллаһ аны кичерсен, әйткән: “Әгәр колның ике дөньядагы бәхете Аллаһ илчесенең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) күрсәтмәләренә бәйле булса, үзенә яхшылык, котылу һәм бәхет теләгән һәркем, бу хакта белмәүчеләр рәтеннән булмасын, ә аңа иярүчеләрдән булсын өчен аның тормыш юлын өйрәнергә тиеш. Аның күрсәтмәләренә карата кешеләр аз белүче, күп белүче һәм бөтенләй белмәүчеләргә бүленә. Рәхим-шәфкать Аллаһ Тәгалә кулында һәм Ул аны кемгә теләсә шуңа бирә, чөнки Аллаһ Тәгалә олугъ рәхим-шәфкать иясе”. |

# Өченче дәрес

**Өченче дәрес: ИМАН БАГАНАЛАРЫ (ӘРКӘННӘРЕ)**

Иманның алты баганасы бар: Аллаһка иман, Аның фәрештәләренә иман, Аның китапларына иман, Аның пәйгамбәрләренә иман, Кыямәт көненә иман, тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһтан икәнлегенә иман.

## Шәригать терминологиясендә иман:

Тел белән әйтү, калеб белән ышану һәм тән әгъзалары белән гамәл кылу. Иман Аллаһка буйсынудан арта һәм Аңа гөнаһ кылу белән зәгыйфьләнә.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| “Тел белән әйтү” дигән сүзләргә пәйгамбәребез-нең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) ошбу хәдисе дәлил: **“Иманның иң бөек тармагы ул - Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк дип шәһәдәт әйтү”.** | “Гамәлләр” дигән сүзгә пәйгамбәребез-нең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әлеге хәдисе дәлил: **“Иманның иң түбән тармагы – юлдан комачау иткән әйберне алып кую”.** | “Йөрәк гамәлләре” дигән сүзләргә пәйгамбәребез нең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) ошбу хәдисе дәлил: **“Оят – иманның бер тармагы”.** | “Иман арта” дигән сүзләргә Аллаһның ошбу сүзләре дәлил: **“Моннан кемнең иманы күчлерәк булды?”** | “Иман төшү” дигәнгә пәйгамбәребез нең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әлеге хәдисе дәлил: **“Динне тиешле дәрәҗәдә тотмаган кешеләрдән беркемне дә күрмәдем...”** |

## Өченче дәрес аңлатмасы

### Иман артуның сәбәпләре

- Тәүхидне, әбигрәк тә Аллаһның күркәм исем-сыйфатларына кагылышлы гыйлемне өйрәнү
- Аллаһ яраткан гамәлләрне күп кылу
- Гөнаһларны калдыру
- Аллаһ Тәгаләнең мәхлуклары хакында фикер йөртү

### Иман төшүнең сәбәпләре

- Тәүхидне, әбигрәк тә Аллаһның күркәм исем-сыйфатларына кагылышлы гыйлемне белмәү
- Аллаһ яраткан гамәлләрне кылмау
- Гөнаһлар кылу
- Аллаһ Тәгаләнең мәхлуклары хакында фикерләмәү

### Иманның алты баганасы

- Аллаһка иман
- Аның фәрештәләренә иман
- Аның китапларына иман
- Аның пәйгамбәрләренә иман
- Кыямәт көненә иман
- Тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһтан икәнлегенә иман

## Беренче багана: Аллаһка иман.
**Аңа менә нәрсәләр кирәк:**

Аллаһның барлыгына иман. Ул дүрт ысул ярдәмендә раслана:

Аллаһның Раббылыгына иман

Аллаһның гыйбадәт кылуга лаекле икәнлегенә иман

Аллаһның исем-сыйфатларына иман

**Акыл**

мәхлукларны Бар кылучыдан башка күз алдына китерергә баш тарта. Аллаһ әйтте: **“Әллә алар үзләре халык ителделәрме? Әллә алар үзләре халык кылучылармы?”**

**Физик тоемлау**

Кешегә кайгы һәм бәла-каза килгәндә, ул, кулларын күтәреп ялвара: *“Йә, Раббым! Йә, Раббым!”* – һәм ул бәла-казалар Аллаһның теләге белән үтәләр.

**Фитрый иман**

Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әйтте: **“Һәрбер бала фитрый иман белән туа, ә инде соңыннан эти-әнисе аннан яһүд яки насара ясый …”**

**Шәригать**

Ибн Әл-Кайим әйтте: “Коръәннең һәрбер аяте тәүхидкә ишарәли һәм аны дәлилли”.

## Икенче багана: Фәрештәләргә иман.

Фәрештәләр яшерен дөньяның бер өлеше булып торалар. Алар нурдан яратылган затлар, алар Аллаһка буйсыналар һәм бу буйсынудан һичкайчан тайпылмыйлар. Аллаһ Тәгаләнең сүзләренә караганда, аларның рухлары: **“Изге рух (Җәбрәил)”;** тәннәре: **“Аллаһ фәрештәләрне ике, өч, дүрт канатка ия илчеләр итеп яратты”;** гакыл һәм калебләре: **“Калебләреннән курку киткәч, алар: “Раббыгыз ни диде?” – диярләр** бар. Без гомумән барлык фәрештәләргә дә иман китерәбез, шулай ук Аллаһ Тәгалә безгә исемнәрен хәбәр иткән фәрештәләргә (мәсәлән, Җәбрәил, Микаил, Исрафил) иман китерәбез, аларның сыйфатларына **(“Аллаһның әмерләреннән тайпылмыйлар, кушылганнарны үтиләр”)** һәм кылган эш-гамәлләренә ышанабыз.

### Фәрештәләр хакында безгә мәгълүм булган кайбер хәбәрләр:

Алар арасында Көрсине күтәреп йөртүче сигез фәрештә, вәхий китерү өчен җаваплы Җәбраил, яңгыр өчен җаваплы Микаил фәрештәләр бар. Без фәрештәләргә һәм алар хакында безгә ирешкән гомуми хәбәрләргә дә, җентекле тулы хәбәрләргә дә ышанырга тиешбез.

## Өченче багана: Китапларга иман.

Без китапларның Аллаһ сүзе икәнлекләренә, алар кешеләр тарафыннан язылмаган, ә Аллаһ тарафыннан иңдерелгән булуына һәм Аллаһ Тәгалә һәр пәйгамбәр белән китап иңдергәненә ышанырга тиешбез. Без бөтен китапларга да ышанабыз һәм аларның кайберләренең Аллаһ тарафыннан безгә белгертелгән исемнәренә һәм аларда китерелгән хәбәрләргә, шулай ук аларда билгеләнгән кануннарга, әгәр дә алар гамәлдән чыкмаган булса, ышанабыз һәм инанабыз. Коръәннең үзенә кадәр килгән китапларны: Тәүрат, Инҗил, Зәбур, шулай ук Ибраһим һәм Муса сәхифәләрен гамәлдән чыгаруына инанабыз.

## Дүртенче багана: пәйгамбәрләргә иман.

Без пәйгамбәрләрнең Аллаһның табынырга ярамый торган коллары һәм ялган сөйләүләрендә шикләнергә ярамый торган илчеләре булуына инанабыз. Без рәсүлләрнең кешеләр булуына һәм аларның Аллаһ Тәгаләгә хас иләһи сыйфатларга һәм үзенчәлекләргә ия булмавына ышанабыз. Аллаһ Тәгалә аларны җибәрде, аларга вәхий иңдерде, Үзенең могҗизалары белән ярдәм итте, ә алар, үз чиратларында, үзләренә ышанып тапшырылган миссияне үтәделәр, үз өммәтләренә карата ихлас булдылар, хакыйкатьне җиткерделәр һәм Аллаһ юлында чын тырышлыкларын күрсәттеләр. Без аларга, гомумән, ышанабыз, шулай ук аларның Аллаһ тарафыннан безгә белгертелгән исемнәренә, тасвирланышларына, алар хакындагы мәгълүматка һәм аларга бүләк ителгән могҗизаларга ышанабыз. Без Адәм пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе һәм салаваты булсын) беренче пәйгамбәр булуына, беренче рәсүлнең Нух (Аллаһның аңа сәламе һәм салаваты булсын) икәнлегенә, ә соңгы пәйгамбәр һәм рәсүл Мөхәммәд (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) булуына инанабыз. Мөхәммәд пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) шәригате аңа кадәрге барча шәригатьләрне гамәлдән чыгарды. Рәсүлләр арасында биш «гаять кыюлыкка ия булганнары» (улюль-'азм) бар: Мөхәммәд, Нух, Ибраһим, Муса һәм Гайсә, Аллаһның аларга сәламе һәм рәхмәте булсын!

## Бишенче багана: Соңгы көнгә иман.

Ул пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) үлемнән соң нәрсәләр буласы (мәсәлән, кабер сынавы, Сурга өрү, кабердән кубарылу, терелү, Хисап, Үлчәү, Гамәл дәфтәрләре, Сират күпере, Җәннәт, Җәһәннәм, пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) һәм тәүхид ияләренең шәфәгате, Сулык, иманлы бәндәләрнең Кыямәт көнендә һәм Җәннәттә Аллаһ Тәгаләне күрүләре һәм башка яшерен вакыйгалар) хакындагы хәбәрләренә ышануны үз эченә ала.

## Алтынчы багана: Тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһтан икәнлегенә иман.

Тәкъдиргә ышану түбәндәгеләрдән гыйбарәт: гыйлем, язу, теләк һәм халык кылу: “Раббыбызның гыйлеме, Аның язуы, шулай ук Аның теләге һәм халык кылуы”

| Гыйлем | Язу | Теләк | Халык кылу |
|---|---|---|---|
| Аллаһның бар нәрсәне дә, тулаем да, җентекле рәвештә дә белүенә ышану. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Ул аларның киләчәкләрен һәм үткәннәрен белә”.** | Аллаһның Кыямәт көненә кадәр бөтен мәхлукатның язмышын язып куюына инану. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Күктә һәм җирдә Китапта (Ләүхүл Мәхфүздә) язылмаган яшерен әйберләр юк”.** | Аллаһ теләгән нәрсәләрнең булуына, ә Ул теләмәгән нәрсәләрнең булмавына ышану. Кешенең үз теләге бар, әмма ул Аллаһ Тәгаләнең теләгенә буйсынган. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһ теләмичә торып, сез теләмәссез”.** | Аллаһның колы, аның гамәлләре һәм башка мәхлуклар кебек үк халык кылынган, яратылган булуына ышану. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһ – бар нәрсәне Халык кылучы”, “Аллаһ сезне һәм сез ясаган нәрсәләрне барлыкка китерүче”.** |

# Дүртенче дәрес

## Дүртенче дәрес: ТӘҮХИД ҺӘМ ШИРЕК ТӨРЛӘРЕ

Әлеге дәрес тәүхид төрләрен аңлатуны үз эченә ала, алар өчәү: Аллаһны Раббылыкта берләү, иләһлектә (табынырга лаеклы икәнлегендә) берләү, шулай ук исем һәм сыйфатларында берләү. Аллаһны Раббылыкта берләү Аллаһ Тәгалә – барлык мәхлукатның Хуҗасы һәм Тәрбиячесе булуына һәм бу эштә Аңа тиңдәш затлар юк икәнлегенә ышанудан гыйбарәт. Аллаһны иләһлектә берләү – бары тик Аллаһ кына табынырга лаеклы зат булуына, һәм бу эштә Аңа тиңдәшләр юк икәнлегенә ышану ул. “Лә Иләһә иллә-Ллаһ” – Аллаһтан башка табынырга лаеклы бер зат та юк шәһәдәт кәлимәсенең дә мәгънәсе шуннан гыйбарәт. Бөтен төр гыйбадәт тә (намаз, ураза һәм башкалар) тулаем бары тик Бер Аллаһка гына багышланырга тиеш, һәм бер гыйбадәтне дә, хәтта аның бер өлешен генә дә Аннан башка бүтән затларга багышлау рөхсәт ителми. Аллаһны исем һәм сыйфатларында берләү Аллаһның Коръәндә яки дөрес хәдисләрдә килгән исем һәм сыйфатларына кагылышлы барлык хәбәрләргә дә ышанудан гыйбарәт. Аллаһка карата бу исем һәм сыйфатларны Аның Олугълыгына муафыйк рәвештә, мәгънәсен үзгәртмичә, кире какмыйча, кемгәдер яки нәрсәгәдер охшатмыйча, “Ничек?” дип сорау бирмичә кулланырга кирәк. Аллаһ Тәгалә әйтте: “Әйт: ***"Ул - Аллаһ Һич, Тиңдәше Вә Охшашы Булмаган Ялгыз Бер Генә Аллаһдыр. Ул һичкемне тудырмады һәм һичкемнән тудырылмады”,*** Ул шулай ук: ***“Аның кебек һичнәрсә юктыр, мәгәр Аллаһ Үзе генәдер, Ул - Аллаһ һәрнәрсәне ишетүче һәм һәрнәрсәне күрүчедер”,*** - диде.

Ширекнең өч төре бар: зур ширек, кече ширек, яшерен ширек. Зур ширек гамәлләрне файдасыз итә һәм мәңгелек Җәһәннәмгә әләгүгә сәбәп була. Аллаһ Тәгалә әйтте: ***“Әгәр Аңа ширек китерсәләр, аларның кылган барлык гамәлләре дә буш булыр”***, шулай ук Ул әйтте: ***“Кәферләргә кәгъбәне төзәтүләрендә аларга сәваб булмас үзләренең кәфер икәнлеге белән шәһадәт бирен торган хәлләрендә. Аларның гамәлләре батыл, һичберсенә сәваб юк, алар җәһәннәмдә мәңге калучылардыр”.*** Исән вакытында зур ширек кылып бу дөньядан киткән кешегә, бу гөнаһысы гафу ителмәс һәм аның өчен Җәннәт бакчалары тыелган булыр. Аллаһ Тәгалә әйтте: ***“Аллаһ, әлбәттә, үзенә тиңдәшлек кылуны ярлыкамас, мәгәр тиңдәшлек кылу гөнаһыннан башка гөнаһны үзе теләгән кешедән ярлыкар”,*** Ул шулай ук әйтте: ***“Берәү Аллаһка кемнедер, нәрсәнедер тиңдәш кылса дөреслектә Аллаһ ул кешегә җәннәтне хәрам кылды. Аларның булачак урыннары уттыр, ул ут ни яман урындыр”.*** Зур ширек төрләренә шушыларны кертергә була: вафат булганнарга һәм потларга дога белән мөрәҗәгать итү, алардан ярдәм сорау, аларга багышлап нәзер әйтү, алар ризалыгын өмет итеп корбан чалу һәм башкалар.

Кече ширек, Коръән һәм Сөннәттә ширек дип аталса да, зур ширеккә тиң түгел, мәсәлән: кайбер төр гыйбадәтләрдә тәкъвалыкны кешегә күрсәтү, Аллаһ белән ант итмәү, “Аллаһ һәм шул-шул кеше шулай теләде”, - дип әйтү һәм башкалар.

Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын): **“Барысыннан да бигрәк мин сезнең өчен кече ширектән куркам”, - диде. Аннан кече ширекнең нәрсә икәнлеге хакында сорагач, ул: “Кешегә күрсәтелгән тәкъвалык (рия)”**, - дип җавап бирде. Шулай ук ул (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын): **“Кем дә кем Аллаһтан башка бүтән нәрсәләр белән ант итсә, ул ширек кылган булыр”**, - диде. Шулай ук аның (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) сүзләреннән**: “Аллаһ һәм шул-шул кеше шулай теләде”, - дип әйтмәгез, “Аллаһ шулай теләде, шуннан соң шул-шул кеше теләде”,** - диегез”, әлеге хәдисне Имам Әбу Дауд китерде, хәдисне тапшыручыларның ышанычлы чылбыры аша Хузәйфа Ибн әл-Ямәннән килде, Аллаһ аннан риза булсын. Ширекнең әлеге төре кешене диннән чыгармый һәм ул кешенең мәңге Җәһәннәм утында калуына сәбәп түгел, әмма ул кешенең өстенә йөкләтелгән тәүхидне кимчелекле итә. Өченче төр – яшерен ширек, аның хакында Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) болай диде: **“Сезнең өчен Дәджҗалдән дә ныграк нәрсәдән куркуым хакында җиткеримме?”, кешеләр әйтте: “Җиткер, йә Аллаһның илчесе”, һәм ул дәвам итте: “Сезнең өчен мин яшерен ширектән куркам, ул - намазга дип баскан кешенең намазын, бу вакытта аны күрүчеләр өчен, матурлап, бизәп укуы”.** Шулай ук ширекне ике төргә: зур һәм кече ширеккә генә бүлеп карау да рөхсәт ителгән, ә яшерен ширеккә килгәндә, ул зур да, кече дә була ала. Яшерен зур ширекнең мисалы итеп монафыйкларның ширкен китерергә мөмкин, чөнки алар эчләрендә имансызлыкны, ышанмауны яшерәләр, ә тышкы яктан кешеләргә күрсәтү һәм үзе өчен куркудан мөселман булып йөриләр. Яшерен кече ширекнең мисалы исә - кешегә күрсәтелгән тәкъвалык, ул Мәхмуд Ибн Ләбид әл-Ансариның югарыда китерелгән хәдисендә, шулай ук Әбу Сәиднең алдарак китерелгән хәдисендә телгә алына. Һәм Аллаһ уңышка ирештерүче.

## Тыелган гамәлләрнең төрләре

### Зур ширек

Иң катгый тыю белән тыелган.

### Кече ширек

Зур ширеккә караганда гөнаһысы кечерәк, зур гөнаһларга караганда гөнаһысы зуррак.

### Зур гөнаһлар

Бу – аны кылган өчен билгеле бер җәза (мәсәлән, ләгънәт кылыну яки бу гөнаһны кылучыга катышмау кебек) вәгъдә ителгән теләсә-кайсы гамәл. Җәза шулай ук гөнаһ кылучыны кәфер яки мөшрик итеп тасвирлау яки иң әшәке хайванга тиңләү рәвешендә дә булырга мөмкин.

### Кечкенә гөнаһлар

Аларның барысын да Аллаһ Тәгалә тыйды, әмма алар өчен билгеле бер җәза билгеләмәде.

## Зур гөнаһлар

### Зур гөнаһларның хөкеме

Тәүбә итү мәҗбүри, чөнки Аллаһның рәсүле (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әйтте: **“Үлеменә чаклы тәүбә кылмаган елаучы хатын...”**, шулай ук икенче хәдистә килә: **“...әгәр зур гөнаһлардан сакланса...”**

### Аларның дәрәҗәләре бармы?

Әйе, алар бер-берсеннән дәрәҗәләре белән аерылалар. Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әйтте: **“Зур гөнаһларның олугълары...”**

### Зур гөнаһлар кылучының хөкеме

1) Ул иманы кимчелекле булган кеше. Ягъни үзенең иманы дәрәҗәсендә иманлы, үзенең гөнаһысы дәрәҗәсендә имансыз;
2) Аны иманына нисбәтле рәвештә яратырга һәм гөнаһысына нисбәтле рәвештә яратмаска кирәк;
3) Кеше зур гөнаһ кылганда, аның белән булырга ярамый;

### Зур гөнаһларның саны

Сан белән чикләнмәгән, әмма югарыда телгә алынган тасвирлау белән чикләнгән.

## Зур ширек белән кече ширек арасындагы аерма

### Зур ширек

1. Кешене диннән чыгара.
2. Барлык гамәлләрне дә юкка чыгара.
3. Кешене мәңгелеккә җәһәннәмгә кертә.
4. Әгәр шуңа дәлилләр булса, ширек зур ширек була.
5. Сәбәп (чара) галәмдә яшерен рәвештә эш итәргә мөмкин дип инану.
6. Әгәр кеше зур ширекне кылып вафат булса, ул кеше Аллаһ тарафыннан кичерелми.
7. Әгәр кеше исән вакытында тәүбә итсә, ул гафу ителәчәк, тик ошбу ике очрактан кала: кояш көнбатыштан чыккач һәм жан бугазга терәлгәч, тәүбә итү файда китерми.

### Кече ширек

1. Кешене диннән чыгармый.
2. Үзе кушылган гамәлдән тыш, калган гамәлләрне юкка чыгармый.
3. Кешене мәңгелеккә җәһәннәмгә кертми.
4. Әгәр шуңа дәлилләр булса, ширек кече ширек була.
5. Әгәр кеше Аллаһ Тәгалә сәбәп (чара) итмәгән нәрсәләрне сәбәп (чара) дип санаса.
6. Зур ширеккә илтүче барлык сәбәпләр дә кече ширек була.
7. Әгәр шәригатьтә “ширек” яки “көферлек” сүзләре килеп, ул сүзләр “әл” билгелелек артикле белән бергә тормаса, башка дәлилләр моның киресенә күрсәтмәгән очракта, ул кече ширек була.

# Бишенче дәрес

**Бишенче дәрес: ИХСӘН**

Ихсән – ул Аллаһка Аны күргән кебек гыйбадәт кылу, чөнки син Аны күрмәсәң дә, Ул сине күрә.

Ихсанның бер әркәне бар, һәм ул ике баскычтан гыйбарәт:

**Аллаһны күргән кебек гыйбадәт кылу (Гыйбадәтуль-мушәхәдә)**

Бу Аллаһ Тәгаләне ярату, Ул әзерләгән җәннәткә омтылуга нигезләнгән гыйбадәт. Пәйгамбәрләр һәм рәсүлләр гыйбадәте шундый иде.Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әйтте: “**Әллә миңа рәхмәтле кол булырга кирәкмиме?!**” Мондый гыйбадәтнең сәбәбе – Аллаһтан курку хисе белән, Аны ярату, Ул әзерләгән җәннәткә омтылу.

**Аллаһның һәрдаим күзәтчелек итеп торуын сизеп гыйбадәт кылу (Гыйбадәтуль-муракаба)**

Гыйбадәт кылганда Аллаһ Тәгаләдән, Аның җәзасыннан курку халәте. Һәм бу дәрәҗә һәр мөселман кешесендә дә булырга тиеш.

# Белемнәрне тикшерү өчен сораулар

**1. Динебезнең ничә баскычы бар ?**
- Бер;
- Ике;
- Өч.

**2. Исламның ничә баганасы бар?**
- Биш;
- Алты;
- Җиде.

**3. Ислам Иманнан дәрәҗәсе буенча зуррак.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**4. Шәһадәтнең ничә әркәне бар?**
- Җиде;
- Сигез;
- Ике.

**5. “Лә иләһә илләә-Ллаһ” шәһадәтенең ничә шарты бар?**
- Сигез;
- Җиде;
- Биш.

**6. “Лә иләһә илләә-Ллаһ”ның шарты булган “гыйлем”нең мәгънәсе:**
- Нәрсәнедер чынлыкта нинди, шул рәвешле танып-белү;
- Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк.

**7. Әгәр хаклык ирешеп тә, кеше аңа инанмаса, әлеге кешенең көферлегендә бездә шик туса, без:**
- Зур көферлеккә төшәбез;
- Кече көферлеккә төшәбез.

**8. “Кабул итү” - “Лә иләһә иллә-Ллаһ”ның бер шарты һәм ул үз эченә түбәндәгеләрне ала:**
- Сүз;
- Гамәл;
- Инану;
- Бөтен вариантлар да дөрес.

**9. “Лә иләһә иллә-Ллаһ” шәһадәтендә кешегә күрсәтелгән тәкъвалык (рия) сәдака бирүдәге рияга тиң һәм кече ширк була.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**10. “Лә иләһә иллә-Ллаһ”ны әйтсә, ләкин йөрәгендә шуңа инану булмаса, ул кеше:**
- Тәүхид иясе;
- Мөселман, ләкин имансыз (Исламда булып, иманы булмаган кеше);
- Зур кәферлеккә төшкән имансыз;
- Зәгыйфь иманлы кеше.

**11. Әгәр кеше пәйгамбәребезне (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) Аллаһны яраткан кебек, шуның дәрәҗәсендә яратса, бу кеше:**
- Зур кәферлеккә төшкән була;
- Кече кәферлеккә төшкән була;
- Зур гөнаһ кылган була.

**12. Мәхәббәтнең ничә төре бар?**
- Дүрт;
- Өч;
- Ике.

**13. Аллаһ ризалыгы өчен мәхәббәт гамәлләргә, кешеләргә, аерым урыннарга һәм вакытларга карата мәхәббәттә күренә.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**14. Аллаһка тиң кылып кемнедер ярату ул:**
- Кече ширек;
- Мәҗбүри;
- Зур ширек;

**15. Аллаһ ризалыгы өчен мәхәббәт:**
- Рөхсәт ителгән;
- Мәҗбүри;
- Зур ширек.

**16. Аллаһка хезмәт итүнең ничә төре бар?**
- Ике;
- Өч;
- Дүрт.

**17. Бөтен мәхлуклар да Аллаһка мәҗбүри коллык аша буйсынган, хәтта имансызлар да.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**18. Әгәр кеше “Лә иләһә иллә-Ллаһ” шәһәдәтен әйтсә, ләкин бернинди гыйбадәт тә, һичнинди изге гамәл дә кылмаса, шул исәптән намаз да укымаса, бу шәһәдәте аңа:**
- Файда китерер;
- Файда китермәс.

**19. “Мөхәммәд (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) – Аллаһның колы һәм Аның рәсүле”, ягъни “Табынырга ярамаган Аллаһның колы һәм ялганлауда гаепләргә ярамаган Аллаһның илчесе”.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**20. “Аллаһның илчесенә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) аның кушканында буйсыну, ул тыйганнардан тыелу...” – ул:**
- “Мөхәммәд (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) – Аллаһның илчесе” шәһәдәтенең мәгънәсе;
- “Мөхәммәд (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) – Аллаһның илчесе” шәһәдәтенең эчтәлеге.

**21. Пәйгамбәрне (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) иләһлек һәм раббылык сыйфатлары белән сыйфатлаган кеше аның (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Аллаһның колы булуы хакындагы шәһәдәтне китермәде.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**22. Пәйгамбәрне (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) иң олугъ тасвирлау шуннан гыйбарәт:**
- Аллаһның илчесе;
- Аллаһның колы һәм Аның илчесе;
- Соңгы пәйгамбәр

**23. Кем дә кем ислам диненә яңалык кертсә һәм аны яхшы дип санаса, ул Мөхәммәдне (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) безгә хаклыкны җиткермәде, дип саный, чөнки Аллаһ әйтте: “Бүген динне сезнең өчен камил кылдым”, - диде һәм ул көнне диннең бер өлеше булып тормаган нәрсәләр бүген дә шулай булмаслар”, - бу сүзләр кемнеке? :**
- Шейхуль-Ислэм Ибн Тәймиянеке;
- Имам Мәликнеке;
- Имам Ибн Базныкы.

**24. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) кайсы нәселдән?**
- Исмәгыйль (галәйхиссәләм);
- Исхак (галәйхиссәләм).

**25. Буш урыннарны тулыландыр:**
Ул (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) ______ елында ______ шәһәрендә туа. Ул _____ ел яши, шуларның _____ – пәйгамбәрлек иңгәнче, _____ елын – пәйгамбәр һәм Аллаһның илчесе буларак гомер итә. Ул (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын)_____________ иңгәч пәйгамбәр, ә____________ иңгәч рәсүл була.

**26. Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) кемгә җибәрелә?**
- Үзенең халкына;
- Кешеләргә;
- Кешеләр һәм җеннәр нәселенә;

**27. Мигъраж - ул Аллаһ илчесенең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Мәдинәдән Иерусалимга сәяхәте.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**28. Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) кайсы шәһәргә хиҗрәт кыла:**
- Таиф;
- Эфиопия;
- Мәдинә;
- Бөтен вариантлар да дөрес.

**29. Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) катнашкан мөһим сугышлар ничәү булган?**
- Бер; - Ике; - Өч; - Дүрт;
- Биш; - Алты; - Җиде.

**30. Аллаһ илчесенең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) ничә баласы булган?**
- Өч;
- Дүрт;
- Җиде.

**31. Пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Саубуллашу хаҗын үтәве, аның моңа кадәр дә хаҗ гамәлен үтәвенә ишарәли.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**32. Аллаһ илчесенең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) тормыш юлын өйрәнү:**
- Мәҗбүри;
- Яхшы;
- Рөхсәт ителгән.

**33. Буш урыннарны тулыландыр:**
Иман - ул _____ әйтү, _____ ышану һәм _____ һәм _____ гамәлләре. Ул ___________ арта һәм _________кими.

**34. Иманның ничә әркәне бар?**
- Алты;
- Биш;
- Дүрт.

**35. Аллаһка иман китерүгә нәрсәләр керә, алар ничәү?**
- Дүрт;
- Өч;
- Ике;
- Бер.

**36. Аллаһның барлыгы ничә ысул ярдәмендә раслана?**
- Дүрт;
- Аларны санап бетерү мөмкин түгел.

**37. Микаил – яңгыр өчен җаваплы булган фәрештә.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**38. Йөрәк дигән әгъза бары тик кешеләрдә генә була, фәрештәләргә килгәндә, аларның йөрәкләре юк.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**39. Безгә исемнәре билгеле булган ничә китап бар?**
- Алты;
- Дүрт;
- Җиде;
- Бик күп.

**40. Аллаһ Тәгалә һәрбер пәйгамбәргә китап җибәргән.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**41. Аллаһның беренче рәсүле – ул Адәм (галәйһиссәләм)**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**42. Мөхәммәд (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) – рәсүл, әмма пәйгамбәр түгел.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**43. Ничә рәсүл гаять кыюлыкка ия булган (улюль-‘азм)?**
- Биш;
- Дүрт;
- Өч;
- Бик күп.

**44. Соңгы көнгә иман үлемнән соң нәрсәләр буласы, шуларның барысына да ышануны үз эченә ала.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**45. Тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһтан икәнлегенә иманның берничә этапы бар. Алар ничә?**
- Өч;
- Дүрт;
- Биш;
- Алты.

**46. Аллаһ Тәгалә нәрсә дә булса хакында ул вакыйга булганчыга кадәр беләме?**
- Әйе;
- Юк.

**47. Аллаһ Тәгалә кешеләр кылган барлык гамәлләрне дә беләме?**
- Әйе;
- Юк.

**48. Кешеләрнең кылган гамәлләрен Аллаһ Тәгалә алдан ук язып куйганмы?**
- Әйе;
- Юк.

**49. Кешенең ирке һәм теләге бар, шуңа күрә ул ни теләсә, шуны эшли ала.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**50. Аллаһ колларының эш-гамәлләре халык кылынганмы?**
- Әйе;
- Юк.

**51. Тәүхид ничә төргә бүленә?**
- Ике;
- Өч;
- Ике вариант та дөрес һәм мондый бүленеш бәхәсләшү өчен җирлек түгел.

**52. Зур ширек һәм кече ширек арасындагы биш аерманы исеңә төшер һәм бирегә яз:**

1. ____________________________________________________________
2. ____________________________________________________________
3. ____________________________________________________________
4. ____________________________________________________________
5. ____________________________________________________________

**53. Зур ширек һәм кече ширеккә биш мисал яз:**

| Зур ширек | Кече ширек |
|---|---|
| ........................................ | .................................... |
| ........................................ | .................................... |
| ........................................ | .................................... |
| ........................................ | .................................... |
| ........................................ | .................................... |

**54. Ышанудагы монафыйклык – диннән чыгармый торган кече ширек.**

- Дөрес;

- Дөрес түгел.

**55. Ихсанның ничә әркәне бар?**

- Бер;

- Ике.

# Алтынчы дәрес

**Алтынчы дәрес: НАМАЗ ШАРТЛАРЫ**

Намаз шартлары тугыз: 1. Ислам динендә булу; 2. Гакыл; 3. Аера алу яшенә ирешү (тәмйиз); 4. Нәҗесләрдән пакьлану; 5. Нәҗесләрдән арыну; 6. Гаурәтне каплау; 7. Намаз вакыты керү; 8. Кыйбла тарафына юнәлү; 9. Ният.

## Беренче шарт: Ислам динендә булу

Аның капма-каршысы – көферлек. Мәсәлән, әгәр намазны Аллаһны хурлаучы яки гыйбадәтен Аллаһтан башка затларга багышлаучы кеше үти икән, бу эшләре өчен Аллаһка тәүбә итмәсә, аның намазы дөрес булмаячак.

## Икенче шарт: Гакыл

Аның капма-каршысы акылдан язганлык була, аннан да яманрагы – исерү.

## Өченче шарт: Аера алу яшенә ирешү

Аера алу яшенә ирешү (тәмйиз) – ул җенси өлгерү түгел, әмма бу яшьтә бала әйберләрнең аермасын белә башлый, сорауны аңлый һәм аңа җавап бирә ала. Нигездә, җиде яше тулган бала тәмйиз яшенә ирешә. Баланың намазы кайчан дөрес санала? Бала әйберләрнең аермасын белә, сорауны аңлый һәм аңа җавап бирә ала башлагач һәм әйберләрнең аермасын белгәч, мәсәлән, су һәм ут арасындагы аерма һәм башкалар. Әгәр бала бу яшькә ирешмәсә, аның намазы дөрес булмый.

## Дүртенче шарт: Нәҗесләрдән пакьлану

Моңа керәләр:

### Зур нәҗесләр

Госел ярдәмендә бетерелә.

### Кече нәҗесләр

Тәһарәт ярдәмендә бетерелә.

## Бишенче шарт: Нәҗесләрдән арыну

Тәнне, киемне, намаз укый торган урынны нәҗесләрдән арындырырга кирәк. Әгәр кеше үзендә нәҗес булганын белә һәм аннан арынырга мөмкинлеге була торып намаз укыса, аның намазы дөрес булмый. Нәҗесләрдән чистарыну өч төрле була:

**Авырайтылган (мугалләзә):** Бу эт нәҗесләрен чистарту. Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) эт су эчеп киткән савытны җиде тапкыр юарга (шуның беренчесе җир белән юылырга тиеш) кушты. Бу хәдисне Имам Мөслим китерде.

**Җиңеләйтелгән (мухаффәфә):** Бу нәҗесләр бары су белән чылатып кына, хәтта ышкымыйча һәм киемне сыкмыйча гына да чистартылалар. Әйтик, шул рәвешле әле гадәти ризык белән тукланмаган ир баланың бәвеленнән; женси ярсыну вакытында бүленеп чыга торган ябышкак сыекчадан; шулай ук мәнине дә (аның үзеннән-үзе чиста икәнлеген исәпкә алып) шул рәвешле чистарталар, әмма пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әгәр мәни сыек булса, ул киемгә су сипкән, әгәр кипкән булса, киемне ышкыган.

**Уртача (мутавассита):** Мондый нәҗесләрдән чистарынган вакытта, аларны су белән юешләргә, аннан соң ышкырга һәм сыгарга кирәк. Бу төркемгә калган барлык төр нәҗесләр керә, мәсәлән, адәм бәвеле һәм башкалар.

**Нәҗесләрнең төрләре:**

Адәм бәвеле һәм тәрәте, итен ашау өчен кулланырга ярамаган хайваннарның бәвеле һәм тизәге. Мәче, качыр, ишәк кебек сакланырга кыен булган хайваннардан тыш барлык ерткыч җанварлар. Мал чалганда ага торган, җенес әгъзасыннан һәм арт юлдан чыккан кан. Вафат булган кешеләрдән, шулай ук каннары булмаган бөҗәкләрдән (чебен, черки һәм башкалар), шулай ук диңгез үләксәсеннән (балык) саранчадан тыш бөтен үләксә дә нәҗес.

## Алтынчы шарт: Гаурәт җирләрне каплау

Гаурәтнең өч төре бар:

**Җиңеләйтелгән (мухаффәфә):**
Бу җиде яшьтән алып ун яшькәчә булган ир баланың гаурәте. Ул җенси органнар һәм арт юл тирәсен каплап йөрергә тиеш.

**Авырайтылган (мугалләзә)**
Бу җенси яктан өлгергән (балигъ булган) ирекле булган (ягъни кол булмаган) хатын-кызның гаурәте. Ул намазда йөзеннән гайре үзенең бөтен тәнен, ә туганнары булмаган ир-атлар янында йөзен дә капларга тиеш.

**Уртача (мутавассита)**
Бу калган барлык кешеләрнең гаурәте. Алар кендектән алып тезләргә кадәр булган урыннарын капларга, моннан тыш җилкәләрен ябарга һәм матур итеп киенергә тиеш.

## Җиденче шарт: Намаз вакыты керү

Билгеле бер сәбәп белән (әйтик, сәфәр вакыты) намазларны берләштереп уку очрагыннан тыш, вакыты кергәнче укылган намаз дөрес булмый, шулай ук аны вакыты чыккач уку да дөрес түгел. Белә торып, намазны вакыты чыгып беткәнчегә кадәр калдыру гөнаһ була.

## Сигезенче шарт: Кыйбла тарафына юнәлү

Искәрмә - юлда вакытта укылган мөстәхәб (укырга хәерле, саваплы булган) намазлар, чөнки мондый очракларда, өстенә утырып барган хайванның кай тарафка караса, шул тарафка юнәлү рөхсәт ителгән. Безнең көннәрдә исә очкычта намаз уку да бу кагыйдәгә карый. Кешенең Кәгъбәтулла тарафына юнәлергә мөмкинчелеге булмау яки дошманнан саклану да шулай ук бу шарттан искәрмә булып тора.

## Тугызынчы шарт: Ният

Ниятнең урыны – йөрәк, һәм ниятне тел белән әйтү – бидгать гамәл. Әгәр ният намазга кадәр ясалган булса яки кеше бу вакытның фарыз намазын үтәргә (ягъни билгеле бер намазны укырга) ниятләсә, шул җитә.

## Мөһим искәрмәләр

1. Шартларны үтәү мәсьәләсендә белмәү, онытылу, шартны белә торып үтәмәү кебек акланулар кабул ителми. Бары тик кеше үзе белмәгән яки белеп тә оныткан нәҗескә кагылышлы мәсьәлә генә искәрмә була ала. Шундый очракта укылган намаз дөрес була;

2. Шартлар гыйбадәт кылыр алдыннан үтәлә һәм аның асылыннан ерак тора, әмма әлеге шартларның гыйбадәтнең башыннан алып ахырына кадәр үтәлүе кирәк.

# Җиденче дәрес

**Җиденче дәрес: Намаз әркәннәре**

Намаз әркәннәре ундүрт:

1. Мөмкинчелек булса, басып тору; 2. “Тәкбиратуль-Ихрам” (Намазны ачучы тәкбир); 3. “Әл-Фатиха” сүрәсен уку; 4. Рөкүгъ – билгә тикле баш ию; 5. Рөкүгътан тураю; 6. Сәҗдә – тәннең җиде өлеше белән җиргә тикле баш ию; 7. Сәҗдәдән тураю; 8. Ике сәҗдә арасында утыру; 9. Барлык гамәлләрне башкарганда да тынычлык саклау; 10. Әркәннәр арасында эзлеклелек саклау; 11. Соңгы тәшәххуд; 12. Тәшәххуд вакытында утыру; 13. Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) өчен дога (салават);
14. Ике сәлам әйтү.

## Беренче әркән: Мөмкинчелек булса, басып тору

**Фарыз намазда:**

Фарыз намазда басып торырга тулы мөмкинчелек булмаганда бу әркән төшерелә. Әгәр кеше бераз булса да басып тора алса, ул моны эшләргә тиеш.

**Нәфел намазда:**

Нәфел намазны утырып уку рөхсәт ителә, әмма мондый намаз өчен әҗер басып укылган намаз әҗеренең яртысы кадәр генә булачак; шулай ук намазны кырын ятып уку өчен әҗер утырып укылган намаз әҗеренең яртысы кадәр генә була.

## Икенче әркән: “Тәкбиратуль-Ихрам” - намазны ачучы тәкъбирне әйтү

“Тәкбиратуль-ихрам” – ул намазны ачып җибәрүче “Аллаһу Әкбәр” (Аллаһ Бөек) дигән сүзләр. Һәм “Аллаһу Әкбәр”дән тыш башка сүзләр куллану рөхсәт ителми.

## Өченче әркән: “Әл-Фатиха” сүрәсен уку

Һәр намазның һәр рәкәгатендә “Әл-Фатиха” сүрәсен уку мәҗбүри, һәм бу сүрә кычкырып укыламы яки пышылдап кынамы, анысы мөһим түгел. Ул, бер генә аятен дә төшереп калдырмыйча, тулаем укылырга тиеш. Аятьләрне бер-бер артлы, рәттән, хәрефләрне, хәрәкәләрне, сүзләрне дөрес итеп әйтеп уку шарт. “Әл-Фатиха”ны укуның мәҗбүрилеге бары тик кеше имам артына рөкүгъ вакытында килеп басса гына бетә. Мондый очракта ул намазга килеп кушыла һәм аның “Әл-Фатиха”дан башка булса да, рәкәгате дөрес санала.

## Тугызынчы әркән: Барлык әркәннәрне башкарганда тынычлык саклау

Һәр әркәндә Аллаһны зекер итүнең канунлаштырылган төрләренең берсен әйткәндә, тыныч булу зарур.

## Мөһим искәрмә

Әлеге әркәннәр гыйбадәтнең асылына керә. Әркәнне калдыру гыйбадәтне яраксыз итә, һәм ул белепме, белмичәме яки онытылып эшләнелгәнме – анысы мөһим түгел. Калдырылган әркәнне намаздагы җитешсезлекне төзәтү өчен кылына торган сәһү сәҗдәсе белән төзәтеп булмый. Әркәнне төшереп калдырган кешегә, вакыты чыгып киткәнче, намазны яңадән уку кирәк. Ә аның әркәннәре төшеп калган элеккеге намазларына килгәндә, алар кичерелә. Чөнки пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) намазны начар укыган кешегә аларның барысын да яңадән укырга кушмады, намазның тынычлыкны саклау әркәнен калдырган булса да, аңа бары тик бу намаздан элек килгәнен генә яңадән укырга кушты. Аллаһ бу хакта яхшырак белә.

# Сигезенче дәрес

## Сигезенче дәрес: Намазның үәҗибләре

Алар сигез:

1. Беренче, намазны ачып җибәрүче тәкбирдән кала бөтен тәкбирләр (“Аллаһу әкбәр” сүзләре);

2. “Сәмиа’Ллаһу лимән хәмидәһ” (Аллаһ Үзен мактаучыны ишетә) сүзләрен әйтү, бу сүзләр имам тарафыннан гына, шулай ук намазны ялгыз укучы тарафыннан әйтелә;

3. Бөтен кеше тарафыннан: “Раббәнә уә ләкәлхәмд” (Әй Раббым, сиңа гына мактау!) сүзләренең әйтелүе;

4.Рөкүгъта “Субхәнә раббиәл-газыйм” (Бөек Рабым барча кимчелектән пакь!) сүзләрен әйтү;

5. Сәҗдәдә “Субхәнә раббиәл-әгълә” (Иң югары булучы Раббым барча кимчелектән пакь) сүзләрен әйтү;

6. Ике сәҗдә арасында “Рабби-гъфирли” (Раббым, гафу ит мине!) сүзләрен әйтү;

7. Беренче тәшәххуд;

8. Беренче тәшәххуд вакытында утыру.

## Мөһим искәрмә

Рөкүгъ вакытында “Субхәнә раббиәл-газыйм” сүзләрен нәкъ менә шул рәвешле бер тапкыр гына булса да әйтү  мәҗбүри, шуннан соң башка төр зикерләрне өстәргә мөмкин; шулай ук сәҗдә вакытында “Субхәнә раббиәл-әгълә” сүзләрен нәкъ менә шул рәвешле бер тапкыр гына булса да әйтү мәҗбүри, шуннан соң башка төр зикерләрне өстәргә мөмкин.

# Тугызынчы дәрес

## Тугызынчы дәрес: Тәшәххуднең аңлатмасы

Тәшәххуд шушы рәвешле башкарыла:

التَّحِيَّاتُ لِلَّهِ، وَالصَّلَوَاتُ، وَالطَّيِّبَاتُ، السَّلاَمُ عَلَيْكَ أَيُّهَا النَّبِيُّ وَرَحْمَةُ اللَّهِ وَبَرَكَاتُهُ، السَّلاَمُ عَلَيْنَا وَعَلَى عِبَادِ اللَّهِ الصَّالِحِينَ. أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّداً عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ

“Барлык салаватлар һәм иң яхшы мактау сүзләре Аллаһка гына! Әй пәйгамбәр, сиңа Аллаһның рәхмәте, сәламе һәм бәрәкәте булсын! Безгә дә һәм Аллаһның башка изге-салих колларына да сәламнәр булсын! Хакыйкатьтә, Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы илаһ юк дип шаһитлык кылам һәм хакыйкатьтә, Мөхәммәд Аның колы һәм рәсүле дип шаһитлык кылам!” [6].

Шуннан соң пәйгамбәребезгә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) салават әйтелә:

اللهم صل على محمد، وعلى آل محمد؛ كما صليت على إبراهيم وعلى آل إبراهيم، إنك حميد مجيد،اللهم وبارك على محمد، وعلى آل محمد؛ كما باركت على إبراهيم، وعلى آل إبراهيم، إنك حميد مجيد

“Әй Аллаһ! Ибраһимга һәм аның әһле-бәйтенә салаватларың булган кебек, Мөхәммәдкә һәм аның әһле-бәйтенә дә салаватларың булсын, дөреслектә, Син Мактаулы һәм Данлыклы! Әй Аллаһ! Ибраһимга һәм аның әһле-бәйтенә бәрәкәтең булган кебек, Мөхәммәдкә һәм аның әһле-бәйтенә дә бәрәкәтең булсын, дөреслектә, Син Мактаулы һәм Данлыклы!” [7].

Соңыннан, соңгы тәшәххуд вакытында, намаз укучы Җәһәннәм уты, кабер газапларыннан, дөньялыкта һәм бакыйлыктагы сынаулардан һәм коткыга бирелүләрдән, Дәджәл коткысыннан Аллаһка сыена. Шуннан соң намаз укучыга дога, бигрәк тә шәригатьтә килгән дога-зикер сүзләрен сайлап алып әйтергә тәкъдим ителә. Мәсәлән: *“Ий Аллаһ, Сине иң яхшы сыйфатта зикер итәргә вә Сиңа гына гыйбадәт кылырга миңа ярдәм ит”*, *«Ий Аллаһ, мин үземә күп золым кылдым, һәм гөнаһларны Синнән башка һичбер ярлыкаучы юктыр, мине ярлыкагыл, бары тик Син генә ярлыкаучы вә рәхмәт итүчесең!”*. Беренче тәшәххудкә килгәндә исә, намаз укучы ике шәһәдәтне әйткәннән соң Зухр (Өйлә), Гаср (Икенде), Мәгъриб (Ахшам), Иша (Ястү) намазларының өченче рәкәгатенә торып басарга тиеш. Әгәр намаз укучы өченче рәкәгатькә басканчы пәйгамбәребезгә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) салават әйтсә, бу темага җыелган хәдисләргә муафыйк рәвештә яхшырак була.

# Унынчы дәрес

## Унынчы дәрес: Намазның сөннәтләре

Намазның сөннәтләре шулар:

1. Намаз башындагы дога (әл-истифтах);
2. Рөкүгъка кадәр басып торганда һәм рөкүгътан торып баскач та уң кул чугын сул кул чугы өстенә кue;
3. Бармакларны бер-берсе белән тоташтырып һәм турайтып, кулларны җилкәләр яки колаклар биеклегенә күтәрү. Намазны ачучы беренче тәкбирдә, рөкүгъка киткәнче һәм аннан торып баскач, беренче тәшәххудтән соң өченче рәкәгатькә торып басканда да шул рәвешле эшләнә;
4. Рөкүгътагы “Субхәнә раббиәл-газыйм” һәм сәҗдәдәге “Субхәнә раббиәл-әгълә” сүзләрен бер тапкыдан артык әйтү;
5. Рөкүгътан соң басып торган вакытта “Раббәнә уә ләкәлхәмд” сүзләренә өстәмә рәвештә башка зикерләр, шулай ук ике сәҗдә арасында әйтелүче “Рабби-гъфирли” сүзләрен бер тапкырдан күбрәк әйтү;
6. Рөкүгъ вакытында башның арка турысында булуы;
7. Сәҗдә вакытында куллар ян-яклардан ерагайтылган (ягъни тәнгә тиеп тормаска тиеш), корсакның ботлардан, ә ботларның балтырлардан ерак булуы;
8. Сәҗдә вакытында терсәкләрнең җирдән бераз күтәрелгән булуы;
9. Беренче тәшәххуд вакытында һәм ике сәҗдә арасында җирдә яткан һәм үзеңә таба бөкләнгән сул аяк табаны өстендә, ә уң аякның табанын вертикаль рәвешкә китереп һәм аның бармакларын Кыйбла ягына каратып утыру;
10. Өч яки дүрт рәкәгатьтән торган намазларның соңгы тәшәххудләрендә “тауаррук” халәтендә утыру. Бу вакытта намаз укучы сул аягын уң аяк астына кертеп һәм уң аяк табанын вертикаль рәвешкә китереп, сул ботына утыра;
11. Беренче һәм икенче тәшәххудләрдә, намаз укучы тәшәххуд уку өчен утырган мизгелдән алып аны укып бетергәнчегә кадәр, аның уң кулының имән бармагы күрсәтү халәтендә булуы һәм намаз вакытында әлеге бармагы белән хәрәкәт башкаруы;
12. Беренче тәшәххудтә Аллаһка Мөхәммәд һәм аның гаиләсенә, Ибраһим һәм аның гаиләсенә салават һәм бәрәкәт сорап үтенеч белән мөрәҗәгать итү;
13. Соңгы тәшәххудтә сәлам сүзләрен әйткәнче Аллаһка дога белән мөрәҗәгать итү;
14. Иртәнге, җомга, бәйрәм намазларын укыганда, шулай ук, яңгыр сорап намаз укыганда Коръәнне кычкырып уку. Ахшам һәм Ястү намазларының беренче ике рәкәгатендә Коръәнне кычкырып уку;
15. Өйлә һәм Икенде намазлары вакытында, шулай ук Ахшам намазының өченче һәм Ястү намазының соңгы ике рәкәгатендә Коръәнне эчтән генә уку;
16. “Әл-Фатиха” сүрәсеннән тыш, Коръәннән тагын нәрсә дә булса уку.

Болардан тыш, Сөннәттә килгән калган гамәлләрне үтәү дә мәслихәт. Бирегә, мәсәлән, рөкүгътан турайганда әйтелә торган “Раббәнә уә ләкәлхәмд” сүзләренә өстәмә рәвештә башка зикерләр өстәү кирә. Бу имам артына басып намаз укучыга да, имамга да, ялгыз намаз укучыга да мәслихәт. Бирегә шулай ук рөкүгъ вакытында кул чукларын, бармакларны җәйгән хәлдә, тезләргә кую да кирә.

## Намаз башындагы дога (әл-истифтах)

Бу дога намазны ачучы тәкбирдән соң ук әйтелә. Ул пәйгамбәребездән (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) килгән рәвешле итеп укыла: “Аллаһуммә, бә'ид бәйни вә бәйнә хатәйәйә кә-мә бә'әдта бәйнә-л-мәшрики вә-л-мәгъриби, Аллаһуммә, нәккый-ни мин ха-тәйәйә кә-мә йунәкка-с-саубу-л-әбйәду мин әд-данәси, Аллаһуммагсиль-ни мин хатәйәйа би-с-салҗи, вә-л-мәи вә-льбәради» [8], яки: «Субхәнә-кә, Аллаһуммә, вә бихәмди-кә, вә табәракә-сму-кә вә тә'әлә җәдду-кә вә лә иләһә гайру-ка» [9]

# Унберенче дәрес

**Унберенче дәрес: НАМАЗНЫ БОЗУЧЫ ГАМӘЛЛӘР**

Алар сигезәү:

1. Тыелганын белә торып һәм истә тотып, нәрсәдер сөйләү. Онытылу яки белмәү сәбәпле сөйләү очрагы намазны бозмый; 2. Көлү; 3. Ашау; 4. Эчү; 5. Гаурәт урыннар ачылу; 6. Кыйбладан шактый ук авышу; 7. Бик күп кирәкмәгән дәвамлы эш-гамәлләр кылу; 8. Тәһарәт бозылу.

**Беренче гамәл:** Тыелганын белә торып һәм истә тотып, нәрсәдер сөйләү.

Хата ясаган булса, имамны төзәтү бу кагыйдәдән чыгарма булып тора.

## Намаз вакытында хәрәкәт төрләре:

| Тыелган хәрәкәтләр: | Житди кисәтүгә лаек хәрәкәтләр: | Рөхсәт ителгән хәрәкәтләр: | Кирәкле хәрәкәтләр: | Фарыз хәрәкәтләр: |
|---|---|---|---|---|
| хаҗәтсез бик күп һәм кирәкмәгән дәвамлы эш-гамәлләр кылу. | Хаҗәтсез кечкенә генә хәрәкәт эшләү, мәсәлән, аз гына борылу. | Хаҗәт булганда аз гына хәрәкәтләр ясау, мәсәлән, сакалны кашып алу. | Бу хәрәкәтләргә намазның сыйфаты бәйле, мәсәлән, рәттә урын алу. | Бу хәрәкәтләргә намазның дөреслеге бәйле, мәсәлән, нәҗесләрдән чистарту. |

## Мөһим искәрмә

Намазның шартлары, әркәннәре,  фарызлары һәм сөннәтләре арасында аерма нидә?

<table>
<tr><th>Шарт</th><th>Әркән</th><th>Фарыз</th><th>Сөннәт</th></tr>
<tr><td>Гыйбадәт чикләре артында</td><td colspan="3">Гыйбадәтнең асылына керә</td></tr>
<tr><td>Бөтен гыйбадәт буена дәвам итә</td><td colspan="3">Гыйбадәт өлешләренең берсе булып тора</td></tr>
<tr><td colspan="2">Аны калдыру, аның ничек (белеп, белмичә яки онытылып) эшләнүенә бәйсез рәвештә гафу ителми</td><td>Аны белмичә һәм онытылып калдыру гафу ителә, бары белеп эшләмәү генә гафу ителми.</td><td>Аны калдыру, аның ничек (белеп, белмичә яки онытылып) эшләнүенә бәйсез рәвештә гафу ителә</td></tr>
<tr><td>Шартлар өчен житешсезлекне төзәтү өчен кылына торган сәһү сәҗдәсе каралмаган</td><td>Житешсезлекне төзәтү өчен кылына торган сәһү сәҗдәсе белән төзәтеп булмый.</td><td>Житешсезлекне төзәтү өчен кылына торган сәһү сәҗдәсе белән төзәтеп була.</td><td>-</td></tr>
</table>

**Сәһү сәҗдәсе**

Җитешсезлекне төзәтү өчен сәһү сәҗдәсе кылыну сәбәпләре өчәү:

**Артык хәрәкәт:**

Мәсәлән, намаз укучы артык рәкәгать яки артык сәҗдә һәм башка шундыйларны кылса.

**Төшереп калдыру:**

Мәсәлән, әгәр кеше намаз фарызларының берсен төшереп калдырып, башка хәрәкәткә күчсә.

**Шик:**

Мәсәлән, әгәр намаз укучы үзенең ничә (өчме, дүртме) рәкәгать укыганлыгында шикләнсә. Шик ике төрле була:

**Гыйбадәтне кылып тәмам иткәч туган шик:**

Гыйбадәттә хата киткәнлеккә һич шикләрсез инану булмыйча торып, мондый шикләргә игътибар итәргә кирәк түгел.

**Гыйбадәт вакытында туган шик:**

Мондый шикләр еш булса, аларга игътибар итәргә ярамый. Әгәр шикләр сирәк туса, мондый очракларда кеше үзе нинди фикергә авышса, шуңа нигезләнә. Әгәр фикерләрнең кайсысына авышырга да белмәсә, бу очракта ул аз санга нигезләнә.

**Искәрмәләр:**

- Әгәр намаз укучы сәһү сәҗдәсен ясаган вакытта хата җибәрсә, өстәмә сәҗдәләр кылу кирәк түгел, аның намазы дөрес була;

- Әгәр намаз укучы намазның бер әркәнен үтәмәсә, шул әркәнне һәм аннан соң килгән гамәлләрне үтәгәнчегә кадәр аның намазы дөрес булмаячак. Шуннан соң ул намаз ахырында сәһү сәҗдәсен кылырга тиеш;

- Әгәр намаз укучы онытылып китеп фарыз хәрәкәтне башкармыйча, алдагы хәрәкәткә күчсә, намаз ахырында сәһү сәҗдәсен кылу җитә.

## Намазның кыскача тасвирламасы:

- Беренче чиратта кеше өендә пакьланырга һәм иң яхшы киемен киярgә тиеш;

- Шуннан соң ул мәчеткә бара (җәяү яки транспортта). Шул ук вакытта аның хәрәкәтләре тыныч, ә үзенең кыяфәте лаек булырга тиеш, ягъни ул ашыгырга, йөгерергә, еш борылып карарга яки тавышын күтәрергә тиеш түгел;



- Мәчеткә кергәч, ул аяк киемнәрен сала, аларны махсус аяк киемнәре өчен билгеләнгән урынга куя, һәм аяк киемнәре белән бергә ул дөнья тормышын мәчетнең тышында калдыра. Мәчеттә сату-алу белән шөгыльләнү, шулай ук югалган әйберне тавыш күтәреп эзләү тыелган;

- Мәчеткә ул уң аягы белән, зикер әйтеп керә: *“Бисми Лләһи, вә-с-саләту вә-с-саләму гәлә расули-Лләһи. Аллаһуммә-фтах ли әбвәбә рахмәти-кә”* [10], чыкканда исә сул аягы белән чыга һәм ошбу сүзләрне әйтә: *“Би-сми Лләһи, вә-ссаләту вә-с-саләму гәлә расули-Лләһи. Аллаһуммә инни әс-әлүкә мин фәдликә»* [11];

- Ир-атлар беренче рәткә, хатын-кызлар соңгы рәткә омтылырга тиешләр;

- Әгәр намаз башланган булса, соңга калучы кеше намазны ачучы тәкбирне (“Аллаһу әкбәр” сүзләре) әйтергә һәм, имам нинди генә халәттә булмасын, намазга кушылырга тиеш. Әгәр кеше намазга имамның “Әл-Фатиха” сүрәсе укыла торган басып тору халәтендә яки рөкугъта булган вакытында килеп кушылса, рәкәгать төгәлләнгән санала. Имам намазны тәмам иткәннән соң, соңга калган кеше торып басып өлгерми калган рәкәгатьләрне укып бетерергә тиеш.

Әгәр ул мәчеткә керсә һәм әле намаз башланмаган булса, ул, бу фарыз намазы алдыннан укылучы өстәмә намазны укый. Әгәр андый өстәмә намаз булмаса, ул, утырганчы, мәчетне сәламләү намазын үтәргә тиеш;

- Ул үзенең һаман сәгатькә карап алу, намазны тизрәк башласыннар дигән ишарә белән тамак кырып кую кебек гамәлләре белән мәчетнең изгелеген бозарга тиеш түгел;


- Имам һәм ялгыз гына намаз укый торган кеше алдында киртә (сутра) булса әйбәт. Имам артыннан намаз укучының киртәсе булып исә имамның киртәсе хезмәт итә;




- Намаз укучы аякларын җилкәләре киңлегендә куя һәм аларны тышкы яктан тигезли;



- Намаз укучы намазның барлык шартларын да үтәгәч, “Аллаһу әкбәр” дип намазга керү тәкбирен әйтә. Бу сүзләрне әйткәндә, бармакларны бер-берсе белән тоташтырып һәм уч төпләрен Кыйбла тарафына юнәлтеп, кулларны җилкәләр яки колаклар биеклегенә күтәрә;



- Шуннан соң ул, уң кул чугын сул кул чугының аркасына, шулай ук беләзеккә һәм беләкләргә куя, яки уң кулы белән сул кулының беләзеген тота;



- Намаз укучы үзенең күз карашын сәҗдә урынына юнәлтә һәм намаз вакытында читкә борылмый;



- Соңыннан, тәкбирдән соң, намаз башында укылучы зикерләр (әл-истифтах) укылса, яхшы була. Төрлелек өчен, Сөннәттә килгән башка зикерләр укылса, тагын да әйбәтрәк була;

- Шуннан соң намаз укучы *“Әгузу би-Лләһи минәш-шәйтанир-ражим”* (истигәзә) сүзләрен әйтеп, Аллаһның яклавына сыена;

- Шуннан соң: *“Би-сми-Лләһи әр-Рахмәни әр-Рахим*” сүзләрен әйтә;


- Шуннан соң ул *“Фатиха”* сүрәсен, бер генә аятен дә төшереп калдырмыйча, тулаем укый. Аятьләрне бер-бер артлы, рәттән, хәрефләрне, хәрәкәләрне, сүзләрне дөрес итеп әйтеп уку шарт;

- “*Фатиха*”дан соң “*Коръән*”нән тагын нәрсә булса да уку әйбәт. Бу очракта истигәзә әйтелми һәм әгәр уку сүрә башыннан башланса, бу очракта “Би-сми-Лләһи әр-Рахмәни әр-Рахим” сүзләрен әйтү кирәк;

- Шуннан соң намаз укучы, беренче тәкбирдәге кебек итеп: “Аллаһу әкбәр”, - ди һәм рөкүгъка китә;

- Намаз укучы кулларын тезләренә куя, бу вакытта куллар терсәкләрдән бөгелми. Аның аркасы исә башы белән бер турыда булырга тиеш;

- Ул мәҗбүри рәвештә бер генә тапкыр булса да “Субхәнә раббиәл-газыйм” сүзләрен әйтергә тиеш, аннан соң Сөннәттә килгән башка зикер һәм догаларны өстәп әйтсә ярый;



-Шуннан соң рөкүгътан турайган вакытта, тураеп беткәнче, намаз укучы *“Сәмиа’Ллаһу лимән хәмидәһ”* сүзләрен әйтә;

- Шуннан соң тулысынча тураеп беткәч, ул: *“Раббәнә уә ләкәлхәмд”,* - ди. Шуннан соң ул Сөннәттә килгән башка зикер-догаларны әйтсә, яхшы була;

- Моның соңында ул: “Аллаһу әкбәр”, - ди һәм тәннең җиде өлеше: маңгай белән борын, уч төпләре, тезләр һәм ике аяк бармакларының эчке өлешләре белән сәҗдә кыла;

- Сәҗдә вакытында намаз укучы кулларын ян-яклардан (ягъни алар тәңгә тиеп тормый), корсакны ботлардан, ә ботларны балтырлардан ерагайта, шулай ук терсәкләрне җирдән күтәрә;



- Ул мәҗбүри рәвештә бер тапкыр гына булса да *“Субхәнә раббиәл-әгълә”* сүзләрен әйтә, аннан соң Сөннәттә килгән башка зикер һәм догаларны өстәп әйтсә ярый, шулай ук ул әгәр теләсә, башка дога сүзләрен әйтә ала, әмма ул Аллаһка пәйгамбәребездән (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) килгән сүзләр белән мөрәҗәгать итсә, тагын да яхшырак була;

- Шуннан соң ул *“Аллаһу әкбәр”,* - ди һәм җирдә яткан һәм үзенә таба бөкләнгән сул аяк табаны өстенә, ә уң аякның табанын вертикаль рәвешкә китереп һәм аның бармакларын Кыйбла ягына каратып утыра, кулларын ботларының тезләргә якын өлешенә куя – шул рәвешле бөтен намазларда да утырыла. Бары өченче һәм дүртенче рәкәгатьләрдә генә “тауаррук” халәтендә – сул аягын уң аяк балтыры астына кертеп утыру кирәк;



- Утырып торудан соң намаз укучы *“Аллаhу әкбәр”,* - дип әйтә һәм беренче тапкырдагы кебек үк сәҗдә кыла;

- Шуннан соң ул *“Аллаhу әкбәр”,* - дип әйтә һәм икенче рәкәгатькә торып баса. Аны беренче рәкәгать кебек үк үти, ләкин икенче рәкәгатьтә намазны ачучы тәкбир әйтелми һәм “истифтах” догасы кылынмый;

- Намаз укучы икенче сәҗдәдән күтәрелеп, “тәшәххуд” кылу өчен утыра;

- Уң кулының имән бармагын Кыйбла ягына юнәлтә һәм, ә урта һәм баш бармакларын боҗра итеп тоташтыра;


- Бу вакытта ул мәҗбүри рәвештә “тәшәххуд” сүзләрен әйтә;

- Әгәр намаз ике рәкәгатьтән торса, намаз укучы шулай ук мәҗбүри рәвештә пәйгамбәребезгә (Аллаhның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) дога-салаватлар әйтә;

-Шуннан соң ул Аллаһтан дүрт бәладан: Җәһәннәм газапларыннан, кабер газабыннан, дөнья һәм үлем фетнәсеннән, Дәджәл коткысыннан саклану сорый *(Аллаһуммә инни ә'узубикә мин 'әзаби джәхәннәм, уа мин 'әзабиль-къабр, уа мин фитнәтиль-мәхья уәль-мәмәт, уә мин шәрри фитнәтильмәсихи-ддәджҗәл)* [12], шуннан соң намаз укучы Аллаһка башка дога сүзләре белән мөрәҗәгать итә ала, әмма ул Аллаһка пәйгамбәребездән (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) килгән сүзләр белән мөрәҗәгать итсә, тагын да яхшырак була, мәсәлән: "Йә Аллаһ, тиешле дәрәҗәдә Сине зикер кылырга, Сиңа шөкер итәргә һәм Сиңа гыйбадәт кылырга ярдәм ит миңа!" (*Аллаһуммә, ә'ин-ни 'әлә зикри-кә, вә шукри-кә вә хусни 'ибәдәти-кә*);



-Шуннан соң ул уң якка да, сул якка да сәлам бирә, сәлам биргән вакытта җилкәләр борылмый, бары тик баш кына борыла (баш күтәрелми дә, төшерелми дә) һәм ян-якларга куллар белән күрсәтелми;



-Әгәр намаз өч яки дүрт рәкәгатьтән торса, бу очракта намаз укучы беренче “тәшәххудне” укыганнан соң торып басарга тиеш, ләкин башта пәйгамбәребезгә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) салават әйтү яхшырак булачак;

- Аңа тәкбир әйтергә һәм, әгәр намаз өч рәкәгатьле булса, өченче рәкәгатьне башкарып, “тәшәххуд” уку өчен утырырга кирәк. Әгәр намаз дүрт рәкәгатьле булса, ул өченчедән соң дүртенче рәкәгатькә торып баса, бары шуны укыганнан соң гына соңгы «тәшәххуд»не уку өчен утыра;

- “Тәшәххуд”не укыганнан соң ул пәйгамбәребезгә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) салаватлар әйтә, аннан соң ул Аллаһтан дүрт бәладан: Җәһәннәм газапларыннан, кабер газабыннан, дөнья һәм үлем фетнәсеннән, Дәджәл коткысыннан саклану сорый (*Аллаһуммә инни ә’узубикә мин ‘әзаби джәһәннәм, уа мин ‘әзабиль-къабр, уа мин фитнәтиль-мәхья уәль-мәмәт, уә мин шәрри фитнәтильмәсихи-ддәджҗәл)* [12], шуннан соң намаз укучы Аллаһка башка дога сүзләре мөрәҗәгать итә ала, әмма ул Аллаһка пәйгамбәребездән (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) килгән сүзләр белән мөрәҗәгать итсә, тагын да яхшырак була, мәсәлән: “Йә Аллаһ, тиешле дәрәҗәдә Сине зикер кылырга, Сиңа шөкер итәргә һәм Сиңа гыйбадәт кылырга ярдәм ит миңа!” *(Аллаһуммә, ә'ин-ни 'әлә зикри-кә, вә шукри-кә вә хусни ’ибәдәти-кә);*

- Әгәр бу фарыз намазы булса, аннан соң зикер кылу кирәк;

- *“Әстәгфиру-Ллаһ (өч тапкыр), Аллаһуммә, Әнтә-с-Саләму вә мин-кә-с-саләму, тәбәрактә, йа Зә-ль-джәләли вә-льикрам»*, - диелә [13];

- Шуннан соң намаз укучы утыз өчәр тапкыр: “Субхәнал-Ллаһ”, “Әлхәмду лиЛләһ”, “Аллаһу әкбәр” сүзләрен, ә йөзенчегә: “Лә иләһә иллә Ллаһу вәхдә-ху лә шәрикә ләһ, ләхуль-мульку ә ләхуль-хәмду вә хувә 'әлә кулли шәйин кадир” [14], - дип әйтә;

- Шуннан соң “Аятелкөрси”не, шулай ук “Әл-Ихлас”, “Әл-Фәләк” һәм “Ән-Нәс» сүрәләрен укыса әйбәт.

## Мөһим искәрмәләр:

-Гаурәт җирләрне каплау – намаз дөрес булсын өчен мөһим бер шарт булып торуы хакында әйткән идек инде, шуңа күрә намаз укучы намаз вакытында гаурәт урыннарның ачылуыннан сакланырга тиеш, чөнки гаурәт урыннар ачылу намазның яраксыз булуына сәбәп була;





-Әгәр кеше намазны имам янәшәсендә башкарса, бу очракта ул имамның уң ягына баса һәм аяк табаннарын имамның табаннары белән бер тигезлектә куя, имамнан алга чыгу да, артка китү дә ярамый. Җәмәгать белән намаз укыганда башкалар белән бер рәткә басканда да, кеше шул рәвешле үк баса.



## Намаз хакында кыскача

| Намазның исеме | Хөкеме | Вакыты | Рәкәгатьләр саны | Тасвирламасы |
|---|---|---|---|---|
| Җомга намазы | Фарыз | Өйлә вакыты | 2 | Өч һәм аннан да күбрәк ир-аттан торган җәмәгать белән кычкырып укыла. |
| Ай, кояш тотылу намазы (кусуф) | Җәмәгать бурычы (фарыз кифая) | Ай, кояш тотылган вакыт. | 2 | Кычкырып укыла һәр рәкәгатьтә ике рөкүгъ ясала. |
| Витр | Аеруча кирәкле (сөннәт муәккадә) | Ястү намазыннан алып иртәнге намазга кадәр бара | 1-11 | - Бер рәкәгать;<br>- Өч рәкәгать, бу очракта тәшәххуде бер була һәм өченче рәкәгатьтә үтәлә. Яки ике рәкәгать укылып, сәлам белән намаз тәгәлләнә, һәм тагын бер рәкәгать укыла.<br>- Биш рәкәгать, бу очракта тәшәххуде бер була һәм бишенче рәкәгатьтә укыла;<br>- Җиде рәкәгать, бу очракта тәшәххуде бер |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | була һәм жиденче рәкәгатьтә укыла;<br>- Тугыз рәкәгать, бу очракта тәшәххуде сигезенче рәкәгатьтә була, әмма намаз сәлам белән төгәлләнми, соңыннан тугызынчы рәкәгатьне үтәгәч, тәшәххуд һәм сәлам әйтелә.<br>- Ахырларында тәшәххуд булган икешәр рәкәгатьле намазлар, алар укылып беткәч, калган бер так рәкәгать укыла. |
| Иртәнге намазның сөннәте | Аеруча кирәкле (сөннәт муәккадә) | Иртәнге намаз алдыннан | 2 | Беренче рәкәгатьтә “Әл-Кәфирун”, икенче рәкәгатьтә “Әл- Ихлас” сүрәләрен уку мәслихәт. |
| Өйлә намазының сөннәте | Сөннәт | Дүрт рәкәгате өйләгә кадәр, икесе өйләдән соң | 4/2 | Дүрт рәкәгать ул икешәр рәкәгатьле сәлам белән аерылган ике намаз |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Ахшам намазының сөннәте | Сөннәт | Ахшам намазыннан соң | 2 | Беренче рәкәгатьтә “Әл-Кәфирун”, икенче рәкәгатьтә “Әл- Ихлас” сүрәләрен уку мәслихәт. |
| Ястү намазының сөннәте | Сөннәт | Ястү намазыннан соң | 2 | |
| Тәравих намазы | Сөннәт | Ястү намазыннан алып иртәнге намазга кадәр бара. | 2-20 | |
| Мәчетне сәламләү намазы | Аеруча кирәкле (сөннәт муәккадә) | Мәчеткә кергәч, утырганчы | 2 | |
| Духа намазы | Сөннәт | Кояш горизонт сызыгыннан сөңге буе күтәрелгәч башлана, һәм кояш зәүвәлгә | 2-8 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | керергә бераз вакыт калгач тәмамлана | | |
| Истихара намазы | Сөннәт | Теләсә-кайсы вакытта | 2 | Сәлам биргәнче “Әл-Истихара” догасын укырга кирәк(сәләм биргәчтә ярый) |
| Истиска (Яңгыр сорау) намазы | Ихтыяж булса, Сөннәт | Кояш горизонт сызыгыннан сөңге буе күтәрелгәч башлана | 2 | Беренче рәкәгатьтә, намазны ачучы тәкбирне дә кертеп, җиде тапкыр тәкбир әйтергә кирәк. Икенче рәкәгатьтә исә беренче рәкәгатьтән икенчесенә күчкәндә әйтелә торган тәкбирдән соң (әл-Интикаль) биш тәкбир әйтелә. |
| Гает намазлары | Фарыз | Кояш горизонт сызыгыннан сөңге буе күтәрелгәч башлана | 2 рәкәгать һәм 2 хөтбә | Беренче рәкәгатьтә, намазны ачучы тәкбирне дә кертеп, җиде тапкыр тәкбир әйтергә кирәк. Икенче рәкәгатьтә исә беренче рәкәгатьтән икенчесенә күчкәндә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | әйтелә торган тәкбирдән соң (әл-Интикаль) биш тәкбир әйтелә. |

**Билгеле булмаган (сәбәбе булмаган) өстәмә намазлар уку тыелган вакытлар:**

1. Иртәнге намаздан алып кояш горизонт сызыгыннан сөңге буе күтәрелгәнчегә кадәр булган вакыт;

2. Икенде намазыннан соң Ахшам намазына кадәр булган вакыт;

3. Кояш зәүвәлдә булган вакыттан алып аның көнбатышка авыша башлаган мизгелгә кадәр вакыт.

# Намаз хакындагы бүлеккә кагылышлы белемнәрне тикшерү өчен сораулар

**1. Намазның ничә шарты бар?**

- Сигез;
- Унбер;
- Тугыз.

**2. “Ислам” дигән шартны намаз шартлары арасында телгә алу хаталы, чөнки намаз гыйбадәтен бары тик мөселманнар гына башкара.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**3. Тәмйиз – ул җенси өлгерү яше (балигъ булу).**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**4. Нәҗесләрне тәннән, киемнән һәм намаз уку урыныннан чистарталар.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**5. Дуңгыз нәҗесе ул нинди нәҗес?**

- Авырайтылган;
- Уртача;

**6. Мәни – нәҗес, шуңа күрә ул чыкканнан соң, госел коену мәҗбүри.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**7. Киемне чылату һәм юу арасында аерма юк.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**8. Бөтен үләксә дә нәҗес.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**9. Этнең нәҗесеннән чистарыну өчен җир урынына заманча химик чаралар кулланырга ярый.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**10. Сакланырга кыен булган хайваннар – алар кешеләр белән катышкан хайваннар. Шулай итеп, кайбер кешеләр өчен мәче чиста, ә кайбер кешеләр өчен нәҗес булачак.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**11. Хайваннарның кан тамырында калган кан нинди?**

- Чиста;
- Нәҗес.

**12. Намазның ничә әркәне бар?**

- Ундүрт;
- Тугыз;
- Сигез.

**13. Тәкбиратуль-ихрам – ул кулларны күтәрү.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**14. Әгәр кеше онытылып китеп намазның бер әркәнен үтәмәсә, ул ике сәһү сәҗдәсе кылырга тиеш.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**15. Намазда ничә мәҗбүри хәрәкәт бар?**

- Ундүрт;
- Тугыз;
- Сигез.

**16. Әгәр намаз укучы кеше сәҗдә вакытында “Субхәнә раббиәл-әгъләү” сүзләрен бер тапкыр гына булса да әйтү мәҗбүри икәнен белеп, аны әйтмичә башка зикерләр әйтсә, аның намазы дөрес түгел.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**17. Намаз укучы кеше уң кул чугын сул кул чугы аркасына, шулай ук беләзеккә һәм беләкләргә куя.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**18. Намазда, әгәр ул төнлә укыла торган намазның беренче ике рәкәгате булса, шулай ук ике бәйрәм намазы кебек җәмәгать белән укыла торган һәрбер намазда Коръән кычкырып укыла.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**19 . Намазны яраксыз итә торган ничә гамәл бар?**

- Ундүрт;
- Тугыз;
- Сигез.

**20. Намаз укучы “тауаррук” халәтенә кайчан утыра?**

- Беренче тәшәххудтә;
- Икенче тәшәххудтә;
- Бөтен җаваплар да дөрес.

**21. “Раббәнә уә ләкәл-хәмд” сүзләреннән соң “уә-ш-шукр” (һәм шөкерләр) дип әйтү:**

- Рөхсәт ителгән;
- Хәерле эш;
- Тыелган.

**22. Сәҗдә вакытында терсәкләрне идәнгә кую:**

- Тыелган;
- Үтәү тиеш;
- Шелтәләнә.

**23. Сәҗдә әс-сәһү кылу өчен булган сәбәпләр ничәү?**

- Ике;
- Өч;
- Дүрт.

**24. Гыйбадәттән соң булган шикләр бернәрсәгә дә тәэсир итми, хәтта алар бик күп булсалар да.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**25. Иртәнге намазның сөннәте башка намазлардан фазыйләте, җиңеллеге (ягъни кыскалыгы), кайбер сүрәләрнең үзенчәлекле укылуы, юлда булганда кылынуы, өйдә булганда бу намаздан соң ятып торырга кирәклек белән аерылып тора.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**26. Ошбу очракларга карата шәригать хөкемнәрен аңлат:**

| Сорау/билгеле бер очрак | Хөкеме |
|---|---|
| Динне хурлаган кешенең намазы | |
| Исерек кешенең намазы | |
| Альцгеймер авырулы кешенең намазы | |
| Баланың намазы | |
| Кеше, тәһәрәт алырга онытып, намазын укыса | |
| Кеше, киемендә нәҗес барлыгын онытып, намаз укыса | |
| Сыер бәвеле | |
| Карга бәвеле | |
| Кеше ботларын капламыйча намаз укыса | |
| Кеше, онытылып, вакыты кермичә намаз укыса | |
| Самолетта очканда намаз ничек укыла? | |
| Кеше әлеге вакытның намазын | |

| | |
|---|---|
| укырга ниятләсә, әмма кайсы намаз икәнлеген конкрет итеп билгеләмәсә | |
| Кеше намазын утырып укыса | |
| Намазда Фатихә сүрәсен укырга онытса | |
| Намазга имам рөкүгъта булганда килеп кушылса | |
| Намаз укыганда ашыгычлык | |
| Намаз укыганнан соң туган күптөрле шикләр | |
| Кеше, намазга керешкәч, тәһарәтенең дөреслегендә шикләнсә | |
| Онытылып, артык рөкүгъ ясаса | |
| Намазны ачучы тәкбирне әйтмәсә | |
| Беренче тәшәххудне эшләмәсә | |
| Соңгы тәшәххудне эшләмәсә | |
| Кеше, намаз вакытында ничә рәкәгать: өчме, я дүртме рәкәгать укуында шикләнсә | |
| Бу хакта намаздан соң шикләнсә | |
| Намаз уртасына җиткәч туган шикләр | |
| Сәһү сәҗдәсендә хата җибәрсә | |
| Онытылып намазда сөйләшсә | |
| Намазны гаурәтен capламыйча укып, бу хакта намаз тәмам булгач белсә | |
| Мәчеткә намазга барыр алдыннан өйдә тәһәрәт алу | |
| Мәчеттә сәүдә | |
| Мәчеттә валюта алыштыру | |

| | |
|---|---|
| Имам соңгы тәшәххудне укыган вакытта намазга килеп кушылу | |
| Намаз укый торган кеше алдында киртә (сутра) булу | |
| Намазда гәүдәне бераз бору | |
| Намазда күп боргалану | |
| Җим чүпләгән этәч сыман намазны тиз уку | |
| Тәшәххудтә пәйгамбәребезгә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) салават әйтү | |
| Намазда сөйләшү | |
| Намазда хәрәкәтләр | |
| Җомга намазы | |
| Витр намазы | |
| Мәчетне сәламләү намазы | |

**27. Намазның шартлары, әркәннәре, фарызлары һәм сөннәтләре арасында нинди аерма бар?**

| Шарт | Әркән | Фарыз | Сөннәт |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Уникенче дәрес

## Уникенче дәрес: ТӘҺӘРӘТНЕҢ ШАРТЛАРЫ

Тәһәрәтнең шартлары унау: 1. Ислам динен тоту; 2. Гакыл; 3. Аера алу яшенә ирешү (тәмйиз); 4. Ният; 5. Ниятне тәһәрәт алу дәвамында саклау, ягъни тәһәрәт алучы тәһәрәтне алу тәмам булганчы аны бүлергә ниятләргә тиеш түгел; 6. Тәһәрәтне фарыз иткән барлык нәрсәләрнең тәмам булуы; 7. Тәһәрәт алганчы су яки кәгазь белән истинҗа кылу; 8. Суның чисталыгы һәм рөхсәт ителгәнлеге; 9. Суның тәнгә эләгүенә комачау итә торган нәрсәләрне бетерү; 10. Даими пычранган халәттә булучылар өчен намаз вакыты керү.

### Кайбер шартларның аңлатмасы:

- "Ниятне тәһәрәт алу дәвамында саклау, ягъни тәһәрәт алучы тәһәрәтне алу тәмам булганчы аны бүлергә ниятләргә тиеш түгел" – бу тәһәрәтне алу нияте аны ала башлаганнан алып тәмамлаганчыга кадәр булырга тиеш дигәнне аңлта;
- "Тәһәрәтне фарыз иткән барлык нәрсәләрнең тәмам булуы" – ягъни кеше, әйтик, кече йомышын башкарганда яки дөя итен ашаганда тәһәрәт ала башларга тиеш түгел. Тәһәрәтне ала башлаганчы аны бозучы гамәлне эшләүдән туктарга кирәк;
- "Тәһәрәт алганчы су яки кәгазь белән истинҗа кылу" – газ чыгу, йоклау, дөя итен ашау кебек тәһәрәт алу тиешле булган очраклардан тыш;
- "Суның чисталыгы һәм рөхсәт ителгәнлеге" – Ягъни тәһәрәт ала торган су нәҗесле һәм көч белән (урлап) алынган булырга тиеш түгел;
- "Суның тәнгә эләгүенә комачау итә торган нәрсәләрне бетерү" – мисал өчен, камыр яки тырнак буяу өчен лак, алар тәннең тәһәрәт алган вакытта юылырга тиешле өлешенә су эләгүенә комачау итәләр.

### Фитраның сөннәтләре

Фитра (кеше өчен табигый булган гамәлләр) сөннәтләренең кайберләре:

**1.** Сөннәткә утырту – ир-атлар өчен мәҗбүри, хаҗәт булганда хатын-кызларга да кирәкле эш ;

**2-5.** Мыекларны кыскарту, тырнакларны кисү, култык астындагы чәчләрне йолку, касык сөяге өлешен кыру. Әнәс, Аллаһ аннан риза булсын, әйткән: ***"Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) безгә кырык көнгә бердән дә ким булмаган тапкыр мыекларны кыскартуны, тырнакларны кисүне, култык астындагы чәчләрне йолкуны, касык сөяге өлешен кыруны әмер итте",*** – ягъни бу эшләрне башкаруны кырык көннән дә артыкка сузарга ярамый;

**6.** Сакал үстерү – мәҗбүри, ә аны кыру – иң зур гөнаһларның берсе булып тора;

**7.** Сивак куллану. Сивак – Ул Арак агачының тамыры яки шуңарга охшашлы теш чистарту өчен кулланыла торган нәрсә. Аны куллану кирәкле эш (сөннәт) һәм намаз, тәһәрәт, Коръән укыр алдыннан, өйгә кергәндә, йокыдан торганда, вафат булгач һәм авыздан начар ис килгәндә куллану зарурлыгы арта.

# Унөченче дәрес

## Унөченче дәрес: ТӘҺӘРӘТНЕҢ ФАРЫЗ (МӘҖБҮРИ) ӨЛЕШЛӘРЕ

Тәһәрәтнең мәҗбүри гамәләре алтау:

1. Битне юу, әлеге гамәлгә авызны чайкау һәм борынны юдыру да керә;
2. Терсәкләр белән бергә кулларны юу;
3. Колаклар белән бергә бөтен башны сыпыру;
4. Ашык сөягенә кадәр тубыктан тиң аякларны юу;
5. Эзлеклелекне саклау;
6. Бүленмәү.

Авызны чайкау, борынны юдырган кебек үк битне, кулларны һәм аякларны да өчәр тапкыр юу мөстәхәб(сөннәт). Боларның барысын да берәр тапкыр эшләү фарыз (мәҗбүри) булып тора. Башны сыпыруга килгәндә исә, дөрес хәдисләрдә килгәнчә, аны бер тапкырдан артык сыпыру кирәкмәгән эш.

### Эзлеклелекне саклау

Эзлеклелек шуннан гыйбарәт: тәннең бер өлешен юуны, аңа кадәр юылган өлеш кипкәнчегә кадәр, кичектереп тору ярамый.

Ундүртенче дәрес

## Ундүртенче дәрес: ТӘҺӘРӘТНЕ БОЗУЧЫ ГАМӘЛЛӘР

Тәһарәтне бозучы гамәлләр алтау:
1. Женси органнардан һәм аналь ачыклыктан бүлендекләр чыгу;
2. Тәннән пычрак чыгу;
3. Акылны югалту: бирегә йокы һәм башкалар керә;
4. Женси органга яки аналь ачыклыкка киртәләрсез (ягъни кием аркылы түгел) кул белән кагылу;
5. Дөя итен ашау;
6. Динне калдыру, мөртәтлек.

**Мөһим искәрмә:** мәет юуга килгәндә, башка дәлилләр булмау сәбәпле, дөресрәк фикер шул (бу гыйлем ияләренең күпчелегенең фикере): әлеге гамәл тәһәрәтне бозмый. Әмма юучы кешенең кулы киртәләрсез мәетнең женси органына яки аналь ачыклыгына тиеп китсә (ләкин болай эшләү ярамаган эш), аның тәһәрәте бозыла.
Шул рәвешле, галимнәрнең дөресрәк фикере буенча, хатын-кызга кагылу да тәһәрәтне бозмый, һәм бу кагылу шәһвәт беләнме яки ансыз булганмы – бу мөһим түгел, бары кагылган кешенең бу вакытта бернинди бүлендекләре дә чыкмавы шарт. Моның дәлиле шул: бервакыт пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) үзенең хатыннарының берсен үбә һәм тәһәрәт алмыйча намаз укый.
Ә Аллаһ Тәгаләнең *“яки әгәр сез хатын-кызга кагылсагыз”* дигән сүзләренә килгәндә исә, биредә сүз женси якынлык турында бара, күпчелек галимнәрнең фикере әнә шундый. Ибн Габбасның, Аллаһ аннан һәм аның атасыннан риза булсын, шулай ук борынгы һәм хәзерге заман галимнәренең дә фикере шундый.

## Тәһарәтне бозучы гамәлләргә аңлатма:

“Җенси органнардан һәм аналь ачыклыктан бүлендекләр чыгу” – бирегә бөтен нәрсә дә керә: бәвел, тәрәт, газлар, мәни, мәзи (шәһвәт вакытында бүленеп чыгучы ябышкак сыекча), вәди (бәвел чыкканнан соң бүленеп чыгучы сыекча), ташлар, кан (гадәти кан да, хәез һәм нифас каннары да) һәм башкалар;

“Тәннән пычрак чыгу” – әгәр ул бәвел яки тәрәт төреннән булса;

“Акылны югалту: бирегә йокы һәм башкалар керә” – йокы үзеннән-үзе тәһарәтне бозмый, әмма йоклаган вакытта газлар бүленеп чыгу ихтималы зур. Әгәр кеше тирән йокыга талмаган булса һәм газлар чыкмаганлыкны сизсә, мондый йокы тәһарәтне бозмый;

“Җенси органга яки аналь ачыклыкка киртәләрсез (ягъни кием аркылы түгел) кул белән кагылу” –дөресрәк фикер җенси органнарга кагылу тәһарәтне бозмый, әмма тәһарәт алуны тиешле итә.

## Тәһарәтнең кыскача тасвирламасы:

- Кеше, тәһарәт алырга ниятләгәннән соң, Аллаһның исеме белән ("Бисми-Ллаһ") ди;
- Шуннан соң өч тапкыр кул чукларын юа;
-Аннан соң уң учына су тутыра, шул суның бер өлешен авызына алып, авыз эчен чайката һәм түкерә; суның калган өлешен борынына суыра, аннан соң аны сеңгерә, сеңгергән вакытта борынын сул кулының баш һәм имән бармаклары белән сыпыра. Шул рәвешле өч тапкыр эшли.
- Шуннан өч тапкыр битен юа. Битнең чикләре шул: чәчләр үсә башлаган урыннан алып ияк астына кадәр, ә киңлеккә – бер колактан алып икенчесенә кадәр;
- Аның соңында терсәкләре белән бергә кулларын (бармак очларыннан алып терсәккә кадәр), башта уңын, аннан сулын юа.
- Шуннан соң юеш ике учы белән башын сыпыра: маңгайдан алып баш артына кадәр һәм киресенчә, баш артыннан маңгайга кадәр;
- Аннары юеш имән бармаклары белән колак яфракларының эчен юа;
- Ахырда өч тапкыр аякларын ашык сөякләренә кадәр тубык тиңентен юа.









- Тәһарәт алып бетергәннән соң: *“Әшхәду әлә иләһә илләл-Лаһ вәхдәху лә шәрикә ләһ вә әшхәду әннә Мухәммәдән гәбдуху вә расулюх”* дип әйтү сөннәт. Әт-Тирмизи башка зикерләр дә китерә: *“Аллахуммә-дж̧ ‘әл-ни мин әт-тәвввәбинә вәдж̧‘әл-ни мин әл-мутатаххирин”* [15].

## Тәһарәт алуда билгеләнгән чикләрне узуга карата шәригать хөкеме

Тәһарәт алуда  билгеләнгән чикләрдән узып китеп, үзеңнән ни дә булса өстәү рөхсәт ителми, мәсәлән, тән әгъзаларын өч тапкырдан да артыграк юу, я булмаса, кулларның терсәктән  югарырак өлешен юу,  яки аякларны юган вакытта балтырларны юу, яки муенны сыпыру.



# Тәһарәт белән бәйле мәсьәләләрне тасвирлаучы кушымта

## Беренчедән: Чистарыну

### Тәяммум (җир белән чистарыну)


Су булмау яки аны куллану зыян китерү сәбәпле, тән әгъзаларын чистарту мөмкинлеге булмаганда, тәһарәтне тәяммум алмаштыра. Бу очракта су урынына туфрак кулланыла.

### Тәяммум кылу тәртибе

Кеше җир белән чистарынуны ният кылганнан соң, “БисмиЛләһ” әйтергә, шуннан соң уч төпләре белән бер тапкыр җиргә сугарга, аннан битен һәм кул аркаларын сыпырырга тиеш.



Һәм уч төпләре белән җиргә сукканда бармакларны берсеннән берсен аеру да, кул аркаларын сөрткәндә бармак араларын сөртү дә дөрес түгел.



## Госелнең фарызлары

Госел алырга ният кылу һәм пычраклардан арыну, шуннан соң “БисмиЛләһ” әйтү, бөтен тәнне, куе, шулай ук сирәк чәчләр астындагы тәнне юу, авыз һәм борыны чайкау.

## Госелнең вәҗибләре

Җенес әгъзаларын һәм арт юл тирәсен юу, шуннан соң кулларны юу һәм намаз уку алдыннан алган кебек тәһәрәт алу, аның соңында чәчләрне чылату һәм юу, шуннан соң башта гәүдәнең уң, аннан сул ягын юу, һәм ахырда аякларны юу.

## Госел фарыз булган гамәлләр

1. Җенси якынлык яки башка сәбәп белән эякуляция (мәни чыгу) булу. Шулай ук мәни чыкмыйча җенси якынлык кылу да госелне боза;
2. Хәез һәм нифас каны ага башлау;
3. Үлем, бу шәһидләргә (яу кырында һәлак булучы) кагылмый;
4. Динсез кешенең Исламны кабул итүе;

## Хуффларны һәм оекбашларны сыпыру шартлары

Хуффлар һәм оекбашлар нәҗесләрдән чиста булырга тиеш

Аларны тәһарәт (бирегә аякларны юу да керә) алганнан соң киеп куярга кирәк

Сыпыру госел алганда түгел, ә тәһарәт алганда гына башкарыла.

Хуффлар яки оекбашлар аякның тәһарәт алганда юыла торган җиренең күбрәк өлешен каплап торырга тиеш.

Сыпыру билгеле бер вакыт аралыгында башкарылырга тиеш: яшәү урынында булган кешегә көн һәм төн (24 сәгать), сәфәрдәге кеше өчен өч көн һәм өч төн (72 сәгать). Вакытны санау беренче тапкыр сыпырган мизгелдән башлана.

### Оекбашларны ничек сыпырырга?

Дымлы уч төпләре белән бармак очларыннан балтырларга кадәр аяк йөзеннән сыпырырга кирәк. Ике аякны да берьюлы сыпыру тиешле, ягъни уң кул белән уң аяк, сул кул белән сул аяк икесе бер мизгелдә (колакларны сыпырган кебек) сыпырыла, чөнки сөннәт сыпыруның нәкъ менә шул ысулына ачык күрсәтә.

### Сыпыру белән бәйле кайбер мәсьәләләр

1. Сыпыруның вакыты тәгәлләнсә дә, яки хуффлар (оекбашлар) салынса да, тәһарәт яраксызга әйләнми;
2. Хуффлар (оекбашлар) тишек булса да, шулай ук тән күренеп тора торган юка материалдан булган носкилар өстеннән дә сыпырырга рөхсәт ителә.

## Бәдрәфтә хаҗәтләрне үтәү этикеты

**<u>Тиешле булган гамәлләр:</u>**

- Бәдрәфкә сул аяктан керү һәм кергән вакытта: **"Бисми-Лләһ. Аллаһуммә инни ә`узу бикә минәл-хубси уәл-хабәис"**, - дип әйтү [16];
- Чыкканда уң аяктан чыгу һәм чыккан вакытта: **"Гуфранә-кә"**, - дип әйтү [17]; Хаҗәтен үтәгән кешегә кеше күзеннән стена артына яки башка ысул белән качу **мәҗбүри**. Әгәр дә ул ачык җирдә булса, бу очракта аңа башкалардан читкәрәк китү тиешле.

Хаҗәтен үтәүче кешегә **рөхсәт ителми**:

- Хаҗәтен юлларда, кеше җыелган урыннарда, җимеш бирүче агач төбенә, агымсыз торгын суга яки кешеләргә уңайсызлык тудыра торган башка җирләрдә башкару;
- Кәгъбә ягына йөз яки арка белән борылу;
- Җенес әгъзасына уң кул белән кагылу;
-Аллаһ Тәгаләнең исемен телгә алу.

Хаҗәтне үтәгәннән соң, су яисә кәгазь белән истинҗа кылу тиешле. Истинҗа кылуның шартлары түбәндәгеләр:

- Кәгазь белән сөртенгәндә өч яки аннан да күбрәк тапкыр сөртенергә кирәк;
- Тулы чисталыкка ирешкәнче сөртенергә кирәк. Әгәр сөртенгәннән соң кәгазь коры булса, димәк, чисталыкка ирешелгән дигән сүз;
- Нәҗесләр яки затлы нәрсәләр (мәсәлән, ризык) белән сөртенү тыелган, шулай ук сөякләр һәм кипкән тизәк белән сөртенү дә ярамый;

Ир-атларга кече йомышны басып башкару рөхсәт ителгән, әмма бер шарт үтәлергә тиешле: аларның тәннәренә һәм киемнәренә бәвел чәчрәмәскә тиеш һәм аларның гаурәтләрен һичкем күрергә тиеш түгел. ***"Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) чүплек янына килде һәм кече йомышын басып башкарды"*** (Хәдис имам әл-Бохарида һәм Мөслимдә килә).

# Тәһарәт һәм госел мәсьәләсе буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

**1. Тәһарәтнең шартлары ничә?**

- Сигез;
- Тугыз;
- Ун.

**2. Тәһарәтнең мәҗбүри гамәлләре:**

- Тәннең дүрт әгъзасын юу;
- Тәнең дүрт әгъзасын юу, шулай ук эзлеклелекне саклау һәм бүленмәү.

**3. Тәһарәтне ничә гамәл боза?**

- Сигез;
- Алты;
- Биш.

**4. Биредә саналганнарның кайсысы тәһарәтне боза?**

- Газель ите;
- Дөя ите;
- Йокымсырау;
- Газлар;
- Корсактагы тавыш;
- Мәет юу;
- Хатын-кызга кагылу.

**5. Тәяммүм кылуның тәртибен яз:**

____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________

**6. Госел коенуның тәртибен яз:**

____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________

**7. Ошбу очракларга карата шәригать хөкемнәрен аңлат:**

| Очрак | Хөкеме |
|---|---|
| Ниятне кычкырып әйтү | |
| Бер намазны уку өчен тәһарәт алырга ният кылды, шуннан соң бердән артык намаз башкарды | |
| Коръән уку өчен тәһарәт алды, шуннан соң намаз укыды | |
| Тәһарәт алган вакытта ниятен бозды | |
| Тәһарәт алып бетергәннән соң ниятен бозды | |
| Балтырына камыр ябышкан хәлдә тәһарәт алды | |
| Тәһарәт ала һәм шул ук вакытта дөя итен ашый | |
| Урланган су белән тәһарәт алды | |
| Су яки кәгазь белән истинҗа кылганчы тәһарәт алды. | |
| Тәһарәт алган вакытта колакларны сыпыру өчен кулларын юешләтте | |
| Башны өч тапкыр сыпыру | |
| Тәһарәт алган вакытта әгъзаларны бер тапкыр юу | |
| Әгъзаларны өч тапкыр юу | |
| Тәһарәт алган вакытта кул чукларын юу. | |
| Дымлы бармаклар белән сакалны тарау | |
| Тәһарәт алганда дымлы кул белән сөртү | |
| Юарга тиешле әгъзаларны сыпыру | |
| Балтырны юу | |
| Йөзүдән соң намаз уку | |
| Госел коенганнан соң тәһарәт алмыйча гына намаз уку | |
| Башны юу | |
| Кул чукларын су белән тулы савытка төшерү | |
| Тәһарәт алганда башта уң як әгъзаларны юу | |
| Әгъзаларны өч тапкырдан артык юу | |

# Икенчедән: Зәкәт

Зәкәт ике төрле була:

## Милектән зәкәт бирү

Исламның өченче баганасы булып тора. Иректә булган һәм милке нисабка (зәкәт түләнергә тиешле милекнең минималь күләме) тулган һәрбер мөселман өчен мәҗбүри. Милектән зәкәт түләү бары шул очракта гына мәҗбүри була: әгәр милекне алуга ай календаре буенча тулы бер ел үткән булса. Әмма бу шарт җирдән үсүче нәрсәләрдән, шулай ук, нигездә, нисабны арттыра торган милектән, сәүдәдән кергән керемгә карамый – алардан зәкәт түләү вакыты нигез салынган көннән башлап исәпләнә. Милектән бирелә торган зәкәт дүрт төрле була:

## Тән зәкәте

Бирелә сүз Зәкәт әл-Фитр (Рамазан аеның ахырында бирелә торган зәкәт) турында бара. Зәкәтнең әлеге төре һәр мөселман – олымы ул, кечеме, хатын-кызмы яки ир-атмы, кол яки иреклеме – һәр мөселман өчен дә мәҗбүри булып тора.

### Сәүдә өчен товарлар

Бирегә кешенең сату һәм алу өчен әзерләгән бар нәрсәсе дә керә.

### Җирдән үсүче нәрсәләр

Орлыклылар һәм җимешләр.

### Көтүдә йөри торган терлек, мал-туар

Бер ел буе яки бер елга якын вакыт беркемнеке дә булып саналмаган көтүлекләрдә ирекле рәвештә йөргән дөяләр, мөгезле эре һәм вак терлекләр.

### Кыйммәтле әйберләр

Атап әйткәндә: алтын, көмеш һәм аларны алмаштырып килүче нәрсәләр – акча берәмлекләре һ.б. Алтынның нисабы 85 грамм булса, көмешнеке исә 595 грамм.

## Зәкәт кемнәргә түләнә?

-**Фәкыйрьләргә**. Бу бөтенләй бернәрсәләре дә булмаган яки яшәү минимумы өчен кирәкле средстволарның аз өлеше генә булган мохтаж кешеләр;

- **Ярлыларга** (мескеннәр). Болар яшәү минимумы өчен кирәкле средстволарның яртысы яки яртысыннан күбрәк өлеше булган кешеләр. Әгәр бер ел буена яшәү минимумы өчен кирәкле акчалар саны 120 000 дип фаразласак, фәкыйрь ул акчасы 60 000нән кимрәк, ә ярлы кеше 60 000 яки аннан да күбрәк (әмма 120 000гә тулмаган) кадәр акчасы булган кеше. Шуңа күрә без фәкыйрьләргә һәм ярлыларга зәкәтне аларга яшәү өчен нәкъ бер елга җитәрлек итеп бирергә тиешбез, чөнки зәкәт бер елга бер тапкыр бирелә;

- **Зәкәтне җыю, саклау һәм бүлү белән шөгыльләнгән кешеләргә**. Әлеге кешеләрне дәүләт җитәкчесе билгеләп куя, һәм аларның мохтаж кешеләр булулары мөһим түгел, киресенчә – аларның, бай булсалар да, зәкәттән өлеш алырга хаклары бар;

- **Йөрәкләрен яулап алырга мөмкин булган кешеләргә**. Бу, аларга карата, Ислам динен кабул итәр, дигән өмет булган кешеләр. Шулай ук биргә, зәкәт түләү сәбәпле, күңелләрендәге начарлыкларны киметергә яисә иманнарын ныгытырга мөмкин булган кешеләр дә керә;

- **Коллар сатып-алган кешеләргә**:

а) Үзенең хуҗасы белән үз-үзен сатып алу хакында килешү төзегән мөселман-мукәтәбкә ярдәм;

б) Мөселман колларны сатып-алу;

в) Әсирлектә булган мөселманнарны сатып-алу.

Үзенең зәкәт бурычын үтәү өчен хуҗаның үзенең колын азат итүе бу мәсьәләгә кагылмый – болай эшләү рөхсәт ителми;

- **Бурычлы кешеләргә**:

а) Бер-берсенә дошман булган якларны килештерү өчен бурыч алган кешегә;

б) Үзе өчен бурыч алган кешегә. Зәкәт түлим дигән ният белән, бурычлы кешегә аның бурычын гафу итү рөхсәт ителми;

**-Аллаһ юлында чыгымнары булган кешегә**.
**- “Юл балаларына”.** Болар өйләреннән еракта булган һәм яшәү өчен бер тиенсез калган чит ил кешеләре булган юлчылар. Мондый кешеләргә, өйләренә кайтып җитә алсыннар өчен, зәкәтнең бер өлеше түләнә.

Зәкәтне әлеге категория кешеләрнең берсенә бирү белән чикләнү рөхсәт ителә.
Бай яки яшәү өчен үзе акча таба ала торган көчле кешегә зәкәт түләү рөхсәт ителми. Шулай ук Мөхәммәд (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) нәселенә (аңарга Хашим нәселе дә һәм аларның ирекккә җибәрелгән коллары да керә) дә, шулай ук имансызларга да зәкәт түләнми. Моннан тыш, әгәр кеше зәкәтне үзе тәэмин итәргә тиешле кешесенә түләсә, әлеге зәкәт дөрес булмаячак. Ә мөстәхәб дигән төргә караучы сәдәкага килсәк, аны әле санап киткән кешеләрнең барысына да бирү рөхсәт ителгән, әмма сәдакадан файда никадәр күбрәк булса, шуның кадәр ул тулыканлырак булачак.

## Төрле милек төрләреннән түләнүче зәкәтнең

| Милек төре | Ай календаре буенча тулы ел дәвамында милекнең саклануы | Нисаб (зәкәт түләнергә тиешле милекнең минималь күләме) | Зәкәтнең күләме |
|---|---|---|---|
| Көтүдә йөри торган терлек, мал-туар. | Шарт булып тора. | Киләсе таблицаны карагыз. | Киләсе таблицаны карагыз. |
| Җирдән үсүче нәрсәләр. | Шарт булып тормый. | 300 саг (Бер саг яхшы бодай ярмасының ике килограмм кырык грамм күләменә тигез). | Табигый сугарылу (яңгырлар, чишмә) булган очракта уңышның 1/10 өлеше (10%) түләнә. |
| | | | Ясалма сугарылу очрагында уңышның 1/20 өлеше (5%) түләнә. |
| | | | Сугарылуның ике төрен дә кулланган очракта уңышның 3/40 өлеше (7,5%) түләнә. |
| Кыйммәтле әйберләр. | Шарт булып тора. | 85 грамм алтын яки 595 грамм көмеш. | 1/40 (2,5%). |
| Сәүдә өчен әзерләнгән товарлар. | Шарт булып тора. | Мохтаҗлар өчен нәрсәнең яхшырак булуыннан чыгып, алтын яки көмеш бәясе белән исәпләнә. | 1/40 (2,5%). |

**Көтүдә йөри торган терлек, мал-туардан (дөя, мөгезле эре һәм вак терлек) зәкәт**

| Мөгезле вак терлек: сарыклар һәм кәҗәләр | | |
|---|---|---|
| Саны: ...ба шлап | Саны: ...га кадәр | Зәкәт күләме |
| 40 | 120 | 1 сарык |
| 121 | 200 | 2 сарык |
| 201 | 300 | 3 сарык |
| Шуннан соң һәрбер йөздән бер сарык | | |
| Зәкәт кәҗә тәкәләре белән, күренеп торган җитешсезлекләре булган, артык карт, артык яхшы һәм артык начар, шулай ук арык яки буаз, алга таба ризык булачак, дип әзерләнгән маллар белән түләнми. | | |

| Бер яки ике өркәчле дөяләр | | |
|---|---|---|
| Саны: ...ба шлап | Саны: ...га кадәр | Зәкәт күләме |
| 5 | 9 | 1 сарык |
| 10 | 14 | 2 сарык |
| 15 | 19 | 3 сарык |
| 20 | 24 | 4 сарык |
| 25 | 35 | Бер яшьлек ана дөя |
| 36 | 45 | Ике яшьлек |
| 46 | 60 | Өч яшьлек |
| 61 | 75 | Дүрт яшьлек |
| 76 | 90 | Ике яшьлек 2 ана дөя |
| 91 | 120 | Өч яшьлек 2 ана дөя |
| 121 | 129 | Ике яшьлек 3 ана дөя |
| Шуннан соң һәр 40 ана дөядән – ике яшьлек 1 ана дөя, ә һәр 50дән - өч яшьлек ана дөя. Калдыгы тугыздан да артырга тиеш түгел. | | |

| Сыерлар һәм буйволлар | | |
|---|---|---|
| Саны: ...ба шлап | Саны: ...га кадәр | Зәкәт күләме |
| 30 | 39 | Бер яшьлек сыер |
| 40 | 59 | Ике яшьлек сыер |
| 60 | 69 | Бер яшьлек ике сыер |
| Шуннан соң һәрбер 30дан – бер яшьлек, ә һәрбер 40тан – ике яшьлек сыер. | | |

# Зәкәт мәсьәләсе буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

**1. Әгәр кешенең милеге бер ел буе тик ятса, аның өчен зәкәт мәҗбүригә әверелә. Ул ел ничек исәпләнә?**

- Ай календаре буенча (хиҗри буенча);
- Кояш елы;
- Аерма юк.

**2. Әлеге милекнең үз хуҗасында бер ел буе тик ятуы зәкәт түләү өчен шарт булып тормый:**

- Табылган хәзинә;
- Җирдән үсүче нәрсәләр.

**3. Алтынның нисабы (зәкәт түләнергә тиешле милекнең минималь күләме):**

- 85 гр;
- 595 гр;
- 95 гр.

**4. Көмешнең нисабы (зәкәт түләнергә тиешле милекнең минималь күләме):**

- 200 дирхәм;
- 595 гр;
- Барлык вариантлар да дөрес.

**5. Зәкәт түләнә торган йорт хайваннарына дөяләр, сыерлар, буйволлар, мөгезле вак терлек керә.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**6. Зәкәт җиләк-җимештән түләнми.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**7. Көтүлекләрдә йөргән хайван ул:**

- Бәясе күтәрелүче мал;
- Елның күбрәк өлешен яки бер ел көтүлекләрдә ирекле рәвештә йөргән мал.

**8. Ярлылар турында сүз барганда, алар белән беррәттән фәкыйрьләр дә күздә тотыла.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**9. Фәкыйрьләргә зәкәтне күпме вакыт яшәү өчен җитәрлек күләмдә бирергә кирәк:**

- Бер ел;
- Бер ай.

**10. Зәкәт җыю белән шөгыльләнүче кешеләргә кемнәр керә?**

- Моның белән шөгыльләнүче һәркем;
- Бары тик дәүләт җитәкчесе генә билгеләп куйган кешеләр.

**11. Зәкәтнең күләмен билгелә:**

| Милек | Зәкәтнең күләме | Әгәр булса, калдыгы |
|---|---|---|
| 100 000 сум | | |
| 300 000 сум | | |
| 400 000 сум | | |
| 80 грамм алтын | | |
| 500 грамм көмеш | | |
| 30 сарык | | |
| 60 сарык | | |
| 565 сарык | | |
| 4 ана дөя | | |
| 17 ана дөя | | |
| 449 ана дөя | | |
| 30 сыер | | |
| 49 сыер | | |
| 77 сыер | | |
| 99 сыер | | |

| | | |
|---|---|---|
| 20 миллион доллар | | |
| 40 доллар | | |
| 45679 доллар | | |
| 255 саг бодай | | |

**12. “Йөрәкләрен яулап алырга мөмкин булган кешеләр” категориясенә аларга карата Ислам динен кабул итәрләр, дигән өмет булмаган имансызлар да керә.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**13. Әгәр кеше үзенең колын азат итсә, аңа зәкәт бирелергә тиеш.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**14. Бай кешегә бер ярлы кеше билгеле бер күләмдә акча тиеш булган. Бай кеше аның әҗәтен, зәкәт булыр дигән ният белән, гафу итә. Бу зәкәт дөресме?**

- Әйе;
- Юк.

**15. “Аллаһ юлындагы чыгымнар” категориясенә теләсә-нинди изгелеккә, мәсәлән, мәчет салдыруга тотылган акчалар керә.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**16. Кыйммәтле әйберләрдән түләнә торган зәкәтнең күләмен санап чыгару өчен аларны кырык өлешкә бүләргә кирәк.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**17. Көтүлекләрдә ирекле рәвештә йөргән терлектән зәкәт мәҗбүри, ә эш өчен кулланылган, көтүлекләрдә ирекле рәвештә йөрмәүче, киресенчә, хуҗасы аларны туйдыру өчен көч куйган малдан зәкәт түләү мәҗбүри түгел.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**18. Ясалма сугарылып үстерелгән бөртеклеләрнең һәм җимешләрнең зәкәтенә килгәндә, ул аларның 1/20 өлешеннән генә түләнә.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**19. Зәкәт мәҗбүри рәвештә түләнергә тиешле милекнең төрен күрсәт:**
- Тавык;
- Азык-төлек кибете;
- Пальма фермасы;
- 85 грамм алтын;
- Көтүлекләрдә ирекле рәвештә йөрүче дөяләр;
- Ашату өчен көч куелган сарыклар;

**20. Акчадан түләнергә тиешле зәкәтнең күләме:**

- 2,5%;
- 5%.

**21. Сиксән грамм алтынның зәкәте күпмегә тигез?**

- Ике граммга;
- Дүрт граммга;
- Бу күләмдәге алтыннан зәкәт түләнми;

**22. Яшәү өчен дип билгеләнгән йортлардан зәкәт түләнелә.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**23. Теләсә-кайсы юлчының зәкәт алырга хакы бар.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

## Өченчедән: Ураза

Ураза (сыям) гарәп телендә тыелу (имсак) дигәнне аңлата. Шәригать терминологиясендә ураза – ул таң атканнан алып кояш баеганчыга кадәр ашау-эчүдән һәм уразаны боза торган башка гамәлләрдән тыелу аркылы Аллаһка табыну.

### Уразаның әркәннәре

## Уразаны мәҗбүри итә торган шартлар

1. Ислам динен тоту;
2. Акыл;
3. Балигълыкка ирешү. Аеру (тәмийз) яшенә җиткән баланы исә ураза тотарга дәртләндереп тору тиешле;
4. Яшәү урынында булу. Ягъни сәфәрдәге кешегә ураза мәҗбүри түгел. Әмма әгәр ураза тоту аңа авырлык тудырмаса, аңа ураза тоту хәерлерәк. Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) шулай эшли иде. Шулай ук болай эшләү җаваплылыктан тизрәк арыну өчен дә яхшырак, өстәвенә, әлеге ай фазыйләтле булуы белән дә өстен;
5. Сәламәтлек;
6. Хәез һәм нифасның булмавы.

## Ураза вакытында авыру халәте ике төрлегә бүленә:

### Сихәтләнү көтелмәгән авыру

Әлеге төркемгә ураза тота алмаган карт кеше дә керә. Мондый кешегә ураза тоту мәҗбүри түгел, әмма ул һәр калган көн өчен ярлы кешене ашатырга, яки Рамазан аеның көннәре санынча ярлы кешеләрне җыеп, барысын берьюлы бер тапкыр ризыкландырырга тиеш; яки һәр ярлыга чирек сағ ризык (510 грамм яхшы бодай орлыгы кадәр) өләшергә тиеш, шулай ук ризыкта ит булса яхшы була.

### Сихәтләнү көтелгән, әмма аның сәбәпле ураза тоту кыенлашкан авыру

Биргә хәез, нифас халәтен кичерүче хатын-кыз да, бала имезгән ана да, сәфәрдә булган кеше дә керә. Мондый кеше уразаның тотмый калган көннәрен каза кыла, һәм уразасын сәламәтләнгәч тота. Әгәр кеше авырудан сәламәтләнгәнче вафат булса, ураза гыйбадәте аның өстеннән төшерелә.

## Рамазан аеның башлануы ничек раслана?

Рамазан аеның башлануы яңа ай туу белән яки Шәгъбән аеның утызынчы көне тәмамлану белән раслана.

## Уразаны бозучы гамәлләр

1. Белә торып ашау, эчү. Әгәр бу эшләр онытылып эшләнсә, ураза бозылмый;
2. Ураза тоту мәҗбүри булган кешенең көндезге вакытта якынлык кылуы. Мондый очракта кеше авырайтылган кәффәрәт кылуны үз өстенә алырга тиеш: колны азат итү, әгәр мондый мөмкинчелеге булмаса, ике ай рәттән ураза тотарга тиеш, әгәр дә аны да булдыра алмаса, 60 ярлыны ашатырга тиеш;
3. Кагылу, яисә үбешү, яисә кочаклашу һәм башка сәбәпле булган эякуляция (мәни чыгу), әмма поллюция уразаны бозмый;
4. Ризыкны яки эчемлекләрне алыштырып килгән нәрсәләр, мәсәлән, тукландыргыч уколлар, андый үзлеге булмаган башка уколлар уразаны бозмый;
5. Хиджама ярдәмендә кан чыгару. Әмма аз күләмдә кан чыгару, мәсәлән, анализ өчен кан бирү, уразаны бозмый;
6. Үз иркең белән косу;
7. Хәез яки нифас башлану.

## Ураза тотучыга рөхсәт ителә (мөбәх)

Төкерекне йоту, хаҗәт булганда ризыкны тәмләп карау (әмма һичбернәрсә дә йотылмаска тиеш), су коену, сивак белән куллану, ислемай куллану,  суыну.

## Ураза вакытында үтәлергә тиешле гамәлләр

1. Сәхәр (таң алдыннан ризык ашау);
2. Сәхәрне таң атар алдыннан ашау;
3. Ифтарда ашыгу (ягъни кояш баю белән авыз ачу);
4. Саны так булган финиклар белән, алар булмаса, кипкән финиклар белән, алар да булмаса, су йотып авыз ачу. Әгәр авыз ачу өчен һичбер нәрсә дә булмаса, күңелеңнән, уразадан чыгам дип, ният кылу җитә;
5. Авыз ачканда дога кылу;
6. Еш сәдака өләшү;
7. Төнге намазлар укуда тырышлык кую;
8. Коръән уку;
9. Гомрә кылу;
10. Сине тиргәгән кешегә: “Мин уразада”, - дип әйтү;
11. Кадер кичәсен эзләргә тырышу;
12. Рамазан аеның соңгы ун көне һәм төнендә игтикаф кылу (мәчеттә булу).

## Ураза токан вакытта шелтәләнә торган (мәкрух) гамәлләр

1. Авызны һәм борынны чайкауда артыклык кылу;
2. Хаҗәт булмыйча ризыкны тәмләп карау.

## Ураза тотучыга тыелган (харам) гамәлләр

1. Какырыкны йоту (әмма бу гамәл уразаны бозмый);
2. Үбешү. Үбешүдән уразасы бозылырга мөмкин булган кешеләргә тыелган;
3. Ялган сүзләр (бирегә тыелган барлык гамәлләр дә керә);
4. Наданлык (ягъни ахмаклык, кешегә карата йомшак булмау);
5. Тоташтан ураза тоту (ифтарсыз ике яки аннан да артыграк көн ураза тоту).

## Нәфел (өстәмә) уразалар

1. Рамазан аеның уразасын ахырына кадәр тотып бетергән кешегә Шәүәл аеның алты көн уразасын тоту. Әлеге уразаны икенче көннән алып, рәттән тотсаң хәерле;
2. Хаҗ кылмаган кешегә Гарәфә көнендә ураза тоту;
3. Гашура көнендә (Мөхәррәм аның унынчы көне) тугызынчы һәм унынчы көннәре белән;
4. Дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендәге ураза. Дүшәмбе көн ураза тоту исә – хәерлерәк;
5. Ай саен өч көн ураза тоту. Һәм әгәр дә ул “ак көннәр”гә (ай календаре буенча айның 13, 14, һәм 15 көннәре) туры килсә, тагын да яхшырак;
6. Көнаралаш ураза;
7. Аллаһ ае булган әл-Мөхәррәм аенда ураза;
8. Зөл-хиҗҗә аеның беренче тугыз көнендә ураза;
9. Шәгъбән аенда (әмма ай буе түгел) ураза.

## Хәерсез (мәкрух) ураза

Аерым бер көнне генә аерып алып, әйтик гел җомга гына, гел шимбә, я якшәмбе генә ураза тоту хәерле түгел. Бары тик билгеле бер сәбәпләр аркасында, әйтик, Гарәфә көне әлеге көннәрнең берсенә туры килсә генә, әлеге көнне аерып алып ураза тотарга рөхсәт ителә.

## Тыелган ураза

1. Рәҗәб аен аерып ураза тоту;
2. Шикле көндә ураза тоту. Әмма әгәр кемдер даими рәвештә ирекле уразаларның бер төрен тота торган булса, монда тыю юк;
3. Ике бәйрәм көннәрендә ураза тоту;
4. Әт-тәшрик көннәрендә (Корбан бәйрәменнән соңгы өч көндә) ураза тоту, бу тыю корбан чала алмаган кешегә кагылмый;
5. Ел әйләнәсе ураза тоту.

## Уразаны каза кылу

Уразаны каза кылганда аның өзлексез булуы хәерле, моннан тыш каза кылуны бәйрәм көннәреннән соң ук башларга ашыгырга кирәк. Шулай ук киләсе Рамазан аена кадәр уразаны калдыру да рөхсәт ителми. Кеше каза уразасын киләсе Рамазан аена кадәр калдырган булса да, аңа калган көннәрен генә каза кылу тиешле, әмма болай эшләү – гөнаһлы гамәл.

## Фитр сәдакасы (Зәкәт әл-фитр)

Рамазан аеның соңгы көненең кояшы баеган вакытта исән булган һәм бер саг (бер саг – ул бәйрәм көнендә һәм төнендә төп хаҗәтләр, шулай ук мөселманга һәм аның гаиләсенә туклану өчен кирәк булганнан артык ризык) күләмендә артык ризыгы булган һәр мөселманга Фитр сәдакасы мәҗбүри.

Зәкәт әл-Фитрның максаты (Хикмәте):

Ураза вакытында булган кимчелекләрдән (буш һәм әшәке сүзләр сөйләү) чистарыну;

2. Бәйрәм көнендә ярлыларны хәер теләнеп йөрүләреннән котылдыру.

### Фитр сәдакасын түләү вакыты

| Рөхсәт ителгән вакыт | Хәерле вакыт | Тыелган вакыт |
| --- | --- | --- |
| Бәйрәмгә кадәр бер-ике көн кала. | Бәйрәм көнендә иртәнге намаздан соң бәйрәм намазына кадәр. | Бәйрәм намазыннан соң. |

## Фитр сәдакасы күләме

Кешенең көндәлек ризыгының бер саг күләме кадәр, ул ике килограмм кырык грамм яхшы бодай ярмасы күләменә тигез; зәкәт әл-фитрның акчалар белән түләнүе дөрес түгел.

## Гает намазы

Бөтен кеше өчен дә фарыз. Аның вакыты кояш офыктан сөңге буе күтәрелгәч башлана һәм төш вакыты белән тәгәлләнә. Әлеге намазны калдырган кеше аны каза кылмый. Аны торак җирләрдән читтә буш урыннарда үтәү сөннәт булып тора, әмма мәчетләрдә уку да рөхсәт ителгән. Намазга барыр алдыннан так санча финик ашау хәерле. Шулай ук чистарыну, ислемайлар сөртү, иң яхшы киемнәрне кию, мәчеткә бер юл белән барып икенче юл белән кайту да хәерле гамәлләр. Шулай ук "Аллаһ бездән һәм сездән кабул итсен (**Такъаббәлә-Ллаһу минә уә минкум**)" сүзләрен әйтеп, бәйрәм белән котлауда да тыю юк. Шулай ук бәйрәм алдыннан төннән алып бәйрәм көнне кояш баеганчыга кадәр һәр намаздан соң тәкбир әйтү дә хәерле гамәл. Тәкбирләрне ошбу рәвешле әйтергә кирәк: "Аллаһ Бөек, Аллаһ Бөек, Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Аллаһ Бөек, Аллаһ Бөек, һәм барча мактау Аллаһка! (**Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, лә иләһә илләә-Ллаһ, уәЛлаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, уа ли-Лләһи-ль-хәмд**)".

Бәйрәм намазын үтәү тәртибе: бәйрәм намазы бәйрәм вәгазе (хөтбәсе) алдыннан башкарылучы ике рәкәгатьтән тора. Беренче рәкәгатьтә кереш тәкбирдән соң (тәкбир әл-Ихрам) алты тапкыр тәкбир ("Аллаһу әкбәр" сүзләрен) әйтү тиешле. Икенче рәкәгатьтә исә, беренче рәкәгатьтән икенчесенә күчкәндә Коръән укыр алдыннан әйтелә торган тәкбирдән соң (тәкбир әл-Интикаль), биш тәкбир әйтелә.

# Ураза темасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

**1. Уразаның ничә әркәне бар?**
- Ике;
- Өч;
- Дүрт.

**2. Кем өчен ураза тоту мәҗбүри?**
1) ____________________________________________
2) ____________________________________________
3) ____________________________________________
4) ____________________________________________

**3. Һәр авыру кешегә ураза тоту тыелган.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел;

**4. Ошбу очракларга карата шәригать хөкемнәрен аңлат:**

| Очрак | Хөкеме |
|---|---|
| Ураза тотарга иртәнге намаздан соң ният кылу | |
| Ниятсез ураза | |
| Кечкенә баланың уразасы | |
| Сәфәрдәге кешенең уразасы | |
| Нифас халәтендә булган хатын-кызның уразасы | |
| Уразалы килеш ризык ашау | |
| Тукландыргыч инъекцияләр кабул итү | |
| Күзгә тамыза торган дарулар (тамчылар) | |
| Авыртуны баса торган укол ясалу | |
| Хиджама | |
| Косу | |
| Төкерек йоту | |
| Ризыкны тәмләп карау | |
| Йоклау | |
| Авыру кешенең уразасы | |
| Су коену | |
| Суыну | |

| | |
|---|---|
| Сивак куллану | |
| Ислемай куллану | |
| Сәхәр вакыты | |
| Сәхәр вакытында нәрсә ашау хәерлерәк | |
| Нәрсә белән авыз ачу хәерлерәк? | ……………….. алар булмаса, ………………………..алар булмаса……………...…..бер нәрсә дә булмаса……………………………….. |
| Тәравих намазы | |
| Рамазан аенда гомрә | |
| Авыз һәм борынны чайкауда артыклык кылу | |
| Үбешү | |
| Ике яки аннан да күбрәк көн дәвамында өзлексез ураза тоту | |
| Шәүәл аеның алты көн уразасы | |
| Гарәфә көнендә ураза тоту | |
| Шикле көндә ураза тоту | |
| Ике бәйрәм көннәрендә ураза тоту | |
| Әт-тәшрик көннәрендә ураза тоту | |
| Мөхәррәм аенда ураза тоту | |
| Рәҗәб аенда ураза тоту | |
| Ел әйләнәсе ураза тоту | |
| Җомга көнне ураза тоту | |
| Каза уразасын икенче Рамазанга кадәр калдыру | |

## Дүртенчедән: Хаж

**Хаж** – Исламның бишенче баганасы. Ул ошбу шартлар булганда мәҗбүри: Ислам динендә булу, гакыл, җенси җитлегү, кешенең азат булуы, мөмкинчелек һәм хаҗны хатын-кыз кылганда мәхрәмнең булуы.

Хаҗның дүрт әркәне бар:

| Ихрам | Гарәфәдә тору | Тәваф әл-Ифәдә | Сагʼий |
|---|---|---|---|
| Бу хаж кылу гамәленә керешү өчен ният. | Зөл-Хиҗҗә аеның тугызынчы көнендә кояш зәвәлдән авыша башлаган мизгелдән алып бәйрәм көненең таңы атканчыга кадәр. Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әйтте: ***“Хаҗның мәгънәсе – Гарәфәдә тору”***. | Бу Кәгъбә тирәли әйләнү, ул Гарәфә тавында торганнан соң кылына. | Сафә һәм Мәрвә таулары арасында йөрү һәм йөгерү. Аллаһ Тәгалә әйтте: “**Сафа һәм Мәрвә таулары, әлбәттә, Аллаһка гыйбадәт кыла торган урыннарның билгеләредер**”. |

### Хаж төрләре

| Ифрад | Кыйран | Тәмәттуг |
|---|---|---|
| Бу кешенең бары тик Олы Хаҗны үтәргә генә (кече хаж – Гомрә хаҗын үтәмичә генә) ният кылуы. | Бу кешенең, ихрамга бер тапкыр кереп һәм хаж гамәлләрнең барысы да үтәлеп бетмичә аннан чыкмыйча, Олы Хаж белән бергә Гомрәне дә үтәргә ният кылуы. Моннан тыш ул корбан да чалырга тиеш. | Бу вакытта кеше Хаж аенда Гомрә үтәү өчен ихрамга керә, аны үтәгәч ихрамнан чыга, һәм шул ук елны Олы Хаҗны үти. Моннан тыш ул корбан да чалырга тиеш. |

## Хаҗның мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиешле гамәлләре

Кем дә кем әлеге гамәлләрнең берәрсен генә булса да үтәмәсә, бу хатаны Әл-Харам мәчете территориясендә сарык чалу һәм аның итен Мәккә шәһәренең ярлы кешеләрнә тарату аша юарга тиеш. Хаҗ кылучының үзенең әлеге итне ашарга хакы юк.

- Микатта ихрамга керү.
- Гарәфә тавында кояш баеганчыга кадәр (әлеге гамәлне көндез кыла башлаган кешегә) тору.
- Мөздәлифә үзәнлегендә төн үткәрү.
- Мина үзәнлегендә әт-тәшрик көннәрен үткәрү
- Җәмәрәтләргә ташлар ату.
- Чәчләрне кыру яки кыскарту
- Мәккәдән китәргә җыенган (хәтта әле берничә айдан соң гына китәм, дип ниятләсә дә) һәркем өчен Кәгъбә тирәли саубуллашу тәвафын кылу. Бу гамәлне хәез һәм нифас халәтендәге хатын-кызлар кылмый.

## Хаҗ һәм Гомрә өчен микатлар:

### Вакыт белән бәйле

Хаҗ айлары: Шәүәл, Зөл-Кәгъда, Зөл-Хиҗҗә. Хаҗ бары тик шушы айларда гына кылына. Гомрә хаҗын кылуга исә вакытка кагылышлы чикләүләр юк.

### Урын белән бәйле (ягъни хаҗиларның ихрамга керү урыннары)

- Зөл-Хуләйфә – Мәдинә шәһәре халкы һәм аның аша үтүче кешеләр өчен;
- Әл-Җухфә – Шәм, Каһирә һәм Марокко халкы өчен;
- Я л ә м л ә м – Йәмән халкы өчен;
- Зат гирк – Гыйрак халкы өчен.

## Хажның үтәлергә сөннәт гамәлләре

- Ихрамга керер алдыннан коену һәм ислемайлар сөртү
- Ирләр өчен ике кисәк ак тукыма кию (җилкәләргә япма һәм билгә бәйләвеч)
- Ихрамга кергәнче киселергә тиеш булган чәчләрне һәм тырнакларны кисү
- Ихрамга кергәннән алып Соңгы Җәмәраткә таш атканчыга кадәр тәлбия сүзләрен әйтү
- Ифрад  һәм Кыйран хаҗларын кылучылар өчен килгәч тә Кәгъбә тирәли әйләнү (Тәваф әл-кудум)
- Кәгъбә тирәли беренче тапкыр әйләнгәндә беренче өч әйләнештә адымнарны тизләтү
- Кәгъбә тирәли беренче тапкыр әйләнгәндә уң як җилкәне ачу
- Мөздәлифә үзәнлегенә килгәч ахшам һәм ясту намазларын кушып уку
- Гарәфәдә басып тору гыйбадәте алдыннан төнлә Мина үзәнлегендә куну
- Кара ташны үбү
- Таң атканнан алып кояш баешына якын вакытка кадәр Мөздәлифә үзәнлегендә булу. Үзәнлек территориясенең бөтен өлешендә дә булырга ярый

## Ихрамга кергәч эшләргә тыелган гамәлләр

Мондый гамәлләр тугыз: тәндәге чәчләрне алу, тырнакларны кисү, ир-атның башына сылашып торган баш киеме киюе, ир-атның гәүдә формасы яки аяк-кулларына үлчәп тегелгән кием киюе, хатын-кызның никаб һәм перчаткалар киюе, ислемайлар куллану (бирегә хуш исле сабын куллану да керә), коры җирдә ау, никахлашу яки никах уку, җенси якынлык, капма-каршы җенес әгъзасына шәһвәт белән кагылу. Әлеге гамәлләрне онытылып, белмичә яки ирексездән эшләүче кеше кәффәрәт (кайбер кылган хаталар һәм гөнаһлар өчен, Аллаһның ярлыкавына ирешү нияте белән билгеле бер эшләрне эшләү) йөкләтелми. Әмма коры җирдә ау белән шөгыльләнгән кеше әлеге хатасын йолуны, кәффәрәт кылуны үз өстенә алырга тиеш. Алда санап үтелгән гамәлләрне белә торып эшләү дүрт төрлегә бүленә:

**Эшләгән өчен кәффәрәт кылу булмаган гамәлләр**

Никахлашу нәкъ менә шундый гамәлгә керә. Шулай ук шәһвәт белән кагылу, әгәр аның нәтиҗәсендә мәни чыкмаса, бу гамәл өчен кәффәрәт кылынмый, әмма тәүбә итү кирәк.

**Эшләгән өчен кәффәрәт кылу шул гамәлнең үзенә тигез булган гамәлләр**

Коры җирдә киек аулау шундый гамәлләрдән. Ау вакытында җәнлек үтергән кеше, әлеге гамәлен шундый ук хайван белән кәффәрәт кылырга тиеш. Бу хактагы карар тәкъва һәм ышанычлы булган ике кеше тарафыннан чыгарыла.

**Эшләгән өчен авырайтылган кәффәрәт тиеш булган гамәлләр**

Бу гамәлләргә җенси якынлык кылу керә, ягъни ихрам халәтеннән беренче тапкыр чыкканчы якынлык кылган кешенең хаҗы дөрес булмый. Шулай да ул аны ахырына кадәр җиткерергә һәм яңадан үтәргә тиеш. Моннан тыш аңа кәффәрәт сыйфатында корбанга сыер яки дөя чалу тиеш була.

**Эшләгән өчен кәффәрәт кылу авыру вакытындагы кебек булган гамәлләр.**

Бу төргә калган тыелган гамәлләр керә. Кәффәрәт сыйфатында хаҗи гамәлне үзе сайлый: ул өч көн ураза тоту, яки алты ярлыны ашату (аларның һәрберсенә ярты саг ризык бирелә), яки корбанга сарык чалу (аның ите Мәккәдә яшәүче фәкыйрьләргә таратыла) булырга мөмкин.

## Хаж көннәре исемнәре

| Тәрвия көне. | Гарәфә көне. | Бәйрәм көне яки | Тыныч лык көне | Китүнең беренче көне | Китүнең икенче көне |
|---|---|---|---|---|---|
| Зөл-Хиҗҗә аеның сигезенче көне. Әлеге көндә Мина үзәнлегенә су алып килгәннәр. | Зөл-Хиҗҗә аеның тугызын чы көне. | корбан чалу көне. Зөл-Хиҗҗә аеның унынчы көне. | (Карр). Зөл-Хиҗҗә аеның унберен че көне. | (Нәфр). Зөл-Хиҗҗә аеның уникенче көне. | (Нәфр) Зөл-Хиҗҗә аеның унөченче көне. |

Бәйрәм алды төне Берләшү төне дип атала. Бу төнгә мондый исем кешеләрнең Гарәфәдә торганнан соң берләшүе сәбәпле бирелгән, чөнки Ислам дине килгәнче Мәккә халкы алай эшләмәгән.

## Хаж вакытында Аллаһка дога белән мөрәҗәгать итү хәерле булган урыннар

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Айның тугызынчы көнендә Гарәфәдә торганда төштән алып кояш баеганчыга кадәр | Айның унынчы көнендә Мөздәлифә үзәнлегендә иртәнге намаздан соң кояш чыгарга якын вакытка кадәр. | Әт-Тәшрик көннәрендә кече һәм уртанчы Җәмәрәтләрг ә таш атканнан соң. | Кәгъбә тирәли тәваф кылганда | Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөргәндә |

## Гомрә белән Хаҗны үтәү тәртибе.

Микатка җиткәч, госел коеныгыз, гәүдәгезгә (баш һәм сакалыгызга) ислемайлар сөртегез, шуннан соң “Тәмәттуг” хаҗы өчен Гомрә үтәү нияте белән ихрамга керегез, аннан соң тәлбия сүзләрен әйтеп, Мәккәгә юнәлегез [18]. Харам мәчетенә җиткәч Кәгъбә тирәли җиде тапкыр әйләнегез – бу Гомрә хаҗының тәвафы булыр. Шунысын белү мөһим: бөтен мәчет тәваф кылу урыны булып тора, һәм тәвафны Кәгъбә янәшәсендә үк кыласызмы, аннан ерактаракмы, анысы һич мөһим түгел. Шулай да, әгәр этеш-төртеш булмаса, Кәгъбә янәшәсендә булу хәерлерәк, әгәр этеш-төртеш булса, Кәгъбәдән ерагай – бу мәсьәләдә сайлап алу өчен киңлек бар, Аллаһка мактаулар булсын. Тәвафның соңында Ибраһимның басып торган урыны (мәкам) артында ике рәкәгать намаз укыгыз. Мөмкинчелек булса, аңа якынрак килү хәерле, мөмкинчелек булмаса, кайда да укырга ярый, иң мөһиме – намаз башкарганда ул сезнең белән Кәгъбә арасында калырга тиеш. Шуннан соң Гомрәгә кагылган тагын бер гамәлне - Сәфа белән Мәрва таулары арасында йөрергә керешегез, йөрүне Сәфа тавыннан башларга кирәк. Әлеге таулар арасында йөрү җиде тапкырга тулгач, бөтен башыгыздагы чәчләрне кистерегез. Башның бер өлешендәге чәчләрне генә кисү җитми – күпчелек кешеләр болай эшли дип, аларга кызыгып алданмагыз. Зөл-Хиҗҗә аеның сигезенче көне килгәч, госел коеныгыз, ислемайлар сөртегез һәм килгән урыныгыздан Хаҗ үтәү нияте белән ихрамга керегез. Шуннан соң Мина үзәнлегенә барыгыз, шунда өйлә, икенде, ахшам, ястү һәм иртәнге намазларны укыгыз, намазларны укыган вакытта дүрт рәкәгатьлеләрен ике рәкәгать итеп кыскартып укыгыз, әмма бергә кушып укымагыз, чөнки пәйгамбәрегез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Мәккә һәм Минада намазларны кыскартып, әмма бергә кушмыйча укыды. Тугызынчы көннең (Гарәфә көне) кояшы чыккач, Аллаһ каршында түбәнчелекле һәм басынкы кыяфәт белән, тәлбия сүзләре әйтеп, Гарәфә тавына юнәлегез. Анда булганда өйлә вакытында өйлә белән икенде намазларын бергә кушып, әмма икесен дә ике рәкәгатькә кадәр кыскартып укыгыз. Шуннан соң, һәрвакыт таһәрәтле булырга тырышып һәм Кәгъбә ягына йөзне юнәлтеп (хәтта тау сезнең артта калса да, шулай эшләү тиешле, чөнки нәкъ менә Кәгъбә ягына йөз белән борылу динебездә кабул ителгән гамәл) үзегезне Аллаһка зикер һәм догалар әйтүгә багышлагыз. Гарәфә тавының чикләрен игътибар белән күзәтеп торыгыз, чөнки күп очракта хаҗилар аның чикләреннән чыгып китәләр, ә Гарәфәдә тормаган кешенең Хаҗы дөрес булмый. Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әйтте: *“Хаҗның мәгънәсе – Гарәфәдә тору».* Гарәфә тавының бөтен территориясе: аның көнчыгышы, көнбатышы, төньяк һәм көньягы да, Уран үзәнлегеннән кала, тору урыны булып тора. Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әйтте: *“Мин монда бастым, әмма Гарәфә тавының бөтен территориясе – тору урыны”*. Кояш баеганын тикшереп белгәннән соң, пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) кушканча, Аллаһ каршында булдыра алганча түбәнчелекле һәм басынкы булырга тырышып, тәлбия сүзләрен әйтә-әйтә Мөздәлифәгә юнәлегез. Ул да бит Гарәфәдән кузгалгач, дөясенең башы иярнең өзәңгесенә якын булырлык итеп, йөгәнен каты итеп тартып барды, һәм шул вакытта ул, кулы белән ишарәләп: *“Тыныч булыгыз, кешеләр, тыныч булыгыз!”* – дип әйтә иде. Мөздәлифәгә җиткәч, анда ахшам һәм ястү намазларын укыгыз, анда таң атканчы төн үткәрегез. Хәлсезләр исә үзәнлектән төннең ахырында китә алалар. Иртәнге намазны укыганнан соң, кояш чыгу вакыты якынлашканчыга кадәр, Кәгъбә ягына юнәлеп, Аллаһны зурлагыз һәм мактагыз, Аңа зикер һәм догалар белән ялварыгыз. Шуннан соң кояш чыкканчы Минага юнәлегез. Шуннан соң җиде таш җыеп, Мәккәгә барысыннан да якынрак урнашкан Соңгы Җәмәрәткә барыгыз. Кояш чыкканнан соң Аллаһны “Аллаһу әкбәр” сүзләрен әйтеп зурлап, мактап һәм Аның каршында түбәнчелекле булып, җәмәрәткә бер-бер артлы җиде ташны атыгыз.

Исегездә тотыгыз: таш атуның төп максаты – ул Аллаһны зурлау һәм Аны зикер итү. Ташның баганага эләгүе шарт булып тормый, әмма аның янәшәсендә билгеләнгән урынга эләгүе мәҗбүри. Таш ату тәмам булгач, корбан чалуга (һәдий) тотыныгыз. Әлеге корбан чалуның шартлары нәкъ бәйрәм көннәрендә корбан чалган кебек үк. Үзегез өчен корбан чалуны башка кешегә тапшыру мәсьәләсендә дә авырлык юк. Корбан чалганнан соң башыгыздагы чәчләрне тулаем кырыгыз. Башның бер өлешен генә кыру ярамый, бөтен өлешен дә кыру мәҗбүри.  Хатын-кызларга исә чәчләрен бармакның бер буыны кадәр кыскарту тиешле. Шулай итеп, сез ихрамнан беренче (тулаем булмаган) чыгуны башкардыгыз һәм сезгә гадәти кием кияргә, тырнак кисәргә, ислемайлар сөртергә ярый, әмма хатын-кыз белән якынлык кылу гына тыелган килеш кала. Шуннан соң, өйлә намазына кадәр Мәккәгә юнәлегез һәм Хаҗ өчен Кәгъбә тирәли әйләнегез, шулай ук Сафа белән Мәрва таулары арасында йөрегез һәм Минага кайтыгыз. Кәгъбә тирәли әйләнгәннән, Сафа белән Мәрва арасында йөргәннән, таш атканнан һәм чәчләрне кырганнан соң – сез тулысынча ихрам халәтеннән чыгасыз, һәм сезгә ихрамга кадәр рөхсәт ителгәннәрнең барысы да рөхсәт ителә, шул исәптән, хатын-кыз белән якынлык та. Әй кешеләр! Бәйрәм көнендә хаҗи дүрт  йола башкара: Җәмәрәткә таш ату, шуннан соң корбан чалу, шуннан соң чәчләрне кыру, шуннан соң Кәгъбә тирәли тәваф кылу һәм Сафа белән Мәрва арасында йөрү – әлеге йолаларның шушы тәртибе яхшырак дип исәпләнә. Тик бу тәртип бозыла калса да, әйтик чәчне корбан чалганчы алдырсаң да, монда бер дә проблема юк. Шулай ук Кәгъбә тирәли тәвафны һәм Сафа белән Мәрва арасында йөрүне Минадан киткәнчегә кадәр кичектереп торсагыз да ярый. Шулай ук корбан чалуны унөченче көнгә кадәр кичектереп торсагыз һәм бу гамәлне Мәккәдә башкарсагыз да, бигрәк тә әгәр монда файда һәм хаҗәт булса, бу мәсьәләдә дә авырлык юк. Айның унберенче көне алдыннан килүче төнне Минада үткәрегез. Төштән соң өч җәмәрәтнең һәрберсенә дә чиратлан: башта беренчесенә, аннан уртадагысына, аннан соң соңгысына таш атыгыз. Аларның һәрберсенә, һәр атуда “Аллаһу әкбәр!” дип Аллаһны зурлап, җидешәр таш атыла. Бәйрәм көнендә таш ату вакыты – әгәр кешенең моны үтәргә мөмкинчелеге булса, кояш чыкканнан алып баеганчыга кадәр. Әгәр дә кеше хәлсез булса, аның өчен вакыт Бәйрәм көне алдыннан килгән төннең ахырыннан санала башлана. Башка көннәрдә таш ату вакыты төштән соң башланып кояш баегач тәмамлана, әлеге йоланы төшкә кадәр башкару тыелган. Әгәр көндез кешеләр бик күп булса һәм шул сәбәпле этеш-төртеш башланса, бу очракта ташларны төнлә ату рөхсәт ителә. Әгәр бу гамәлне буе кечкенә булу, картлык яки авыру сәбәпле үзе эшли алмаса, мондый кеше таш атуны башка кешегә дә кушарга мөмкин. Әлеге йоланы үтәү кушылган кеше үзе өчен дә, кушкан кеше өчен дә ташны бер урыннан торып атса була, әмма ул таш атуны үзеннән башларга тиеш. Уникенче көндә ташларны атып бетергәч, Хаҗның йолалары үтәлгән булып санала, һәм сезнең сайлау мөмкинчелегегез бар: теләгегез булса, Минаны калдырып китәргә мөмкинсез, яки унөченче көн алдыннан килүче төнне Минада үткәрүне дә сайлап ала аласыз һәм төштән соң Җәмәрәтләргә таш ату йоласын кабаттан башкара аласыз. Икенче вариант хәерлерәк, чөнки  пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) шул рәвешле эшләде. Мәккәдән китәргә уйласагыз, Кәгъбә тирәли саубуллашу тәвафы ясагыз. Хәез һәм нифас халәтендәге хатын-кызлар  исә бу гамәлне башкармый, шулай ук аларга мәчет ишеге янына килеп, аның янәшәсендә торырга да рөхсәт ителмәгән.

# Хаҗ темасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар

**1. Хаҗ мәҗбүри булган шартларны санагыз.**
1) ___________________________________________________________
2) ___________________________________________________________
3) ___________________________________________________________
4) ___________________________________________________________
5) _________________________________________ хатын-кызлар өчен генә.

**2. Хаҗның ничә әркәне бар?**

- Ике;
- Өч;
- Дүрт.

**3. Ихрам – Хаҗның бер әркәне, аның мәгънәсе – ике кисәк ак тукыма кию (җилкәләргә япма һәм билгә бәйләвеч)**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**4. Тәваф әл-Ифәдә һәм Таваф әл-Кудум – бер үк нәрсә түгел. Беренче тәваф әркән булып тора, икенчесен эшләү исә хәерле гамәл.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**5. Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) хаҗ гамәлен өч тапкыр үтәде.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**6. Хаҗны аның мәҗбүрилеге шартлары үтәлгән сәгатьтә үк башкарырга кирәк.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**7. Мәккә халкы ихрам халәтенә Яләмләм микатында керәләр.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**8. Гомрә өчен вакыт микаты – ул Рамазан ае.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**9. Бушлыкларны тулыландыр:**
Хаҗ һәм Госмрә гомердә ______________ тапкыр _______ . Кем Хаҗ кылды һәм ______________ һәм _______________, ул кеше анадан туган кебек гөнаһысыз кайтыр. Ә барлык шартлары да үтәлеп кылынган хаҗның әҗере ___________.

**10. Мәккә халкы Хаҗ өчен ихрамга кергәндә Мәккә шәһәреннән чыгалар.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**11. Хатын-кыз ихрамга кергәндә ак кием кияргә тиеш.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**12. Ихрамга керергә җыенган кешегә ислемайны ____________ хәерле, әмма ________________сөртелергә тиеш түгел.**
**13. Хатын-кызга үзенә үлчәп тегелгән күлмәк кию рөхсәт ителми.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**14. Уң як җилкәне шәрәләндерү хәерле:**

- Гомрә тәвафында;
- Таваф әл-Кудум вакытында;
- Мәккәгә килгән вакыттагы тәвафта;
- Беренче һәм икенче вариантларда;
- Бөтен вариантлар да дөрес.

**15. Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөргәндә нык кызулану тиешле.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**16. Сафа белән Мәрва арасын йөрүне Мәрва тавыннан башларга кирәк.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**17. Хаҗилар Гарәфәдән кояш баеганчы китәргә тиешләр.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**18. Гарәфәдә тору – Хаҗның мәҗбүри булган гамәлләренең берсе.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**19. Хаҗ йолалары ____________ көнендә башлана һәм ______________ көнендә тәмамлана.**

**20. Гарәфә тавының өстенә үк менү кирәк түгел.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**21. Корбан чалу (хадй) тәмәттуг һәм кыйран хаҗларын башкаручы кешеләр өчен мәҗбүри һәм ифрада башкарган очракта тиешле, хәерле.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**22. Тәлбия сүзләрен әйтү Бәйрәм көнендә соңгы җәмәрәткә таш ату белән тәмамлана.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**23. Ташларның баганалар янәшәсендәге билгеләнгән урынга әләгүе җитә.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**24. Әт-Тәшрик көннәрендә (бәйрәмнән соңгы өч көндә) таш ату йоласы төштән соң башлана.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**25. Соңгы җәмәраткә таш атканнан соң Аллаһка дога белән мөрәҗәгать итү тиешле.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**26. Ифрад һәм кыйран хаҗын үтәүчеләр Сафа һәм Мәрва таулары арасында _______________йөриләр, ә тәмәттуг хаҗы очрагында Сафа белән Мәрва таулары арасында_______________йөрелә.**

**27. Ошбу очракларга карата шәригать хөкемнәрен аңлат:**

| Очрак | Хөкеме |
|---|---|
| Баланың хаҗы | |
| Мәхрәмсез хатын-кызның хаҗы. | |
| Әҗәте булган кешенең хаҗы | |

# Унбишенче дәрес

**Унбишенче дәрес: ҺӘР МӨСЕЛМАНГА ХАС БУЛЫРГА ТИЕШЛЕ ӘХЛАК СЫЙФАТЛАРЫ**

Әлеге дәрес һәр мөселманга хас булырга тиешле әхлак сыйфатларына багышланган. Аларга шушы сыйфатлар керә: *дөреслек, ышанычлылык, әхлакый пакьлек, оялчанлык, кыюлык, юмартлылык, вәгъдәгә тугрылык, Аллаһ тыйган нәрсәләрдән ерак булу, күршеләр белән яхшы мөнәсәбәттә булу, мөмкинчелек булганда мохтаҗларга ярдәм итү һәм Коръән белән Сөннәттә күрсәтелгән башка сыйфатлар.*

## Мөһим искәрмәләр

- **Дөреслек** – кеше үзенең сүзләрендә, эшләрендә һәм ышануларында Аллаһ каршында дөрес булырга тиеш. Шулай ук Аллаһ коллары белән мөнәсәбәттә дә әлеге сыйфат бик мөһим. Аның капма-каршысы – ялганчылык;
- **Ышанычлылык** – бу кеше өстендәге бөек амәнәт. Аның капма-каршысы - хыянәт;
- **Әхлакый пакьлек** – барлык тыелган нәрсәләрдән дә үз-үзеңне тотып тору;
- **Оялчанлык** – барлык мактауга лаек гамәлләрне кылуны һәм барлык начар гамәлләрне калдыруны үз эченә алган сыйфат;
- **Күршеләр белән яхшы мөнәсәбәттә булу** – аның эченә кергән сыйфатларның берсе – күршеләреңнең башкалардан яшерергә теләгән нәрсәләрен күзәтмәү һәм карашларны төшерү;
- **Мохтаҗларга ярдәм** – Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әйтте: “**Әгәр кеше бу дөньяда иманлы бәндәнең кайгы-хәсрәтен таратса, Аллаһ Кыямәт көнендә аның кайгы-хәсрәтен таратыр. Әгәр кеше мохтаҗлык кичергән кешенең тормышын җиңеләйтсә, Аллаһ аның дөньялыктагы тормышын да, киләчәк тормышын да җиңеләйтер. Әгәр кеше бер мөселманның гөнаһысын яшереп калдырса, Аллаһ бу дөньяда да, соңгы тормышта да ул кешенең үзенең гөнаһларын яшерер. Аллаһ Тәгаләә кешегә ул үзенең кардәшенә булышудан туктаганчыга кадәр ярдәм итә**”. Хәдисне имам Мөслим китерә.

# Уналтынчы дәрес

## Уналтынчы дәрес: ИСЛАМ ДИНЕ ЭТИКЕТЫ

Әлеге дәрес ислам әхлакый этикасына багышлана. Бу нормаларга: сәламләү, ачык йөзлелек; уң кул белән ашау һәм эчү; ашар алдыннан Аллаһның исемен телгә алу, һәм ашаганнан соң Аллаһны мактау; төчкергән кешенең Аллаһны мактавы, һәм, төчкергәч, Аллаһны мактаган кешегә “Ярхәмукә-Ллаһ” (Аллаһ сиңа шәфкатьле булсын) сүзләре белән җавап кайтару; авыру кешенең хәлен белү; җеназа намазы уку һәм җирләү өчен мәетне озата бару; мәчеткә яки өйгә кергәндә, чыкканда, сәфәргә кузгалганда шәригать кагыйдәләрен үтәү; әти-әниләр, күршеләр, өлкән кешеләр һәм балалар белән мөнәсәбәтләрдә этикет кагыйдәләрен үтәү; бала туу һәм өйләнү белән котлау; кайгы уртаклашуны белдерү; һәм шулай ук ислам этикетының башка кагыйдәләрен, шул исәптән, өс һәм аяк киемнәрен салу һәм киюгә кагылышлы кагыйдәләрне дә үтәү кирәк.

Мөһим искәрмәләр:

- **Сәламләү** – сәламләүнең иң яхшы ысулы: “Әс-Саләму галәйкум уә рахмәту-Ллаһи уә бәракәтуһ”, - дип әйтү. Кешеләрне беләсеңме син яки юкмы – мөһим түгел, аларның барчасын да сәламләү тиешле(Мөселманар арасында булганда). Сәламләүгә җавап бирү фарыз;
- **Уң кул белән ашау һәм эчү** – бу мәҗбүри. Ашаганда өч бармак белән ашарга кирәк. Шулай ук кешедән нәрсәдер алганда да, аңа нәрсәдер биргәндә дә моны уң кул белән эшләү хәерле;
- **Ашар алдыннан Аллаһның исемен телгә алу** - ягъни “Бисми-Лләһ”, - дип әйтү;
- **Ашап бетергәннән соң, сөннәттә килгәнчә, Аллаһны мактау**, мәсәлән: “Әл-Хәмду ли-Лләһи әл-ләзи әтгәмәни хәзә уә разакани мин гайри хаулин минни уә лә куввә”, - дип әйтү [19];
- **Ашаганда үзеңә якынрак торган ризыкны ашау тиешле**, һәм ризыкны гаепләргә ярамый;

- **Төчкергән кешенең Аллаһны мактавы** - ягъни “Әл-хәмду ли-Лләһ”, - дип әйтү.

- **Төчкергәч, Аллаһны мактаган кешегә** “Ярхәмукә-Ллаһ” (Аллаһ сиңа шәфкатьле булсын) сүзләре белән җавап кайтару – моңа җавап итеп төчкергән кеше: “Яхдикуму-Ллаһу уә юслиху бәләкум”, - диярга тиеш [20];

- **Авыру кешенең хәлен белү** – хәл белергә берничә мәртәбә килү тиешле, ләкин авыру янына уңайлы вакытны сайлап барырга, аның янында озак утырмаска, Аллаһның рәхимлелегенә кагылышлы мәсьәләдә төшенкелеккә китермәскә кирәк;

- **Җеназа намазы уку** һәм җирләү өчен мәетне озата бару ирләргә кагыла, хатын-кызга алай эшләү тиеш түгел;

- **Мәчеткә яки өйгә кергәндә**, чыкканда шәригать кагыйдәләрен үтәү – мәчеткә кергәндә уң аяктан атлап: “Бисми-Лләһ. Уәс-саләту уәссаләму гәлә расули-Лләһ. Аллахуммә-фтах ли әбвәбә рахмәтикә”, - дип әйтеп керергә кирәк. Чыкканда исә сул аяктан атлап һәм: “Бисми-Лләһ. Уәс-саләту уәссаләму гәлә расули-Лләһ. Аллаһуммә инни әс-әлүкә мин фәдликә”, - сүзләрен әйтеп чыгалар. Өйдән чыкканда: “Бисми-Лләһи уә тәвәккәльту гәлә-Ллаһ. Уә лә хәулә уә лә куввәтә иллә би-Лләһ. Аллаһуммә инни әгузу бикә ән әдыллә әу удаллә, әу әзиллә әу узаллә, әу әзлимә әу узләмә, әу әҗхалә әу юҗхалә гәләй”, - дип әйтү тиешле [21], ә кергәндә: “Аллаһуммә инни әс-әлүкә хайраль-мәулиҗи уә хайральмәхраҗи. Бисми-Лләһи уәләҗнә, уә бисми-Лләһи хараҗнә, уә гәлә-Лләһи Раббинә тәвәккәлнә”, - дип әйтергә [22], шуннан соң гаиләңне сәламләргә кирәк;

- **Никах белән котлау** – ягъни өйләнешүчеләргә: “Бәрака-Ллаһу ләкумә уә бәракә-Ллаһу гәләйкумә, уә җәмәгә бәйнәкумә фи хәйрин”, - дип әйтү [23];

- **Кайгы уртаклашуны белдерү** – өч көн булып, аннан да артмаска тиеш.

# Унҗиденче дәрес

## Унҗиденче дәрес: ШИРЕКТӘН КИСӘТҮ ҺӘМ ГӨНАҺЛАРНЫҢ ТӨРЛӘРЕ

Әлеге дәрес ширектән һәм төрле гөнаһ гамәлләрдән кисәтүгә багышланган. Һәлакәткә илтүче җиде төрле гөнаһ бар: Аллаһка тиңдәшлек кылу (ширек); сихер; Аллаһ гомерен кагылгысыз итеп яраткан кешенең хаксызга җанын кою, рибачылык (процентка акча бирү яки алу); ятимәрнең хакын ашау; яу кырыннан качу; гөнаһ кылу хәтта уйларында да булмаган гыйффәтле, пакь иманлы хатын-кызларны зинада гаепләү. Зур гөнаһларга керүчеләр арасыннан шушыларны санарга мөмкин: әти-әнигә буйсынмау; туганлык җепләрен өзү; ялган шаһитлык бирү; ялган ант итү; күршегә уңайсызлыклар тудыру; кешеләргә, аларның тормышларына карата да, намусларына һәм милекләренә карата да җәбер-золым кылу; исерткеч матдәләр куллану; комарлы уеннар; кешене яманлау һәм гайбәт; Аллаһ һәм Аның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) тыйган башка гамәлләр.

## Мөһим искәрмәләр

- **Аллаһка тиңдәшлек кылу** (ширек) – ул зур ширекне дә, кече ширекне дә үз эченә ала;
- **Сихер** – моңа бозымны сихер ярдәмендә чыгару да, сөйдергечләр ясау да керә. Сихерчелек белән шөгыльләнгән яки аннан риза булган кеше имансыз була. Сихерчеләргә бару, аларның сайтларына керү, алар хакында булган телетапшырулар карау, йолдызнамәләр белән газета-журналлар уку тыела. Сихер сихерчелек белән бетерелми, ә шәригатьтә рөхсәт ителгән өшкерүләр, догалар һәм башка чаралар (мәсәлән, хиджәмә) ярдәмендә чыгарыла;
- **Аллаһ гомерен кагылгысыз итеп яраткан кешенең хаксызга җанын кою...** – һәм аның мөселман яки мөселманнар җирендә яшәүче яки алар белән килешү төзегән, яки мөселманнар җирендә куркынычсызлык вәгъдә ителгән имансыз булуы да мөһим түгел;

- **Ятим** – ул женси өлгерү чорына житмәгән әтисез калган бала;
- **Яу кырыннан качу** – сүз Аллаһ юлында көрәшүче гаскәрләр турында бара;
- **Гыйффәтле, пакь хатыннарны гаепләү** … - биредә сүз иректе (кол булмаган) хатын-кызлар турында бара;
- **Ялган ант итү** – шулай ук Аллаһтан башка берәр зат яки әйбер белән ант итү, мәсәлән, пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) исеме белән яки кемнеңдер гомере, намусы, каберләр, чал чәч яки сакал белән ант итү;
- **Азартлы уеннар (мәйсир)** – ул ни дә булса оту яки милекне оттыруга корылган барлык мөнәсәбәтләр (уен, килешү);
- **Гайбәт(гиба)** - пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) аңа болай дип билгеләмә бирде: “Кардәшеңне аңа ошамаган рәвешле телгә алу”;
- **Сүз йөртү (нәмимә)** – кешеләр арасында сүзләр, имеш-мимешләр тарату;

## Ислам динендә ярышларның хөкеме

| Катнашучылардан бүләк өчен түләү кертү дә, кертмәү дә рөхсәт ителгән: | Нинди генә очракта да тыелган: | Катнашучылардан бүләк өчен түләү керткән очракта тыелган, түләү кертмәгән очракта рөхсәт ителгән: |
| --- | --- | --- |
| Дөя, ат чабышлары, җәядән ату ярышлары. | Нардлар, шахматлар һәм башка шундый уеннар. | Телгә алынмаган башка ярышлар |

# Унсигезенче дәрес

## Унсигезенче дәрес: МӘЕТНЕ ҖИРЛӘРГӘ ӘЗЕРЛӘҮ, ЖЕНАЗА НАМАЗЫ ҺӘМ АНЫ ҖИРЛӘҮ

Әлеге темага кагылышлы булган менә нәрсәләрне белергә кирәк:

**Беренчедән**, үлем түшәгендә ятучы кешегә “Лә иләһә иллә-Ллаһ” сүзләрен исенә төшереп тору тиешле, пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әйтте: **“Вафат булучыларыгызга: “Лә иләһә иллә-Ллаһ” сүзләрен искә төшерегез”.** “Вафат булучыларыгызга” – ягъни якынлашып килүче үлем билгеләре күренгән кешеләр;

**Икенчедән**, әгәр кеше вафат булса һәм аның вафатында шикләр булмаса, сөннәткә муафыйк рәвештә аның күзләрен йомдырырга һәм ияген бәйләп куярга кирәк;

**Өченчедән**, мөселман булган кешенең тәнен юу мәҗбүри. Бары тик яу кырында шәһит киткән кешенең генә тәне юылмый, аңа җеназа намазы да укылмый, аны үз киемнәре белән җирлиләр, чөнки пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Өхед янындагы сугышта һәлак булучыларны юмады һәм җеназа намазы да укымады;

**Дүртенчедән**, мәетне юу тәртибе:

Мәетнең гаурәтен каплау тиешле, шуннан соң аның гәүдәсен бераз гына күтәрергә һәм йомшак кына эченә басарга кирәк (эчәклектә булган нәрсәләр чыксын өчен). Шуннан соң мәетне юучы, кулына тукыма кисәге урап, аның ярдәмендә мәетне истинҗа кылдырырга тиеш. Моның соңында мәеткә, намаз алдыннан алган кебек, тәһарәт алдырырга кирәк. Шуннан соң Ююба агачы (Сидр) яфракларыннан ясалган төнәтмә яки шуның ише нәрсә белән кушылган су белән аның башы һәм сакалы юыла. Аннары мәетнең уң як ягы, соңыннан сул як ягы юыла...

Әлеге эзлеклелекне икенче һәм өченче тапкыр эшләү кирәк һәм һәрберендә мәетнең эченә басып, кулны эч буйлап аска таба шудырырга кирәк. Әгәр шуннан соң да эчәклектәге нәрсәләр чыгудан туктамаса, арт юлны юарга һәм тукыма кисәге я шуңа охшаш берәр нәрсә белән томалап куярга кирәк, әгәр ул да булышмаса, бу очракта кызыл балчык яки заманча медицина чаралары (мәсәлән, пластырь һәм башка шундыйлар) кулланыла, шуннан соң тәһәрәт алуны янәдән кабатларга кирәк. Әгәр өч тапкыр юганнан соң да тән чистармаса, аны биш яки җиде тапкыр юарга һәм киптерергә кирәк. Тәннең юарга кыен булган җирләренә (култык аслары, ботның эчке өлешләре), шулай ук гәүдәнең сәҗдә кыла торган өлешләренә ислемай сөртергә кирәк, ә ислемайны бөтен тәнгә сөртү хәерлерәк. Әгәр мәетнең мыеклары һәм тырнаклары озын булса, аларны кыскарту тиеш, тик аларны шул килеш калдырсаң да, куркыныч юк. Аның чәчәләрен тарау, касыгындагы чәчләрне кыру, сөннәткә утырту кирәкле эш түгел, чөнки шәригатьтә моңа күрсәтмәләр юк. Хатын-кызның чәчләрен өч толымга үрергә һәм артка куярга кирәк.

**Бишенчедән**, мәетне кәфенгә төрү. Ир-атны, пәйгамбәребезне (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) төргән кебек, өч кисәк ак тукымага төрү хәерлерәк. Кәфенлеккә күлмәк тә, чалма да керми, әмма мәеткә күлмәк кидертеп, биленә тукыма урасаң һәм җәймә белән төрсәң дә, куркыныч юк. Хатын-кызга исә биш төрле кием кидертәләр: киң күлмәк, химар (тәнгә төшеп торучы баш киеме), билгә урарга тукыма һәм ике җәймә. Кечкенә малайны бер төрле генә киемгә киендерергә дә ике, өч төрле киемгә дә киендерергә була. Кыз балага исә күлмәк кидертеп, ике җәймәгә төрәләр. Ә иң азы, һәркемгә дә бөтен тәнне каплап торучы бер төрле кием кидертү фарыз.

Әгәр ир кеше ихрам халәтендә вафат булса, аның тәнен Ююба (сидр) төнәтмәсе кушылган су белән юарга һәм үзендә булган ике кисәк тукымага төрергә яисә башка кием кидерергә кирәк, тик аның башы да, йөзе дә ябылмый. Шулай ук аңа ислемайлар да сөртергә кирәк түгел, чөнки ул Кыямәт көнендә кабердән тәлбияләр әйтә-әйтә кубарылачак, бу хакта Аллаһ илчесенең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) ышанычлы, сахих хәдисендә килә. Әгәр хатын-кыз ихрам халәтендә вафат булса, аны башка хатын-кызларны төргән кебек кәфенлеккә төрәләр, әмма шулай ук аңа ислемайлар сөртергә, никаб һәм перчаткалар кидертергә кирәк түгел. Аның битен һәм кулларын үзе төрелгән җәймә (кәфенлек) белән капларга кирәк.

**Алтынчыдан**, ир затыннан булган мәетне юарга, шулай ук җеназа намазы укырга һәм җирләргә барысыннан да бигрәк ул үзе васыять итеп калдырган кешенең, аннан соң әтисенең, бабасының, шуннан соң, туганлык һәм якынлык дәрәҗәсенә карап, калган туганнарының хакы бар. Хатын-кыз затыннан булган мәеткә килгәндә исә, бу эшләрне башкарырга барысыннан да бигрәк вафатына кадәр үзе васыять итеп калдырган хатын-кызның, аннан соң әнисенең, шуннан соң әбисенең, шуннан соң, туганлык һәм якынлык дәрәҗәсенә карап, калган кыз туганнарының хакы бар. Ир белән хатынга килгәндә, алар бер-берсенең тәнен юа алалар, чөнки Әбу Бәкернең җәсәден аның хатыны юган, ә Гали үзенең хатыны Фатыйманың (Аллаһ аннан риза булсын) җәсәден юган.

**Җиденчедән**, җеназа намазын уку тәртибе. Җеназа намазы дүрт тәкбирдән (“Аллаһу әкбәр” сүзләреннән) тора. Беренче тәкбирдән соң “Әл-Фәтиха” сүрәсе укыла, әгәр аннан соң, Ибн Габбас (Аллаһ аннан риза булсын) тарафыннан китерелгән хәдистә әйтелгәнчә, берәр кыска сүрә яки бер-ике аять укылса, яхшы була. Шуннан соң икенче тәкбирне әйтергә һәм, тәшәххудтә укылганча, пәйгамбәребезгә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) салаватлар укырга кирәк. Өченче тәкбирдән соң мәрхүм өчен дога кылына:

اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِحَيِّنَا وَمَيِّتِنَا، وَشَاهِدِنَا وَغَائِبِنَا، وَصَغِيرِنَا وَكَبِيرِنَا، وَذَكَرِنَا وَأُنْثَانَا. اللَّهُمَّ مَنْ أَحْيَيْتَهُ مِنَّا فَأَحْيِهِ عَلَى الْإِسْلاَمِ، وَمَنْ تَوَفَّيْتَهُ مِنَّا فَتَوَفَّهُ عَلَى الإِيمَانِ، اللَّهُمَّ لاَ تَحْرِمْنَا أَجْرَهُ، وَلاَ تُضِلَّنَا بَعْدَهُ

“Йә Аллаһ, безнең тереләребезне дә, үлгәннәребезне дә, биредә булганнарыбызны да, булмаганнарыбызны да, яшьләребезне дә, олыларыбызны да, ирләребезне дә хатын-кызларыбызны да ярлыка. Йә Аллаһ, исән булганнарыбызны ислам динендә яшәт, ә үлгәннәребезне иман белән бу дөньядан күчер! Йә Аллаһ, аның өчен безне әҗердән мәхрүм итмә, һәм аннан соң да туры юлдан тайпылдырма!” [24] яки бу дог укыла:

اللَّهُمَّ اغْفِرْ لَهُ وَارْحَمْهُ، وَعَافِهِ، وَاعْفُ عَنْهُ، وَأَكْرِمْ نُزُلَهُ، وَوَسِّعْ مُدْخَلَهُ، وَاغْسِلْهُ بِالْمَاءِ وَالثَّلْجِ وَالْبَرَدِ، وَنَقِّهِ مِنَ الْخَطَايَا كَمَا نَقَّيْتَ الثَّوْبَ الأَبْيَضَ مِنَ الدَّنَسِ، وَأَبْدِلْهُ دَاراً خَيْراً مِنْ دَارِهِ، وَأَهْلاً خَيْراً مِنْ أَهْلِهِ، وَزَوْجاً خَيْراً مِنْ زَوْجِهِ، وَأَدْخِلْهُ الْجَنَّةَ، وَأَعِذْهُ مِنْ عَذَابِ القَبْرِ

“Йә Аллаһ, аны кичер һәм ярлыка, аны начарлыктан сакла, һәм аны яхшы итеп кабул ит, аның каберен иркен ит, һәм кар вә боз белән ю, киемнәрене пычрактан чистарткан кебек, аны гөнаһлардан арындыр, һәм аңа алмашка аның йортыннан яхшырак йорт, гаиләсеннән яхшырак гаилә, хатыныннан яхшырак хатын бир, аны Җәннәткә керт һәм кабер газабыннан ут газабыннан сакла, каберен иркен һәм якты кыл! Йә Аллаһ, аның өчен безне әҗердән мәхрүм итмә, һәм аннан соң да туры юлдан тайпылдырма!” [25]

Шуннан соң дүртенче тәкбир һәм уң якка бер тәслим (“Әссәләму гәләйкум уә рахмәту-Ллаһ”) әйтелә. Һәр тәкбир саен кулларны күтәрү тиешле.

Әгәр җеназа намазы хатын-кызга укылса, бу очракта “Я Аллаһ, аны гафу кыл (Аллаһуммәгьфир ләһи)”,

әгәр мәетләр икәү булса, “Я Аллаһ, аларның икесен гафу ит (Аллаһуммә-гьфир ләһумә)” диелә.

Әгәр мәрхумнәр өч я аннан да артыграк булса, “Я Аллаһ, аларны гафу ит (Аллаһуммә-гьфир ләһум…)” дияргә кирәк.

Әгәр вафат булган кеше бала булса, гафу сорау догасы урынына ошбу сүзләрне әйтергә кирәк:

اللَّهُمَّ اجْعَلْهُ فَرَطاً وَذُخْراً لِوَالِدَيْهِ، وَشَفِيعاً مُجَاباً، اللَّهُمَّ ثَقِّلْ بِهِ مَوَازِينَهُمَا، وَأَعْظِمْ بِهِ أُجورَهُمَا، وَأَلْحِقْهُ بِصَالِحِ الْمُؤْمِنِينَ، وَاجْعَلْهُ فِي كَفَالَةِ إِبْرَاهِيمَ، وَقِهِ بِرَحْمَتِكَ عَذَابَ الْجَحِيمِ

“Йә Аллаһ, шулай эшлә ки, ул Җәннәткә эти-энисеннән алданрак керсә иде һәм алар өчен алдан әзерләнгән әҗер һәм шәфәгать челеге кабул ителә торган шәфәгатьче булса иде, йә Аллаһ, аларның үлчәүләрен авырайт, бу бала сәбәпле аларның әҗер-савапларын күбәйт һәм аны иманлылар рәтенә керт, аны Ибраһим (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) яклавы астына куй һәм аның Рәхимлегең сәбәпле Җәһәннәм газапларыннан сакла!” [26]

Сөннәт буенча әгәр мәрхүм ир кеше булса, имам аның башы каршында, хатын-кыз булса, гәүдәсенең уртасы каршында торырга тиеш. Әгәр мәрхүмнәр күп булса, ирләрнең мәетләре имамга якынрак, ә хатын-кызларның мәетләре кыйблага якынрак ятарга тиеш. Балаларга килгәндә, малайлар хатын-кызлар алдынннан, ә кызлар хатын-кызлардан соң ятарга тиеш. Малай кешенең башы ир кешенең башы тигезлегендә, хатын-кызның гәүдәсенең уртасы ир-атның башы белән бер тигезлектә ятарга тиеш. Шулай ук кыз бала да: аның башы хатын-кыз башы белән бер тигезлектә, ә гәүдәсенең уртасы ир-атның башы белән бер тигезлектә ятарга тиеш. Җеназа намазын укучылар имамның артына баса, имам артында урын тапмаган кешеләр аннан уң якка баса.

**Сигезенчедән**, җирләү тәртибе. Каберне ир-атның буеның яртысы тирәнлегендә казырга кирәк. Кыйбла ягыннан ләхет алына һәм шунда уң ягына куелып, мәетнең гәүдәсе урнаштырыла. Шуннан соң кәфенлекне тотып торучы бауларның төеннәрен чишәргә һәм шунда калдырырга кирәк, әмма мәетнең, ир-ат булса да, хатын-кыз булса да, йөзе ачылмый. Шуннан соң ләхетне плитәләр белән капларга һәм, җирнең авырлыгы астында ишелмәсен өчен, кызыл балчык белән ныгытырга кирәк. Әгәр плитәләр булмаса, ләхетне агач такталар, ташлар белән капларга мөмкин, алар ләхет эченә балчык керүдән сакларга тиеш. Бу вакытта ошбу сүзләрне әйтү тиеш:

بِسْمِ اللَّهِ وَعَلَى سُنَّةِ رَسُولِ اللَّهِ

“Аллаһ исеме белән һәм Аллаһ илчесенең дине белән муафыйк рәвештә”
(Би-сми-Лләһи уә гәлә сүннәти расули-Лләһ)
Кабер өстендәге җирне бер карыш биеклегендә күтәрергә мөмкин. Әгәр мөмкинлек булса, каберне вак таш белән каплап кую һәм аңарга су сибү зарур. Җирләргә килүчеләр бераз вакыт кабер янында торып, вафат булган кеше өчен Аллаһтан дога кылып сорый алалар, чөнки Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын), җирләү тәмам булганнан соң, кабер янына басып: “Кардәшегез өчен Аллаһтан кичерү сорагыз һәм аның өчен Аллаһтан ныклык сорагыз, чөнки хәзер аннан сорау алалар”, - дип әйткән.

**Тугызынчыдан**, җеназа намазын укымаган кеше, пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) эшләгәнчә, намазны мәетне җирләгәч укый ала. Әмма намаз һич тә соңрак түгел, ә бер ай эчендә укылырга тиеш. Бер ай вакыт үткән булса, намаз уку шәригать тарафыннан рөхсәт ителми, чөнки пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) алай эшләмәгән.

**Унынчыдан**, вафат булучының гаиләсеннән булган туганнары кешеләр өчен сый-ризык әзерләргә тиеш түгелләр, бу хакта намуслы сәхәбәләрдән берсе булган Джәрир Ибн АбдуЛлаһ Әл-Бәджәли (Аллаһ аннан риза булсын) әйткән: *“Вафат булган кешенең өендә ризык әзерләү һәм җыелып утыруны без катгый тыелган, дип саный идек”*. Әмма бүтән чит кешенең берәрсе әлеге гаилә яки аларның якын туганнары булган кунаклары өчен ризык әзерләсә, һич куркыныч юк. Вафат булган кешенең гаиләсе өчен ризыкны туганнары һәм күршеләре әзерләсә хәерле. Чөнки пәйгамбәребезгә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Шамда Джәфәр Ибн Әби Талибның вафат булуы хакындагы хәбәр ирешкәч, ул үз гаиләсенә Джәфәр гаиләсе өчен ризык әзерләргә куша һәм: *“Аларга аларны бу эштән бүлә торган нәрсә килде”,* - дип әйтә. Әгәр вафат булган кешенең гаилә әгъзалары килгән ризыктан авыз итәргә дип, күршеләрен дәшсә, куркыныч юк, һәм, безгә билгеле булганча, моның шәригать тарафыннан билгеләп куелган аерым бер вакыты юк.

**Унберенчедән**, хатын-кызга, әгәр вафат булган кеше аның ире булмаса, өч көннән дә ары матәмдә(траурда) булу рөхсәт ителми. Вафат булган кеше аның ире булган очракта, ул дүрт ай (ай календаре буенча) һәм ун көн дәвамында матәмдә(траурда) булырга тиеш. Әгәр хатын-кыз авырлы булса, пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) сөннәтенә муафыйк рәвештә, аның матәме (траурда) бала тугач тәмамлана. Ирләргә килгәндә исә, аларга туганнары яки тагын берәрсе вафаты сәбәпле, матәмдә(траурда) булырга рөхсәт ителми.

**Уникенчедән**, ир-атлар, Аллаһка вафат булганнар өчен дога белән мөрәҗәгать итеп, Аннан алар өчен рәхим-шәфкать сорау өчен, шулай ук үлемне һәм аннан соң булачак вакыйгаларны искә төшерү өчен вакыт-вакыт каберләрне зыярат итә алалар. Пәйгамбәребез дә (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) әйткән: *"Каберләрне зыярат кылыгыз, чөнки алар сезгә Соңгы тормыш хакында искәртәләр"*. Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) үзенең сәхәбәләрен каберләрне зыярат кылганда ошбу сүзләрне әйтергә өйрәтә иде:

السَّلاَمُ عَلَيْكُمْ أَهْلَ الدِّيَارِ، مِنَ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُسْلِمِينَ، وَإِنَّا إِنْ شَاءَ اللَّهُ بِكُمْ لاَحِقُونَ،

وَيَرْحَمُ اللَّهُ الْمُسْتَقْدِمِينَ مِنَّا وَالْمُسْتَأْخِرِينَ أَسْأَلُ اللَّهَ لَنَا وَلَكُمُ الْعَافِيَةَ

"Ий мөэминнәр, сезгә Аллаһның сәламе булсын! Әлбәттә, без дә Аллаһның теләге белән сезгә кушылырбыз. Аллаһ иртәрәк киткәннәрне, әле соңгарак калучыларны ярлыкасын, һәм мин безнең өчен дә, сезнең өчен дә Аллаһтан котылу сорыйм" [27].

Хатын-кызларга килгәндә, аларга каберләрне зыярат кылу рөхсәт ителми, чөнки пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) каберләргә баручы хатын-кызларны ләгънәт кылды. Аларга шулай ук җирләгән вакытта да мәет артыннан бару рөхсәт ителми, чөнки пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) аларны бу эштән тыйды. Мәчеттә яки аның өчен билгеләнгән башка урында укыла торган җеназа намазы мәсьәләсенә килгәндә, ул ирләргә дә, хатын-кызларга да рөхсәт ителгән.

Бу җыя алган мәгълүматның соңысы. Һәм пәйгамбәребезгә, аның гаиләсенә һәм сәхәбәләренә Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын.

**Каберләрне зыярат кылу төрләре**

**Шәригатьтә рөхсәт ителгән (зияра шәргия)**
Кешенең каберлекләргә, сөннәттә тасвирланганча, соңгы тормыш турында искә төшерү яки вафат булганнар өчен Аллаһка дога белән мөрәҗәгать итү, алар өчен Аннан рәхим-шәфкать сорау өчен килүе. Моннан тыш, ул шәригатькә каршы килә торган гамәлләр кылмаска тиеш.

**Бидгать булган (зияра бидгия)**
Кешенең каберлекләргә, кабер янында, Аллаһка дога белән мөрәҗәгать итеп сорау өчен килүе.

**Ширек булган (зияра ширкия)**
Кешенең каберлекләргә, кабердәге мәетләргә дога белән мөрәҗәгать итү өчен килүе.

## Белемнәрне тикшерү өчен сораулар

**1. Мөселман билгеләнгән тәртипкә һәм ислам дине этикетына иярергә тиеш.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**2. Минем динем миңа начар кешеләр белән бергә булырга, яхшы кешеләрдән читтә торырга куша.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**3. Ислам дине безне хезмәтчеләргә, эшчеләргә һәм башкаларга яхшы мөнәсәбәттә булырга өйрәтә.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**4. Башка кешеләргә үзенең теле һәм кулы белән зыян китергән кеше белән дус булып мин дөрес эшлим.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**5. Әгәр мине кемдер мыскылласа, мин аңа җавап бирәм, һәм бу гамәл миңа рәхәтлек, канәгатьлек хисе бирәчәк.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**6. Ислам мине көчсезләргә һәм мохтаҗларга ярдәм итәргә өнди.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**7. Мөселман үзенең авыру кардәшенең хәлен белергә һәм аның өчен дога кылырга тиеш.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**8. Күршеләрнең гөнаһларын күзәтү – иманлы бәндәләрнең әхлакый сыйфаты.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**9. Аллаһ каршында иң сөекле бәндәләр – ул башкаларга күп файда китерүче кешеләр.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**10. Өйдән чыкканда ошбу доганы кылырга кирәк: “БисмиЛләһи уәләджнә, уә бисми-Лләһи хараджнә, уә гәлә-Ллаһи Раббинә тәвәккәлнә”.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**11. Төчкергәннән соң, минем өчен Аллаһтан рәхмәт сораган кешегә мин: “Яхдикуму-Ллаһ уә юслиху бәләкум”, - диярга тиеш.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**12. Аллаһны зикер итү мөселманны саклый һәм Аллаһка якынайта.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**13. Мөселманның кардәшенә булган мәхәббәтенең сыйфатлары нинди?**

________________________________________________

________________________________________________

**14. Мөселманнардан көнләшү – иманның зәгыйфьлегенең бер** билгесе.

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**15. Мәхәббәт барлыкка килүнең нинди сәбәпләре бар?**

________________________________________________

________________________________________________

**16. Тыелган алкоголь эчемлекләргә бары тик вино (хәмер) генә керә.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**17. Ризыкка яки эчемлеккә өрү шелтәләнә.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**18. Ашаганнан соң, кулларны юганчы, кул бармакларын ялау тиешле.**
- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**19. Ризык, кием, бизәнү әйберләре мәсьәләләрендә урталыкта булырга кирәк**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**20. Ир затыннан булган мәетне юарга, шулай ук җеназа намазы укырга һәм җирләргә барысыннан да бигрәк ______________, аннан соң ______________, аннан соң ______________, шуннан соң, _________________ хакы бар.**

**21. Вафат булган кешенең әҗәтен түләргә:**

- Мәҗбүри;
- Хәерле, саваплы;
- Рөхсәт ителгән.

**22. Мәетне җирләү:**

- Хәерле;
- Фарыз кифая;

**23. Үлем түшәгендә ятучы кешегә “Лә иләһә иллә-Ллаһ” сүзләрен исенә төшереп тору:**

- Мәҗбүри;
- Хәерле;
- Тыелган.

**24. Мәетне юу процессында булышмаган кешеләрнең булуы:**

- Тыелган;
- Шелтәләнә;
- Рөхсәт ителгән.

**25. Мәетне кабергә урнаштыргач, аның кәфенен бәйләп торучы бауларның төеннәрен чишәргә кирәк.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**26. Ир кеше хатынының (яки киресенчә) җәсәден юа алмый, чөнки аларның берәрсенең вафатыннан соң, ир белән хатын арасында никах өзелә.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**27. Җеназа намазын укый алмаган кеше, намазны _____________ укый ала. Әмма намаз һич тә соңрак түгел, ә _____________ эчендә укылырга тиеш.**

**28. Вафат булган кешегә матәм көннәре чикләнмәгән.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

**29. Кабернең кыйбла ягыннан ләхет алына һәм шунда уң ягына куелып, мәетнең гәүдәсе урнаштырыла.**

- Дөрес;
- Дөрес түгел.

# Эчтәлек

Кереш өлешкә аңлатма …...........……………………………………………2

Беренче дәрес: “Әл-Фатиха” һәм кайбер кечентә сүрәләр…...................…4

Әс-Саади аңлатмаларыннан өзекләр …………….....................………...6

Кереш өлеш һәм сүрәләрнең аңлатмасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар.……………………….............................……………....32

Икенче дәрес: Исламның баганалары .........……………………….…..54

Өченче дәрес: Иманның баганалары (әркәннәре)……………………...61

Дүртенче дәрес: Тәүхид һәм ширек төрләре……...............…………..66

Бишенче дәрес: Ихсан………………................……………………........…70

Белемнәрне тикшерү өчен сораулар…………………......………………..…71

Алтынчы дәрес: Намаз шартлары………..................................……..79

Жиденче дәрес: Намаз әркәннәре…………….................................……83

Сигезенче дәрес: Намазның үәҗибләре…………….................................84

Тугызынчы дәрес: Тәшәххуднең аңлатмасы…..................................…..85

Унынчы дәрес: Намазның сөннәтләре.……………………….......……..86

Унберенче дәрес: Намазны бозучы гамәлләр......................................…87

*Сәһү сәҗдәсе*..............................................................................……89

Намазның кыскача тасвирламасы……….........................……….90

Намаз хакында кыскача...........................……………………………..100

Намаз хакындагы бүлеккә кагылышлы белемнәрне тикшерү өчен сораулар.............……………………………………………………105

Уникенче дәрес: Тәһарәтнең шартлары…...................………………111

Унөченче дәрес: Тәһарәтнең мәҗбүри өлешләре………..................…112

Ундүртенче дәрес: Тәһарәтне бозучы гамәлләр……........………..113

Тәһарәтнең кыскача тасвирламасы…………….............................…..115

Тәһарәт белән бәйле мәсьәләләрне тасвирлаучы кушымта…………………….......................…………………………118

Тәһарәт һәм госел мәсьәләсе буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар………....................………………………………………122

Зәкәт белән бәйле мәсьәләләрне тасвирлаучы кушымта…..................124

Зәкәт мәсьәләсе буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар..............129

Ураза белән бәйле мәсьәләләрне тасвирлаучы кушымта……........…133

Ураза темасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар…………..140

Хаҗ белән бәйле мәсьәләләрне тасвирлаучы кушымта……………......142

Хаҗ темасы буенча белемнәрне тикшерү өчен сораулар……............148

Унбишенче дәрес: Һәр мөселманга хас булырга тиешле әхлак сыйфатлары………......................................................................153

Уналтынчы дәрес: Ислам дине этикеты ……...........................….…154

Унҗиденче дәрес: Ширектән кисәтү һәм гөнаһларның төрләре…......156

Унсигезенче дәрес: Мәетне җирләргә әзерләү, җеназа намазы һәм аны җирләү ……...............................................................…………158

Белемнәрне тикшерү өчен сораулар………………………………......166

# Библиография

1. Изге Коръән;

2. Имам Мөхәммәд Ибн Исмәгыйль Әль-Бухариның, Аллаһ аңа рәхимле булсын, “Сахих”ы;

3. Имама Мөслим Ибн Хәдждҗәнең, Аллаһ аңа рәхимле булсын, “Сахих”ы;

4. Шейх Габдер-Рахман ибн Нәсыйр Әс-Саадиның, Аллаһ аңа рәхимле булсын, Изге Коръәнгә аңлатмасы.